ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«06» август 2019 ел №583

**Опека һәм попечительлек секторы тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре күрсәтү административ регламентларын раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәт күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары нигезендә Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәге опека һәм попечительлек секторы тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре күрсәтү административ регламентларын расларга:

1.1. Опекага алынган кешеләрне стационар хезмәт күрсәтүгә психоневрологик типтагы интернат-йортларга җибәрүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (1 Кушымта);

1.2. Суд тарафыннан эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраксыз дип танылган балигъ булган зат өстеннән опека яки попечительлек билгеләү һәм опекага алучы яки попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (2 Кушымта);

1.3. Опекага алынган кеше мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (3 Кушымта);

1.4. Опекага алынган кеше мәнфәгатьләрендә опекага алучыга торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (4 Кушымта);

1.5. Опекага алучыга опекага алынган кешенеке булган торакны наймга бирүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (5 Кушымта);

1.6. Опекага алынган кешеләрнең милке белән килешүләр башкаруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (6 Кушымта);

1.7. Яшәү урынын алыштыру белән бәйле рәвештә опекага алучыга (попечительгә) опекага алынган кешене яшәү урыны буенча теркәү исәбеннән төшерүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (7 Кушымта);

1.8. Опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган кешенең милек хокукларына керүенә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (8 Кушымта);

1.9. Опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган кешенең саклык исәп-хисап счеты белән куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (9 Кушымта);

1.10. Ятим балалар өчен оешмаларда яшәүче һәм әти-әнисез калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча бирү мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (10 Кушымта);

1.11. Балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (11 Кушымта);

1.12. Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка алучы булу мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү һәм уллыкка алучылыкка кандидат буларак теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (12 Кушымта);

1.13. Балигъ булмаганнарның күчемле милкен алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (13 Кушымта);

1.14. Ундүрт яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (14 Кушымта);

1.15. Ятим балалар һәм әти-әнисез калган балалар, Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар (түләүле яки түләүсез шартларда) өстеннән опека (попечительлек) билгеләү яки опекага алучы (попечитель) булу мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (15 Кушымта);

1.16. Балигъ булмаган затны тулысынча эмансипацияләү (балигъ булмаган затны тулысынча эшкә яраклы дип тану) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (16 Кушымта);

1.17. Балигъ булмаган затныкы булган күчемсез милекне алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (17 Кушымта);

1.18. Балигъ булмаган затлар катнашында, кредит акчалары кулланып, торак сатып алуга һәм аны залогка (ипотекага) бирүгә алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (18 Кушымта);

1.19. Законлы вәкиленә балигъ булмаган затның акча кертемен алуга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (19 Кушымта);

1.20. Балигъ булмаган затлар катнашында торак залогын яңадан рәсмиләштерүгә (яңадан финанслау) алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (20 Кушымта);

1.21. Суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган, социаль учреждениедә социаль хезмәт күрсәтүдә булган балигъ булган затны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча яшәргә бирү турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (21 Кушымта).

2. «Опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентларын раслау турында» 2013 елның 01 апрелендәге 430 нчы номерлы Арча муниципаль районы башкарма комитеты карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Арча районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.И.Гарифҗановка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесенең
вазыйфаларын башкаручы — Р.И.Гарифҗанов

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының
«__»_________, 2019 ел, №_____
Карарына
1 Кушымта

**Опекага алынган кешеләрне стационар хезмәт күрсәтүгә психоневрологик типтагы интернат-йортларга җибәрүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге регламент Арча муниципаль районында яшәүче опекага алынган кешеләрне стационар хезмәт күрсәтүгә психоневрологик типтагы интернат-йортларга җибәрүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – хезмәт күрсәтү) стандарты һәм тәртипләрен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: опекага алынган кешеләрне стационар хезмәт күрсәтүгә психоневрологик типтагы интернат-йортларга җибәрү турында карар алырга теләүчеләр.

1.3. Дәүләт хезмәте ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен башкаручы – опекага алынган кешенең яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (алга таба – опека һәм попечительлек органы).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

1.3.2. Опека һәм попечительлек органы урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

Эш режимы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш.

Төшке аш вакыты – 12.00 – 13.00.

Эчкә үтү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне аныклаучы документ буенча.

1.3.3. Опека һәм попечительлек органы телефоны: (84366)3–13–81.

1.3.4. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайты (алга таба – «Интернет» челтәре): http://www.arsk.tatarstan.ru.

1.3.5. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы бинасында урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аркылы;

2) «Интернет» челтәре аша:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында http://www.arsk.tatarstan.ru;

3) опека һәм попечительлек секторына шәхси мөрәҗәгать итеп;

4) күпфункцияле үзәктә (хезмәт күрсәтүне күпфункцияле үзәк аркылы алып булган очракта).

1.4. Хезмәт күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә башкарыла:

- Россия Федерациясе Конституциясе (алга таба – РФ Конституциясе) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 26.01.2009, №4, 445 маддә);

- Россия Федерациясе Гаилә кодексы 1995 елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гаилә кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 05.12.1994, №32, 3301 маддә);

- Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы (беренче бүлеге) 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гражданлык кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 05.12.1994, №32, 3301 маддә);

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 маддә);

- «Психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткән вакытта гражданнар хокуклары гарантияләре турында» 1992 елның 02 июлендәге 3185-1 номерлы Россия Федерациясе законы (алга таба – 3185-1 номерлы РФ Законы) («Россия Федерациясенең халык депутатлары Советы һәм Югары Советы ведомосте», 20.08.1992, №33, 1913 маддә);

- «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законы (алга таба – 323-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 28.11.2011, №48, 6724 маддә);

- «Күчемсез милеккә хокук һәм аның белән килешүләрне дәүләт теркәве турында» 1997 елның 21 июлендәге 122-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба дәүләт теркәве турында ФЗ) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 28.07.1997, №30, 3594 маддә);

- «Шәхси мәгълүмат турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 152-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2006, №31 (1 бүлек), 3451 маддә);

- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 28.04.2008, №17, 1755 маддә);

- «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ Федераль закон (21.07.2014 редакциясендә) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 31.12.2003, №52 (1 бүлек), 7007 маддә)

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №43-44, 02.03.2004);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №60-61, 25.03.2008);

- «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 880 нче номерлы Карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары җыелмасы, 08.12.2010, №46, 2144 маддә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 15 августындагы боерыгы белән расланган Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында Нигезләмәсе (алга таба – опека секторы турнда Нигезләмә).

1.5.Әлеге Регламентта түбәндәге термин һәм билгеләмәләр кулланыла:

- опека – суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган гражданнарның төзелеш формасы, опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (опекуннар) аларның законлы вәкилләре булып санала һәм алар исеменнән һәм алар мәнфәгате буенча юридик әһәмияткә ия булган гамәлләр башкара ала;

- опекага алынган зат – аңа карата опека яки попечительлек билгеләнгән гражданин;

- эшкә яраксыз гражданин – РФ Гражданнар Кодексының 29 маддәсе нигезендә суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган гражданин;

- административ регламент –Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралар һәм административ эшчәнлек вакытын һәм эзлеклелеген, структур бүлекчәләр һәм вазыйфаи затлар арасындагы хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хакимияте башкарма органнарының физик яки юридик затлар (алга таба – дәүләт хезмәте алучылар), башка дәүләт хезмәте һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгеләүче норматив хокукый документ;

- дәүләт хезмәте – дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән чикләрдә мөрәҗәгать итүче соравы буенча башкарыла торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарган вакытта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек;

- дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе $1^1$ бүлегендә каралган оешмалар яки аларның эшчеләре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта бозылган хокукларны яки законлы мәнфәгатьләрне кире кайтару яки саклау турында таләбе.

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яки муниципаль учреждениенең оештыру-хокукый формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирүче һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча, вәкаләтле оешма;

- «бер тәрәзә» принцибы – мөрәҗәгать итүче 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ маддәсендә күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү, ә дәүләт хезмәт күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар белән күпфункцияле үзәк тарафыннан мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актлар һәм хезмәттәшлек итү турында килешү нигезендә хезмәттәшлек алып бару принцибы.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбе исеме | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Хезмәт күрсәтү исеме | Опекага алынган кешеләрне стационар хезмәт күрсәтүгә психоневрологик типтагы интернат-йортларга җибәрүгә рөхсәт бирү | РФ Гражданлык кодексы, РФ Гаилә кодексы;<br>122-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>3185-ФЗ номерлы Федераль закон, 8-ТРЗ номерлы ТР Законы |
| 2.2. Хезмәт күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты (опекага алынган кешенең яшәү урыны буенча) | Устав, сектор турында Нигезләмә; 7-ТРЗ номерлы ТР Законы |
| 2.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарының опекага алынган кешеләрне стационар хезмәт күрсәтүгә психоневрологик типтагы интернат-йортларга җибәрү (медицина күрсәткечләре һәм клиника-эксперт комиссиясе (алга таба – КЭК) булган очракта) яки опекага алынган кешеләрне стационар хезмәт күрсәтүгә психоневрологик типтагы интернат-йортларга җибәрмәү турында боерыгы | РФ Гражданлык кодексы; 122-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>8-ТРЗ номерлы ТР Законы |
| 2.4. Хезмәт күрсәтү вакыты | Мөрәҗәгать итүчедән барлык кирәкле документларны алганнан соң 15 көн эчендә | |
| 2.5. Закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларның тулы исемлеге | 1. опекага алынган кешеләрне стационар хезмәт күрсәтүгә психоневрологик типтагы интернат-йортларга җибәрү турында рөхсәт бирү турында опекага алучы гаризасы;<br>2. әлеге сәламәтлек саклау учреждениесендә булган һәм стационар социаль хезмәт күрсәтүгә махсуслашкан учреждениегә урнаштыруга мохтаҗ булган эшкә яраксыз затка карата опекага алучы вазыйфаларын башкаручы сәламәтлек саклау учреждениесе гаризасы;<br>3. опека яки попечительлек билгеләү турында һәм опекага алучы яки попечитель билгеләү турында яки опекага алучыны ачыклау турында хокукый акт күчермәсе;<br>4. гражданинны эшкә яраксыз дип тану турында законлы көченә кергән суд органы карары күчермәсе;<br>5. медико-социаль экспертиза учреждениесе тарафыннан бирелгән балигъ булган опекага алынган кешенең инвалидлыгы турында (булган очракта) һәм аны ребилитацияләүнең шәхси программасы турында белешмә (кабул ителгән үрнәктәге) күчермәсе;<br>6. опекага алынган затның паспорт күчермәсе;<br>7. булган очракта опекага алынган затның милке (автомототранспорт, кыйммәтле кәгазьләр, исәп-хисап счетлары һ.б.) турында белешмә;<br>8. мәҗбүри рәвештә табиб-психиатр катнашкан табиблык комиссиясенең (клиник-эксперт комиссиясе) затта аны социаль хезсәт күрсәтү өчен | РФ Гражданлык кодексы;<br>3185-1 ФЗ номерлы Федераль закон;<br>442-ФЗ номерлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| | махсуслашмаган учреждениедә булу мөмкинлегеннән мәхрүм итә торган психик тайпылыш (авыру диагнозы) булуы турында нәтиҗәсе. Нәтиҗәдә аның нинди дәвалау-профилактика учреждениесе тарафыннан рәсмиләштерелүе турында мәгълүмат, рәсмиләштерү номеры, датасы, табиблык комиссиясе әгъзаларының имзалары, фамилияләре, исемнәре, әтиләренең исемнәре булырга тиеш һәм ул дәвалау-профилактика учреждениесенең мөһере белән расланган булырга тиеш | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган документларның тулы исемлеге | Опекага алынган кешенең милке турында Бердәм дәүләт хокукый реестрыннан (Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография Федераль хезмәте идарәсе) алынган мәгълүмат | |
| 2.7. Норматив хокукый актлар белән каралган очракларда хезмәт күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган һәм хезмәт күрсәтә торган башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла торган дәүләт хакимияте һәм аның структур бүлекчәләре исемлеге | Килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Гражданинның тору урыны буенча мөрәҗәгать итмәве | |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>- тапшырылган документларның әлеге Административ регламеентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве | РФ Гражданлык кодексы; 48-ФЗ номерлы Федераль закон; 210-ФЗ номерлы Федераль закон; 122-ФЗ номерлы Федераль закон; 8-ЗРТ номерлы Федераль закон |
| 2.10. Хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә. | |
| 2.11. Әлеге түләүне исәпләү турында мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр таләп ителми | |
| 2.12. Хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алган вакытта чиратта көтүнең максималь вакыты | Аерым категория кешеләр өчен чират билгеләнмәгән. Көтеп утыруның (хезмәт күрсәтүнең) максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты | Гариза кергән көнне | |
| 2.14. Хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр | 1. Гариза түбәндәге адрес буенча тапшырыла:<br>Арча шәһәре, Советлар мәйданы урамы, 12 йорт, опека һәм попечительлек секторы.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү | |

| | | |
|---|---|---|
| | системасы белән җиһазланган бинада башкарыла;<br>3. Бинада гаризалар кабул итү өчен сектор белгеченең эш урыны хезмәтне тулысынча күрсәтергә мөмкинлек бирүче электрон белешмә-хокукый системалар, оргтехника белән тәэмин ителгән шәхси компьютер белән җиһазландырыла.<br>4. Документлар тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазлана һәм документлар тутыру үрнәкләре белән тәэмин ителә.<br>5. Инвалидларга хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыкларсыз керү тәэмин ителә, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм чыгу юлларына, дәүләт хезмәте күрсәтү урынына барып җитү максатында объект буйлап мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итү тәэмин ителә.<br>6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны исәпкә алып, урнаштырыла. | |
| 2.15. Хезмәт күрсәтүнең мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Хезмәт күрсәтүнең аңлаешлылыгы күрсәткечләре:<br>- бинаның җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы;<br>- гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү өчен бина булуы;<br>- мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә башкарма комитетның мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү бердәм порталында хезмәт күрсәтү тәртибе, ысуллары, вакыты турында тулы мәгълүмат булу.<br>Хезмәт күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре:<br>-хезмәт күрсәтү вакытын бозу;<br>- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирү;<br>- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә игътибарсызлык күрсәтүенә шикаять бирү.<br>Хезмәт күпфункцияле үзәктә күрсәтелми. | |
| 2.16. Хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Хезмәт электрон формада күрсәтелми | |

## 3. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкару составы, эзлеклелеге һәм вакыты, аларны башкару тәртибенә таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау:

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- мөрәҗәгать итүчегә опекага алынган кешеләрне стационар хезмәт күрсәтүгә психоневрологик типтагы интернат-йортларга җибәрү турында карар бирү мәсьәләләре буенча консультация бирү;
- гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;
- кабул итү яки баш тарту нигезләрен билгеләү өчен тапшырылган документларның әлеге Административ регламент таләпләренә туры килүен тикшерү;
- Бердәм дәүләт хокукый реестрыннан (Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсе) опекага алынган кешенең милке турында мәгълүмат соратып алу;
- дәүләт хезмәте күрсәтү яки күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема әлеге Административ регламентка 1 кушымтада бирелә.

3.2. Консультация бирү

Мәгълүмат һәм консультация бирү буенча процедуралар кысаларында гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибен җайлаучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;
- опекага алучыны опекага алынган затны стационар хезмәт күрсәтүгә психоневрологик типтагы интернат-йортка җибәрү турында карар бирү мәсьәләсе буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән таныштыра;
- опекага алынган кешене стационар хезмәт күрсәтүгә психоневрологик типтагы интернат-йортка җибәрү турында карар бирү өчен кирәкле документлар исемлеген бирә.

Консультация гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Процедура нәтиҗәсе: документлар составы һәм хезмәт күрсәтү буенча башка сораулар буенча консультация.

Гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирүче белгеч, шәхси мәгълүматларны исәпкә алып, консультациянең грамоталыгы, тулылыгы һәм ачыклыгы өчен шәхси җавап бирә.

3.3. Гариза бирүче, 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән үзе гариза тапшыра.

Опека һәм попечительлек секторы белгече:

- гариза бирүченең шәхесен, опекага алынган кешенең тору урынын; опека билгеләү һәм опекага алучыны билгеләү турында норматив хокукый акт (карар, боерык, әмер һ.б) булуын ачыклый.
- документларның барлыгын тикшерә. Кирәкле документлар булмаган очракта җитмәгән документларны тапшырырга тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларны кабул итүне таләп итсә, документлар кабул ителә.

Документларны кабул итүдән баш тартуга әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта опека һәм попечительлек, күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелсә) белгече гариза бирүчегә гариза һәм документлар алу, теркәлү номеры турында хәбәр итә, аннан соң әлеге Регламентның 3.4. подпунктында күрсәтелгән процедуралар башкарыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән вакыттан соң 1 көн эчендә 15 минут вакыт аралыгында башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язмасы.

Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч, конфиденциаль мәгълүматларны исәпкә алып, документларны кабул итү буенча процедураларны башкаруның дөреслеге өчен шәхси җавап бирә.

3.4 Опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүче тапшырган документлардагы мәгълүматны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергәннән соң 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәт бирү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратып алу әзерләү һәм җибәрү.

3.5.1 Опека һәм попечительлек белгече (гариза бирүче белән килештереп) ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү системасы аркылы әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны җибәрү турында электрон формада соратып алу юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән көннән 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында юлланган соратып алу.

3.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы опека һәм попечительлек секторы органнары соратуы буенча автоматлаштырылган режимда башкарыла:

- соратып алуны эшкәртү һәм соратылган мәгълүматны эзләү;
- ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү аркылы соратып алынган мәгълүматны формалаштыру, соратып алынган мәгълүмат булмаган очракта, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, соратып алынган мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар опека һәм попечительлек органнарына соратып алу кергән вакыттан 5 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: соратып алуга җавап яки әлеге Регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.6.1. Тапшырылган документлар нигезендә опека һәм попечительлек секторы белгече опекага алынган затларны психоневрологик типтагы интернат-йортларга җибәрү турында рөхсәт бирү турында боерык проекты әзерли һәм аны килештерү һәм раслату өчен опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә җибәрә яки тиешле аныклау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: опекага алынган затларны стационар хезмәт күрсәтүгә психоневрлогик типтагы интернат-йортларга җибәрү турында боерык яки 3.8 пункты нигезендә әзерләнгән хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.7. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен тапшыру.

3.7.1. Опека һәм попечительлек секторы белгече, имзаланган боерыкны алгач, аны терки һәм гариза бирүчегә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.5.1 подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.8. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат тапшыру.

3.8.1 Опека һәм попечительлек секторы белгече боерык бирүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты әзерли.

Әзерләнгән баш тарту турында хат проектын Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар баш тарту өчен нигезләр ачыкланган көннән соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзалауга юлланган баш тарту турында хат проекты.

3.8.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек секторы белгеченә кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзаланган баш тарту турында хат.

3.8.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече баш тарту турында хатны аны имзалаган көннән соң 1 эш көне эчендә гариза бирүчегә юллый. Шул ук вакытта гариза бирүчегә карарны шикаять итү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.7.2. подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формасы

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларын үтәүне тикшерүне, карар кабул итүне һәм күпфункцияле үзәкнең (хезмәт күпфункцияле үзәк аркылы күрсәтелсә), опека һәм попечительлек бүлегенең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап бирүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларының хокукый экспертизасын үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау;

- кабул итлегән тәртиптә делопроизводство алып баруны тикшерү;

- кабул ителгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү үткәрү процедураларына контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерү үткәргән вакытта дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык сораулар каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта һәм карар кабул иткән вакытта гамәлләрне башкаруны тикшерүне башкару максатында күпфункцияле үзәк, опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затлар исемлеге күпфункцияле үзәкнең, опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы гариза бирүченең мөрәҗәгатен вакытында карамаган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезләнмәгән рәвештә баш тарткан өчен җавап бирә.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, аларның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелгән очракта), опека һәм попечительлек секторы хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Арча муниципаль районы башкарма комитетына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итәргә мөкин:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган документлар, мәгълүмат яки гамәл кылу таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү вакыты яки тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылганда, әгәр туктатылу нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта мөрәҗәгать итүчедән беренче тапкыр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документлар тапшырган вакытта булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү.

5.2. Шикаять почта аркылы язма рәвештә кәгазь битендә яки электрон формада җибәрелергә, шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәткән очракта шикаять күпфункцияле үзәк аркылы җибәрелә ала.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең документларны кабул итүдән баш тартуына яки киткән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять биргән очракта яки мондый төзәтүләрне башкаруның кабул ителгән вакыты бозылуга шикаять биргән очракта – аны теркәгән көннән соң 5 эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исемен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки муниципаль хезмәткәрнең исемен;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән риза булмавына дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә тасвирланган вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре теркәлгән булырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документлар исемлеге бирелә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәте күрсәтелүче зат тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта Башкарма комитет тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта ачыкланган бозуларны кичекмәстән бетерү максатында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле гамәлләр турында әйтелә.

5.9. Әгәр шикаять канәгатьләндерелмәсә, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул итлегән карарга нигезләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында аңлатма бирелә.

5.10. Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Опекага алынган кешеләрне стационар хезмәт күрсәтүгә психоневрологик типтагы интернат-йортларга җибәрүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына
1 Кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү БЛОК-СХЕМАСЫ**

Опекага алынган кешеләрне стационар хезмәт күрсәтүгә психоневрологик типтагы интернат-йортларга җибәрүгә рөхсәт бирү сораулары буенча гражданнарга мәгълүмат һәм консультация бирү

//

Гариза һәм документлар кабул итү

//

Тапшырылган документларны тикшерү

// \\

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булмаган очракта опекага алынган затларны психоневрологик типтагы интернат-йортларга җибәрү турында карар әзерли

Опекага алынган затларны психоневрологик типтагы интернат-йортларга җибәрү турында боерык бирүдән баш тарту турында хат әзерләү

// \\

Опекага алынган затларны психоневрологик типтагы интернат-йортларга җибәрү турында боерык бирү

Опекага алынган затларны психоневрологик типтагы интернат-йортларга җибәрүдән таш тарту турында хат бирү

Опекага алынган кешеләрне стационар хезмәт күрсәтүгә психоневрологик типтагы интернат-йортларга җибәрүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына
2 Кушымта

## Техник хатаны төзәтү турында гариза

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта җибәрелгән хата турында хәбәр итәм _______________________________________________________________(хата төре)

Язылган:_____________________________________________________________

Дөрес мәгълүмат:_______________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документка түбәндәге үзгәрешләрне кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итмәү турында карар кабул иткән очракта мондый карарны түбәндәге юл белән җибәрүегезне сорыйм:

Электрон документ җибәрү юлы белән E-mail адреска:_________________

Почта аша кәгазь вариантта расланган күчермә формасында ___________________________ адресы буенча.

Үземнең һәм мин вәкиле булып торган затның шәхси мәгълүматны эшкәртүгә (шәхси мәгълүматны җыю, системалаштыру, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), туктату, юкка чыгару, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматны эшкәртү өчен кирәк булган башка гамәлләр кылу), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, дәүләт хезмәте күрсәтү максатында алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан карар кабул итүне кертеп, ризалыгымны раслыйм.

Әлеге низедә раслыйм: гаризага кертелгән, минем һәм мин вәкиле булып торган затның шәхесенә кагылучы мәгълүматның, шулай ук минем тарафтан кертелгән түбәндәге меәгълүматның дөреслеген. Гаризага теркәлгән документлар (документ күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза тапшырган вакытка әлеге документлар гамәлдә һәм дөрес мәгълүматны үз эченә ала.

Түбәндәге телефон буенча миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәте сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашуга үземнең ризалыгымны бирәм: ________________________.

Дата__________________Имза________________/________________________

Хезмәт билгеләре Гариза керде: Дата:

Теркәү №

Гаризаны алган затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме һәм имзасы.

Опекага алынган кешеләрне стационар хезмәт күрсәтүгә психоневрологик типтагы интернат-йортларга җибәрүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына
Кушымта (мәгълүмати)

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне агымдагы контрольдә тотучы җаваплы вазыйфаи затларның**
**РЕКВИЗИТЛАРЫ**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-84366 ) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |
| Сектор белгече | (8-84366 ) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы (шәһәр округы) Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-84366) 3-00-44 | Ispolkom.Arsk@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Арча муниципаль
районы башкарма комитетының
«__»_________, 2019 ел, №_____
Карарына
2 Кушымта

**Суд тарафыннан эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы дип танылган балигъ булган зат өстеннән опека яки попечительлек билгеләү һәм опекага алучы яки попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге регламент Арча муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнар өчен суд тарафыннан эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы дип танылган балигъ булган зат өстеннән опека яки попечительлек билгеләү һәм опекага алучы яки попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.
1.2. Дәүләт хезмәте алучылар: суд тарафыннан эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы дип танылган балигъ булган зат өстеннән опека яки попечительлек алырга теләүче Россия Федерациясе гражданнары.
1.3. Дәүләт хезмәте ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен башкаручы – опекага алынган кешенең яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (алга таба – опека һәм попечительлек органы).
1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.
1.3.2. Опека һәм попечительлек органы урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.
Эш режимы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш.
Төшке аш вакыты – 12.00 – 13.00.
Эчкә үтү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне аныклаучы документ буенча.
Опека һәм попечительлек органы телефоны: (84366)3–13–81.
1.3.3. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайты (алга таба – «Интернет» челтәре): http://www.arsk.tatarstan.ru.
1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:
1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы бинасында урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аркылы;
2) «Интернет» челтәре аша:
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында http://www.arsk.tatarstan.ru;
3) опека һәм попечительлек секторына шәхси мөрәҗәгать итеп;
4) күпфункцияле үзәктә (хезмәт күрсәтүне күпфункцияле үзәк аркылы алып булган очракта).
1.4. Хезмәт күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә башкарыла:
- Россия Федерациясе Конституциясе (алга таба – РФ Конституциясе) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 26.01.2009, №4, 445 маддә);
- Россия Федерациясе Гаилә кодексы 1995 елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гаилә кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 05.12.1994, №32, 3301 маддә);
- Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы (беренче бүлеге) 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гражданлык кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 05.12.1994, №32, 3301 маддә);
- Россия Федерациясе Салым кодексы (1 бүлек) 1998 елның 31 июлендәге 146-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Салым кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 03.08.1998, №31);
- Россия Федерациясе Торак кодексы 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ нмоерлы (алга таба – РФ Торак кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 03.01.2005, №1 (1 бүлек), 14 маддә);
- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 маддә);
- «Психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткән вакытта гражданнар хокуклары гарантияләре турында» 1992 елның 02 июлендәге 3185-1 номерлы Россия Федерациясе законы (алга таба – 3185-1 номерлы РФ Законы) («Россия Федерациясенең халык депутатлары Советы һәм Югары Советы ведомосте», 20.08.1992, №33, 1913 маддә);

- «Күчемсез милеккә хокук һәм аның белән килешүләрне дәүләт теркәве турында» 1997 елның 21 июлендәге 122-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба дәүләт теркәве турында ФЗ) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 28.07.1997, №30, 3594 маддә);
- «Шәхси мәгълүмат турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 152-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2006, №31 (1 бүлек), 3451 маддә);
- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 28.04.2008, №17, 1755 маддә);
- «Балигъ булган эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраксыз гражданнарга карата опека һәм попечительлек алып баруның аерым мәсьәләләре турында» 2010 елның 17 ноябрендәге 927 нче номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (алга таба – 927 нче номерлы РФ Хөкүмәте карары) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 23.11.2010, №48, 6401 маддә);
- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №43-44, 02.03.2004);
- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №60-61, 25.03.2008);
- «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 880 нче номерлы Карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары җыелмасы, 08.12.2010, №46, 2144 маддә);
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 15 августындагы боерыгы белән расланган Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында Нигезләмәсе (алга таба – опека секторы турында Нигезләмә).

1.5.Әлеге Регламентта түбәндәге термин һәм билгеләмәләр кулланыла:
- опека – суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган гражданнарның төзелеш формасы, опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (опекуннар) аларның законлы вәкилләре булып санала һәм алар исеменнән һәм алар мәнфәгате буенча юридик әһәмияткә ия булган гамәлләр башкара ала;
- попечительлек – суд тарафыннан эшкә яраксызлыгы чикләнгән гражданнарның төзелеш формасы, опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (попечительләр) балигъ булган опекага алынган затларга РФ Гражданлык кодексының 30 маддәсе белән каралган гамәлләр кылуга ризалык бирергә тиеш.
- опекага алынган зат – аңа карата опека яки попечительлек билгеләнгән гражданин;
- эшкә яраксыз гражданин – РФ Гражданнар Кодексының 29 маддәсе нигезендә суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган гражданин;
- административ регламент –Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралар һәм административ эшчәнлек вакытын һәм эзлеклелеген, структур бүлекчәләр һәм вазыйфаи затлар арасындагы хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хакимияте башкарма органнарының физик яки юридик затлар (алга таба – дәүләт хезмәте алучылар), башка дәүләт хезмәте һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгеләүче норматив хокукый документ;
- дәүләт хезмәте – дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән чикләрдә мөрәҗәгать итүче соравы буенча башкарыла торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарган вакытта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек;
- дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе 11 бүлегендә каралган оешмалар яки аларның эшчеләре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта бозылган хокукларны яки законлы мәнфәгатьләрне кире кайтару яки саклау турында таләбе.
- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яки муниципаль учреждениенең оештыру-хокукый формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирүче һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча, вәкаләтле оешма;

- «бер тәрәзә» принцибы – мөрәҗәгать итүче 210-ФЗ номерлы Федераль законның 151 маддәсендә күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү, ә дәүләт хезмәт күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар белән күпфункцияле үзәк тарафыннан мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актлар һәм хезмәттәшлек итү турында килешү нигезендә хезмәттәшлек алып бару принцибы.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбе исеме | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Хезмәт күрсәтү исеме | Суд тарафыннан эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы дип танылган балигъ булган зат өстеннән опека яки попечительлек билгеләү һәм опекага алучы яки попечитель билгеләү | РФ Гражданлык кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>927 нче номерлы РФ карары |
| 2.2. Турыдан-туры хезмәт күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты (опекага алынган кешенең яшәү урыны буенча) | Устав;<br>7-ТРЗ номерлы ТР законы |
| 2.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Опека (попечительлек) һәм опекага алучы (попечитель) билгеләү турында Арча муниципаль районы башкарма комитет карары (1 Кушымта) яки опекага алучы (попечитель) билгеләүдән баш тарту | 48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>927 нче номерлы РФ карары |
| 2.4. Хезмәт күрсәтү вакыты | Мөрәҗәгать итүчедән барлык кирәкле документларны алганнан соң 15 көн эчендә | 927 нче номерлы РФ карары |
| 2.5. Закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларның тулы исемлеге | 1. Гариза (2 Кушымта).<br>2. Опекага алучылыкка кандидатның паспорт күчермәсе.<br>3. Гаилә кору турында таныклык күчермәсе (әгәр опекага алучы булырга теләк белдергән гражданин гаиләле кеше булса).<br>4. Опекага алырга (попечитель булырга) теләк белдерүче гражданинның медицина тикшерүе турында белешмәсе*.<br>5. Биләгән вазыйфаны һәм соңгы 12 айга хезмәт хакы күләмен күрсәтеп, эш урыныннан белешмә, хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган гражданнар өчен – керемнәрне раслаучы башка документ (пенсионерлар өчен – пенсия таныклыгы күчермәсе, Россия Федерациясе Пенсия фонды территориаль органы яки пенсия белән тәэмин итә торган башка орган белешмәсе күчермәсе).<br>6. Опекага алучы (попечитель) булырга кандидатка эш урыныннан характеристика. Әгәр эш урыны булмаса, йорт идарәсеннән характеристика.<br>7. Опекага алучы (попечитель) булырга кандидатның торакка хокук билгеләүче документлары күчермәсе – ордер, торак бинаны гражданнарга милеккә бирү килешүе, сату-алу килешүе һ.б.<br>8. Опекага алучы булырга теләк белдергән гражданинн белән бергә яшәүче балигъ булган гаилә әгъзаларының, 10 яшькә җиткән балаларны да кертеп, балигъ булган опекага алынган затның опекага алучы белән бергә яшәвенә язмача ризалыгы, шулай ук опекага аланган кешенең яшәү урынына бәйсез рәвештә – якын туганнарның (әти/әнинең, бертуган абый-апа, эне-сеңелләрнең) ризалыгы; аерым очракларда опекага алынучы кешенең ризалыгы исәпкә алына (гариза формасында).<br>9. Опекага алырга кандидатның автобиографиясе. | РФ Гражданлык кодексы; РФ Салым кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>927 нче номерлы РФ карары |

| | | |
|---|---|---|
| | ** «4» пункт белән каралган документлар опека һәм попечительлек секторы тарафыннан аларны биргән көннән соң алты ай эчендә кабул ителә, «5» һәм «6» пунктлар белән каралган документлар – аларны биргән көннән соң бер ел эчендә.* | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган документларның тулы исемлеге | 1. Опекага алынган кешенең милке турында Бердәм дәүләт хокукый реестрыннан (Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография Федераль хезмәте идарәсе) алынган мәгълүмат;<br>2. Опекага алучы (попечитель) булырга теләк белдерүчедә граждannар тормышына һәм сәламәтлегенә каршы алдан уйланган җинаять эшләгән өчен хөкемгә тартылмау турында эчке эшләр органыннан белешмә* (мөрәҗәгать итүче ризалыгы белән).<br>3. Торак биналарның санитар һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килүе турында белешмә.<br>4. Тору урыны буенча йорт (фатир) кенәгәсеннән өземтә яки торак бина белән куллану хокукын раслаучы яки торак бинага милек хокукын раслаучы башка документ һәм опекага алырга теләк белдергән гражданинның тору урыныннан финанс-исәп-хисап счеты күчермәсе. | |
| 2.7. Норматив хокукый актлар белән каралган очракларда хезмәт күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган һәм хезмәт күрсәтә торган башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла торган дәүләт хакимияте һәм аның структур бүлекчәләре исемлеге | Килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Гражданинның тору урыны буенча мөрәҗәгать итмәве | 927 нче номерлы РФ карары |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>- тапшырылган документларның әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве | РФ Гаилә кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.10. Хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә. | |
| 2.11. Әлеге түләүне исәпләү турында мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр таләп ителми | |
| 2.12. Хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алган вакытта чиратта көтүнең максималь вакыты | Аерым категория кешеләр өчен чират билгеләнмәгән. Көтеп утыруның (хезмәт күрсәтүнең) максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү | Гариза кергән көнне | |

| | | |
|---|---|---|
| вакыты | | |
| 2.14. Хезмәтләр күрсәтелә торган биналарга таләпләр | 1. Гариза түбәндәге адрес буенча тапшырыла:<br>Арча шәһәре, Советлар мәйданы урамы, 12 йорт, опека һәм попечительлек секторы.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазланган бинада башкарыла;<br>3. Бинада гаризалар кабул итү өчен сектор белгеченең эш урыны хезмәтне тулысынча күрсәтергә мөмкинлек бирүче электрон белешмә-хокукый системалар, оргтехника белән тәэмин ителгән шәхси компьютер белән җиһазландырыла.<br>4. Документлар тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазлана һәм документлар тутыру үрнәкләре белән тәэмин ителә.<br>5. Инвалидларга хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыкларсыз керү тәэмин ителә, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм чыгу юлларына, дәүләт хезмәте күрсәтү урынына барып җитү максатында объект буйлап мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итү тәэмин ителә.<br>6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны исәпкә алып, урнаштырыла. | |
| 2.15. Хезмәт күрсәтүнең мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең аңлаешлылыгы күрсәткечләре:<br>- бинаның җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы;<br>- мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү өчен бина һәм җитәрлек белгеч булуы;<br>- мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә башкарма комитетның мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, ысуллары, вакыты турында тулы мәгълүмат булу.<br>- инвалидларга башкалар белән беррәттән хезмәтләрне алу өчен комачаулык тудыра торган каршылыкларны узуда ярдәм күрсәтү.<br>Хезмәт күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре түбәндәге күрсәткечләрнең булмавы белән билгеләнә:<br>- мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итеп алганда һәм аңа документлар биргәндә чиратлар булмавы;<br>- дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозу;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтә торган муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен алганда муниципаль хезмәт күрсәтә торган вазыйфаи зат белән гариза бирүченең бер тапкыр очрашуы күздә тотыла. Хезмәттәшлек итү вакыты регламент белән билгеләнә.<br>Хезмәт күпфункцияле үзәктә күрсәтелми. | |
| 2.16. Хезмәтне электрон формада күрсәтү | Хезмәт электрон формада күрсәтелми | |

| | | |
|---|---|---|
| үзенчәлекләре | | |

## 3. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкару составы, эзлеклелеге һәм вакыты, аларны башкару тәртибенә таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау:
3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:
- мөрәҗәгать итүчегә закон нигезендә эшкә яраксыз яки өлешчә эшкт яраклы дип танылган балигъ булган зат өстеннән опека һәм попечительлек билгеләү мәсьләләре буенча консультация һәм мәгълүмат бирү;
- гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;
- кабул итү яки баш тарту нигезләрен билгеләү өчен тапшырылган документларның әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү;
- ведомствоара соратып алулар формалаштыру;
- гариза бирүче һәм опекага алынучының тормыш шартларын тикшерү; дәүләт хезмәте күрсәтү яки күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү.
3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема әлеге Административ регламентка 6 кушымтада бирелә.
3.2. Консультация бирү
Мәгълүмат һәм консультация бирү буенча процедуралар кысаларында гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:
- дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибен җайлаучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;
- гариза бирүчеләрне, шулай ук аларның законлы вәкилләрен суд тарафыннан эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы дип танылган балигъ булган зат өстеннән опека яки попечительлек һәм опекага алучы яки попечитель билгеләү мәсьләләре буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән таныштыра;
- конкрет затны опекага алучы яки попечитель итеп билгеләү өчен кирәкле документлар исемлеген бирә.
Консультация гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.
Процедура нәтиҗәсе: документлар составы һәм хезмәт күрсәтү буенча башка сораулар буенча консультация.
Консультация һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедуралар башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.
Гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирүче белгеч, шәхси мәгълүматларны исәпкә алып, консультациянең грамоталыгы, тулылыгы һәм ачыклыгы өчен шәхси җавап бирә.
3.3. Гариза бирүче, 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән үзе гариза тапшыра.
Опека һәм попечительлек секторы белгече:
- гариза бирүченең шәхесен, опекага алынган кешенең тору урынын; опека билгеләү һәм опекага алучыны билгеләү турында норматив хокукый акт (карар, боерык, әмер һ.б) булуын ачыклый.
- документларның барлыгын тикшерә. Кирәкле документлар булмаган очракта җитмәгән документларны тапшырырга тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларны кабул итүне таләп итсә, документлар кабул ителә.
Документларны кабул итүдән баш тартуга әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта опека һәм попечительлек, күпфункцияле үзәк белгече гариза бирүчегә гариза һәм документлар алу, теркәлү номеры турында хәбәр итә, аннан соң әлеге Регламентның 3.5. подпунктында күрсәтелгән процедуралар башкарыла.
Опекага алучы яки попечитель булырга теләгән заттан шәхси мәгълүматны эшкәртүгә ризалык турында гариза кабул итә.
Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән вакыттан соң 1 көн эчендә 15 минут вакыт аралыгында башкарыла.
Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язмасы (3 Кушымта).
3.3.1. Һәр опекага алынган затка шәхси эш ачыла, анда документлар (тиешле тәртиптә расланган документ күчермәләре) беркетелә, шәхси эш эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы гражданнарның шәхси эшләрен теркәү журналында (4 Кушымта) теркәлә.
Процедуралар нәтиҗәсе: тегелгән һәм теркәлгән шәхси эш.
Гамәлләрне башкаруның максималь вакыты – 10 минут.
3.4 Опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүче тапшырган документлардагы мәгълүматны тикшерә.
Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергәннән соң 2 эш көне эчендә башкарыла.
Процедуралар нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәт бирү яки баш тарту турында карар кабул итү.
3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратып алу әзерләү һәм җибәрү.
3.5.1 Опека һәм попечительлек белгече (гариза бирүче белән килештереп) ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү системасы аркылы әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны җибәрү турында электрон формада соратып алу юллый.
Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән көннән 2 эш көне эчендә башкарыла.
Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында юлланган соратып алу.
3.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы опека һәм попечительлек секторы органнары соратуы буенча автоматлаштырылган режимда башкарыла:
- соратып алуны эшкәртү һәм соратылган мәгълүматны эзләү;

- ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү аркылы соратып алынган мәгълүматны формалаштыру, соратып алынган мәгълүмат булмаган очракта, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, соратып алынган мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе җибәрү.
Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар опека һәм попечительлек органнарына соратып алу кергән вакыттан 5 эш көне эчендә башкарыла.
Процедуралар нәтиҗәсе: соратып алуга җавап яки әлеге Регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе.
3.6. Опека һәм попечительлек секторы белгече опекага алучы яки попечитель булырга теләк белдергән гражданинның тормыш шартларын тикшерә, тикшерү барышында опекага алучы (попечитель) итеп билгеләргә комачаулык тудыра торган, РФ Гражданлык кодексы белән билгеләнгән шартлар булмавы ачыклана. Әлеге акт (5 Кушымта) шәхси эшкә беркетелә.
Опекага алучы (попечитель) булырга теләк белдергән гражданинның тормыш шартларын тикшергән вакытта опека һәм попечительлек секторы белгече торак-көнкүреш шартларын, опекага алучы вазыйфаларын башкаруга мөмкинлекләрен, гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләрне тикшерә.
Тикшерү нәтиҗәләре опекага алучы (попечитель) булырга теләк белдергән гражданинның тормыш шартларын тикшерү турында актта күрсәтелә (алга таба – тикшерү турында акт). Тикшерү турында акт 2 нөсхәдә тутырыла, аның берсе опекага алучы (попечитель) булырга теләк белдергән гражданинга тапшырыла, 3 көн эчендә тикшерү акты раслана, икенче нөсхәсе опека һәм попечительлек органында саклана.
Тикшерү турында акт опекага алучы булырга теләк белдергән гражданин тарафыннан суд тәртибендә шикаять ителә ала.
Муниципаль берәмлекнең башкарма комитет җитәкчесе эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы гражданинның матди-көнкүреш шартларын һәм опекага алучының яки попечительнең тормыш шартларын тикшерү максатында опека һәм попечительлек секторы белгечен автотранспорт чарасы белән тәэмин итә.
Процедуралар нәтиҗәсе: опекага алучы (попечитель) булырга теләк белдергән гражданинның тормыш шартларын тикшерү турында акт.
Гамәл кылуның максималь вакыты – опекага алучы яки попечитель булырга теләк белдергән затның гаризасын рәсмиләштергән көннән соң 3 көн эчендә.
3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.
3.7.1. Тапшырылган документлар нигезендә опека һәм попечительлек секторы белгече суд тарафыннан эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы дип танылган балигъ булган зат өстеннән опека яки попечительлек һәм опекага алучы яки попечитель билгеләү турында боерык проекты әзерли һәм аны килештерү һәм раслату өчен опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә җибәрә яки тиешле аныклау белән баш тарту турында хат әзерли.
Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң 5 көн эчендә башкарыла.
Процедуралар нәтиҗәсе: суд тарафыннан эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраксыз дип танылган балигъ булган зат өстеннән опека яки попечительлек һәм опекага алучы яки попечитель билгеләү турында боерык яки 3.9 пункты нигезендә әзерләнгән хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат.
3.8. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен тапшыру.
3.8.1. Опека һәм попечительлек секторы белгече, имзаланган боерыкны алгач, аны терки һәм 3 эш көне эчендә гариза бирүчегә тапшыра.
Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.7.1 подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 көн эчендә башкарыла.
Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.
3.9. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат тапшыру.
3.9.1 Опека һәм попечительлек секторы белгече боерык бирүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты әзерли.
Әзерләнгән баш тарту турында хат проектын Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә юллый.
Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар баш тарту өчен нигезләр ачыкланган көннән соң 5 көн эчендә башкарыла.
Процедуралар нәтиҗәсе: имзалауга юлланган баш тарту турында хат проекты.
3.9.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек секторы белгеченә кайтара.
Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 1 эш көне эчендә башкарыла.
Процедуралар нәтиҗәсе: имзаланган баш тарту турында хат.
3.9.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече баш тарту турында хатны аны имзалаган көннән соң 1 эш көне эчендә гариза бирүчегә юллый. Шул ук вакытта гариза бирүчегә карарны шикаять итү тәртибе аңлатыла.
Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.8.2. подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә башкарыла.
Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында гариза бирүчегә хәбәр итү.
3.9.4. Эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраксыз дип танылган гражданинга опекага алучы яки попечитель билгеләүдән баш тарту турында хат гариза бирүченең шәхсән кулына тапшырыла, нәтиҗәнең күчермәсе опекага алынучының шәхси эшенә беркетелә.

Гариза бирүченең опекага алучы (попечитель) була алмавы турында Нәтиҗә белән бергә опека һәм попечительлек бүлеге гариза бирүчегә барлык кабул итеп алынган документларны кире кайтара һәм шикаять итү тәртибе белән таныштыра. Әлеге документларның күчермәләре опека һәм попечительлек органында саклана.
Процедуралар нәтиҗәсе: опека һәм попечительлек секторы белгече эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраксыз гражданин өстеннән опекага алучы һәм попечитель билгеләүдән баш тарту турында нәтиҗә бирә.
Эшчәнлекнең максималь вакыты – 3 эш көне эчендә.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формасы

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларын үтәүне тикшерүне, карар кабул итүне һәм күпфункцияле үзәкнең (хезмәт күпфункцияле үзәк аркылы күрсәтелсә), опека һәм попечительлек бүлегенең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап бирүне үз эченә ала.
Административ процедураларны үтәүне контрольдә тоту формалары булып тора:
- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларының хокукый экспертизасын үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау;
- кабул итлегән тәртиптә делопроизводство алып баруны тикшерү;
- кабул ителгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү үткәрү процедураларына контроль тикшерү үткәрү.
Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерү үткәргән вакытта дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык сораулар каралырга мөмкин.
Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта һәм карар кабул иткән вакытта гамәлләрне башкаруны тикшерүне башкару максатында күпфункцияле үзәк, опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.
4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесе тарафыннан башкарыла.
4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затлар исемлеге күпфункцияле үзәкнең, опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.
Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.
4.4. Җаваплы башкаручы гариза бирүченең мөрәҗәгатен вакытында карамаган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезләнмәгән рәвештә баш тарткан өчен җавап бирә.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, аларның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелгән очракта), опека һәм попечительлек секторы хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Арча муниципаль районы башкарма комитетына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.
Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итәргә мөкин:
1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;
2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;
3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителгәндә;
4) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;
5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;
6) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;
7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;
8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү вакыты яки тәртибе бозылганда;
9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылганда, әгәр туктатылу нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса;

5.2. Шикаять почта аркылы язма рәвештә кәгазь битендә яки электрон формада җибәрелергә, шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәткән очракта шикаять күпфункцияле үзәк аркылы җибәрелә ала.
5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең документларны кабул итүдән баш тартуына яки киткән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять биргән очракта яки мондый төзәтүләрне башкаруның кабул ителгән вакыты бозылуга шикаять биргән очракта – аны теркәгән көннән соң 5 эш көне эчендә.
5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:
1) карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исемен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки муниципаль хезмәткәрнең исемен;
2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;
3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;
4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән риза булмавына дәлилләр.
5.5. Шикаятькә шикаятьтә тасвирланган вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре теркәлгән булырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документлар исемлеге бирелә.
5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәте күрсәтелүче зат, законлы вәкиле тарафыннан имзалана.
5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча опека һәм попечительлек органы җитәкчесе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:
1) шикаять канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;
2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.
5.8. Карар кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.
5.9. Шикаять тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелгән очракта Башкарма комитет җитәкчесе бозуларны бетерү максатында кабул ителергә тиеш булган чараларны билгели.
Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.
5.10. Гариза бирүчеләр Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең һәм күпфункцияле үзәк җитәкчесенең гамәлләренә (гамәл кылмавына) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять итәргә хокуклы.

Суд тарафыннан эшкә яраксыз яки
өлешчә эшкә яраклы дип танылган балигъ булган
зат өстеннән опека яки попечительлек билгеләү
һәм опекага алучы яки попечитель билгеләү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
1 Кушымта

(Бланк) Татарстан Республикасы
муниципаль берәмлеге
башкарма комитеты

**БОЕРЫК**

№ _____ от __________

**Эшкә яраксыз (өлешчә эшкә яраклы) зат өстеннән опека рәсмиләштерү турында**

_______________________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

_______________________________________________________________________________
(даими тору урыны адресы – өлкә, шәһәр, район, урам, йорт №, фатир №)

____________________________________________адресы буенча яшәүче _____________________

__________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туу көне)
__________________________________________________________ адресы буенча теркәлгән,

_________________________ ____________________ карары белән эшкә яраксыз (өлешчә эшкә яраклы)
(суд карары көне) (суд исеме)

дип танылган ______________________________________________________________өстеннән
(эшкә яраксыз гражданинның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туу көне)

аны опекага алучы (попечитель) итеп билгеләү турында гаризасын, тапшырылган документларын карап, РФ Гражданлык кодексының 29, 32 маддәләре, 37 маддәнең 1 пункты белән җитәкчелек итеп, мәҗбүр итәм:

1. ____________________________________________________не эшкә яраксыз
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
________________________________________ өстеннән опекага алучы (попечитель) итеп билгеләргә.
(эшкә яраксыз затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

2. Опекага алучыга (попечительгә) опекага алынган кешене карау, дәвалау, хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау буенча вазыйфаларны башкарырга.

3. Опекага алучыга (попечительгә) ел саен **1 февральдән дә соңга калмыйча** опека һәм попечительлек секторына опекага алынган затның милкен саклау, куллану һәм идарә итү турында үткән елга хисап бирергә.

Җитәкче ______________/ ______________________________
(имза) (фамилия, инициаллар)

Суд тарафыннан эшкә яраксыз яки өлешчә
эшкә яраклы дип танылган балигъ булган зат өстеннән
опека яки попечительлек билгеләү һәм опекага
алучы яки попечитель билгеләү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтү Административ регламентына
2 Кушымта

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты җитәкчесенә
________________________________
(Җитәкченең фамилиясе, инициаллары)
________________________________
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туу көне, тору урыны)
________________________________
________________________________
________________________________
________________________________
(өй телефоны, кәрәзле телефон)
________________________________
(паспорт мәгълүматлары)

**ГАРИЗА**

Мине ________________________________________________________________
(опекага алынучы затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туу көне, тору һәм теркәлү урыны)

____________________________________________________________ өстеннән опекага алучы,

попечитель (кирәклесенең астына сызарга) итеп билгеләвегезне сорыйм. Сәбәбе: ________________________

________________________________________________________________________.

Суд карары "_____" ____________ ________ ел.

Опекага алучының хокуклары һәм вазыйфалары миңа аңлатылды, опекага алучы вазыйфаларын башкара алмаган очракта бу турыда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты каршындагы опека һәм попечительлек секторына 10 көн эчендә хәбәр итәргә йөкләмә алам. Тору урыны үзгәргән очракта вакытында хәбәр итәргә йөкләмә алам.
Мине опекага алучы (попечитель) итеп билгеләгән очракта ел саен **1 февральдән дә соңга калмыйча** опека һәм попечительлек секторына опекага алынган затның милкен саклау, куллану һәм идарә итү турында үткән елга хисап бирергә үз өстемә йөкләмә алам.

Дата "_____" _____________ ________ ел. Имза ____________________

Мин,________________________________________________________________________,
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
"Шәхси мәгълүмат турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әлеге гаризада һәм тапшырылган документларда булган шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә һәм куллануга рөхсәт бирәм.

«____»_________20___ел. _________________/___________________
(имза) (Фамилия, инициаллар)

Теркәлде "__" _____________ ____ ел. № ____

________________________ ______________ _______________________________

(белгеч вазыйфасы) (имза) (имзаның тулы язылышы)

Суд тарафыннан эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы дип танылган балигъ булган зат өстеннән опека яки попечительлек билгеләү һәм опекага алучы яки попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
3 Кушымта

**Опка, попечительлек билгеләү өчен гаризалар исәбен алып бару, теркәү журналы**

| N | Теркәү датасы | Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, адресы | Суд карары реквизитлары (дата, суд исеме, үз көченә керү датасы) | Бирелгән документлар исеме | Торак шартларын тикшерү датасы. Опекага алу, попечительлек билгеләү (туктату) турында карар датасы һәм номеры | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

Суд тарафыннан эшкә яраксыз яки
өлешчә эшкә яраклы дип танылган балигъ булган

зат өстеннән опека яки попечительлек билгеләү
һәм опекага алучы яки попечитель билгеләү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
4 Кушымта

**Эшкә яраксыз, өлешчә эшкә яраклы затларның шәхси эшләрен исәпкә алу һәм теркәү журналы**

| N | Эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, адресы | Суд карары реквизитлары (дата, суд исеме, үз көченә керү датасы) | Опекага алучы, попечитель булырга теләүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | Опекага алу, попечительлек билгеләү (туктату) турында карар датасы һәм номеры | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Суд тарафыннан эшкә яраксыз яки өлешчә
эшкә яраклы дип танылган балигъ булган зат өстеннән
опека яки попечительлек билгеләү һәм опекага
алучы яки попечитель билгеләү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтү Административ регламентына
5 Кушымта

**Суд тарафыннан эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы дип танылган балигъ булган гражданин өстеннән опекага алучы яки попечитель булырга теләк белдергән гражданинның тормыш шартларын тикшерү акты**

Тикшерү датасы "__" _________________ 20__ ел.
Тикшерү үткәргән кешенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), вазыйфасы_______________
________________________________________________________
__________________________________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме
_____________________________________________________________нең тормыш шартлары тикшерелде;
(булган очракта), туу көне)
Шәхесне раслаучы документ: ______________________________________________________
__________________________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________________________
(кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)
Тору урыны _______________________________________________________________________
(теркәү белән расланган тору урыны адресы)
__________________________________________________________________________________________
Яшәү урыны__________________________________________________________________________
(чынлыкта тору урыны һәм тикшерү үткәрү урыны)
__________________________________________________________________________________________

Белеме ___________________________________________________________________________
Профессиональ эшчәнлек _________________________________________________________
__________________________________________________________________________________________
(адрес, биләгән вазыйфаны, эш телефонын күрсәтеп, эш урыны)
______________________________________________________ ____________________ яшәүче торак мәйдан
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта)

_____ кв. м тәшкил итә, __________________________ бүлмәдән тора, һәр бүлмәнең мәйданы: ___ кв.м, _____________ кв. м, ________ кв. м.
___этажда _______ этажлы йортта.
Йорт сыйфаты (кирпеч, панель, агач һ.б.; яхшы хәлдә, тузган, аварияле; бүлмәләр коры, якты, үтә торган, тәрәзәләр саны һ.б.) ____________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________________________
Йорт һәм торак мәйданының төзекләндерелеше (су үткәргеч, канализация, җылыту, газ, ванна, лифт, телефон һ.б.):
__________________________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________________________
Торак мәйданның санитар-гигиеник торышы (яхшы, канәгатьләнерлек, канәгатьләнерлек түгел)
__________________________________________________________________________________________
Торак мәйданда яши (тиешле тәртиптә теркәлгән һәм чынлап яши):

| Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта) | Туу елы | Эш урыны, яки уку урыны | Вазыйфасы | Туганлык мөнәсәбәтләре | Кайчаннан әлеге торак мәйданда яши |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Гражданинның гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәт ___________________________________
__________________________________________________________________________________________
(гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәт характеры, үзара аралашу үзенчәлекләре һ.б.)
_____________________________________________________________________

Гражданинның шәхси сыйфатлары (характер үзенчәлекләре, гомуми мәдәният һ.б.)

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
__________________________________________________________.
Балигъ булган затны гаиләгә алу өчен гражданинның сәбәпләре (туганы булмаса)
______________________________________________________________________________
___________________________________________________________
__________________________________________________________.
Тикшерүнең өстәмә мәгълүматы __________________________________
_________________________________________________________
_________________________________________________________.
Суд тарафыннан эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы дип танылган балигъ булган гражданинны опекага алырга (попечитель булырга) теләк белдергән гражданинның тормыш шартлары
_______________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

(Канәгатьләнерлек/канәгатьләнерлек түгел, конкрет шартларны күрсәтеп)

Тикшерү үткәргән затның имзасы ______________________________

___________________________ ____________ ___________________
(опека һәм попечительлек органы җитәкчесе) (имза) (фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

М.П.

Суд тарафыннан эшкә яраксыз яки өлешчә
эшкә яраклы дип танылган балигъ булган зат өстеннән
опека яки попечительлек билгеләү һәм
опекага алучы яки попечитель билгеләү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтү Административ регламентына
6 Кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү БЛОК-СХЕМАСЫ**

Суд тарафыннан эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы дип танылган балигъ булган затлар өстеннән опека (попечительлек) һәм опекага алучы (попечитель) билгеләү турында гражданнарга мәгълүмат һәм консультация бирү

//

Документлар һәм гариза кабул итү

//

Документларны тикшерү һәм аларны теркәү

// \\

| | |
|---|---|
| Дөүләт хезмәте күрсәтү яки күрсәтүдән баш тартуга нигезләр билгеләү | Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр билгеләү |
| // | \\ |
| Опека яки попечительлек билгеләү турында Боерык проекты әзерләү | Опека яки попечительлек билгеләүдән баш тарту турында нәтиҗә |
| // | \\ |
| Суд тарафыннан эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы дип танылган балигъ булган затлар өстеннән опека (попечительлек) һәм опекага алучы (попечитель) билгеләү турында боерык бирү | Суд тарафыннан эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраксыз дип танылган балигъ булган затлар өстеннән опека (попечительлек) һәм опекага алучы (попечитель) билгеләүдән баш тарту турында нәтиҗә бирү |

Суд тарафыннан эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә
яраклы дип танылган балигъ булган зат өстеннән
опека яки попечительлек билгеләү һәм опекага алучы
яки попечитель билгеләү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтү Административ регламентына
7 Кушымта

**Техник хатаны төзәтү турында гариза**

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ________________________________________________________(хата төре)
Язылган:_______________________________________________________
Дөрес мәгълүмат:_____________________________________________
Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документка түбәндәге үзгәрешләрне кертүегезне сорыйм.
Түбәндәге документларны терким:
1.
2.
Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итмәү турында карар кабул иткән очракта мондый карарны түбәндәге юл белән җибәрүегезне сорыйм:
Электрон документ җибәрү юлы белән E-mail адреска:_________________
Почта аша кәгазь вариантта расланган күчермә формасында ___________________________ адресы буенча.
Үземнең һәм мин вәкиле булып торган затның шәхси мәгълүматны эшкәртүгә (шәхси мәгълүматны җыю, системалаштыру, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), туктату, юкка чыгару, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматны эшкәртү өчен кирәк булган башка гамәлләр кылу), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, дәүләт хезмәте күрсәтү максатында алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан карар кабул итүне кертеп, ризалыгымны раслыйм.
Әлеге низедә раслыйм: гаризага кертелгән, минем һәм мин вәкиле булып торган затның шәхесенә кагылучы мәгълүматның, шулай ук минем тарафтан кертелгән түбәндәге мәгълүматның дөреслеген. Гаризага теркәлгән документлар (документ күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза тапшырган вакытка әлеге документлар гамәлдә һәм дөрес мәгълүматны үз эченә ала.
Түбәндәге телефон буенча миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәте сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашуга үземнең ризалыгымны бирәм: _______________________.

Дата_________________Имза_______________/________________________
Хезмәт билгеләре        Гариза керде:                    Дата:
Теркәү №
Гаризаны алган затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме һәм имзасы.

Суд тарафыннан эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә<br>яраклы дип танылган балигъ булган зат өстеннән<br>опека яки попечительлек билгеләү һәм опекага алучы<br>яки попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте<br>күрсәтү Административ регламентына<br>Кушымта (мәгълүмати)

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне агымдагы контрольдә тотучы җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-84366) 3-13-81 | Arsk-opeka@yandex.ru |
| Сектор белгече | (8-84366) 3-13-81 | Arsk-opeka@yandex.ru |

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-84366) 3-00-44 | Ispolkom.Arsk@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының
«__»_________, 2019 ел, №_____
Карарына
3 Кушымта

**Опекага алынган кеше мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү**
**Административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге регламент Арча муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Арча муниципаль районында яшәүче опекага алынган кеше мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – хезмәт күрсәтү) стандарты һәм тәртипләрен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар: опекага алынган кеше мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт алырга теләүче Россия Федерациясе гражданнары.

1.3. Дәүләт хезмәте ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен башкаручы – балигъ булмаган затның яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (алга таба – опека һәм попечительлек органы).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

1.3.2. Опека һәм попечительлек органы урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

Эш режимы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш.

Төшке аш вакыты – 12.00 – 13.00.

Эчкә үтү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне ачыклаучы документ буенча.

1.3.3. Опека һәм попечительлек органы телефоны: (84366)3–13–81.

1.3.4. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайты (алга таба – «Интернет» челтәре): http://www.arsk.tatarstan.ru.

1.3.5. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы бинасында урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аркылы;

2) «Интернет» челтәре аша:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында http://www.arsk.tatarstan.ru;

3) опека һәм попечительлек секторына шәхси мөрәҗәгать итеп;

4) күпфункцияле үзәктә (хезмәт күрсәтүне күпфункцияле үзәк аркылы алып булган очракта).

1.4. Хезмәт күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә башкарыла:

- Россия Федерациясе Конституциясе (алга таба – РФ Конституциясе) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 26.01.2009, №31, 4398 маддә);

- Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы (беренче бүлеге) 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гражданлык кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 05.12.1994, №32, 3301 маддә);

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 маддә);

- «Психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткән вакытта гражданнар хокуклары гарантияләре турында» 1992 елның 02 июлендәге 3185-1 номерлы Россия Федерациясе законы (алга таба – 3185-1 номерлы РФ Законы) («Россия Федерациясенең халык депутатлары Советы һәм Югары Советы ведомосте», 20.08.1992, №33, 1913 маддә);

- «Күчемсез милеккә хокук һәм аның белән килешүләрне дәүләт теркәве турында» 1997 елның 21 июлендәге 122-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба дәүләт теркәве турында ФЗ) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 28.07.1997, №30, 3594 маддә);

- «Шәхси мәгълүмат турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 152-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 31.07.2006, №31 (1 бүлек), 3451 маддә);

- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 28.04.2008, №17, 1755 маддә);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №43-44, 02.03.2004);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №60-61, 25.03.2008);

- «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 880 нче номерлы Карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары җыелмасы, 08.12.2010, №46, 2144 маддә);

- «Опека һәм попечительлек өлкәсендә җирле үзидарә органнарына бирелгән вәкаләтләр буенча типлаштырылган дәүләт хезмәтләре күрсәтү административ регламентларын раслау турында» 2011 елның 29 июлендәге 1046 нчы номерлы Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы әмере;

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 15 августындагы боерыгы белән расланган Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында Нигезләмәсе (алга таба – опека секторы турнда Нигезләмә).

1.5.Әлеге Регламентта түбәндәге термин һәм билгеләмәләр кулланыла:

- опекага алынган зат – аңа карата опека яки попечительлек билгеләнгән гражданин;

- тәрбиягә алу белән гомерлек карау килешүе – әлеге килешү нигезендә гражданин үзенең күчемсез милкен рента түләүче милкенә күчерә, ә соңгысы үз чиратында гражданинны һәм (яки) ул күрсәткән өченче затны тәрбиягә алу белән гомер буе карап торырга үзенә йөкләмә ала.

- «рента бирүче» – рента түләүче.

- административ регламент –Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралар һәм административ эшчәнлек вакытын һәм эзлеклелеген, структур бүлекчәләр һәм вазыйфаи затлар арасындагы хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хакимияте башкарма органнарының физик яки юридик затлар (алга таба – дәүләт хезмәте алучылар), башка дәүләт хезмәте һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгеләүче норматив хокукый документ;

- дәүләт хезмәте – дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән чикләрдә мөрәҗәгать итүче соравы буенча башкарыла торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарган вакытта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек;

- дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе $1^1$ бүлегендә каралган оешмалар яки аларның эшчеләре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта бозылган хокукларны яки законлы мәнфәгатьләрне кире кайтару яки саклау турында таләбе.

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яки муниципаль учреждениенең оештыру-хокукый формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирүче һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча, вәкаләтле оешма;

- «бер тәрәзә» принцибы – мөрәҗәгать итүче 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ маддәсендә күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү, ә дәүләт хезмәт күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар белән күпфункцияле үзәк тарафыннан мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актлар һәм хезмәттәшлек итү турында килешү нигезендә хезмәттәшлек алып бару принцибы.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбе исеме | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Хезмәт күрсәтү исеме | Опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт | РФ Гражданлык кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.2. Хезмәт күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты (опекага алынган кешенең яшәү урыны буенча) | 8-ТРЗ номерлы ТР Законы |
| 2.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Боерык формасында опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт яки хат формасында опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт бирүдән баш тарту | РФ Гражданлык кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.4. Хезмәт күрсәтү вакыты | Мөрәҗәгать итүчедән барлык кирәкле документларны алганнан соң 15 көн эчендә | |
| 2.5. Закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларның тулы исемлеге | 1. опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт бирү турында опекага алучы яки попечитель гаризасы (сәбәпләрен күрсәтергә);<br>2. опека яки попечительлек билгеләү турында һәм опекага алучы яки попечитель билгеләү турында яки опекага алучыны аныклау турында хокукый акт күчермәсе яки опекага алучы таныклыгы;<br>3. законлы көченә кергән гражданинны эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы дип тану турында суд органы карары күчермәсе;<br>4. опекага алынган затның торагына хокук билгеләүче документ күчермәсе (ордер, торак бинаны гражданның милкенә күчерү турында килешү, сату-алу килешүе һ.б.);<br>5. гражданинның аның белән гомерлек рента (тәрбиягә алу белән гомерлек карау) килешүе төзү турында гаризасы һәм аның гаилә әгъзаларының рента килешүе төзүгә гаризасы;<br>6. рента түләүченең (алга таба – «рента бирүче») паспорт күчермәсе;<br>7. «рента бирүче»нең керемнәре турында белешмә һәм «рента бирүче»нең гаилә әгъзаларының гомуми керемнәре турында белешмә;<br>8. «рента бирүче»нең эш урыныннан белешмә һәм характеристика, шулай ук «рента бирүче»нең барлык гаилә әгъзаларының эш урыннарыннан белешмәләр;<br>9. гомерлек рента килешүе буенча акча күчерү өчен опекага алынган зат исеменә ачылган саклык кенәгәсе. | РФ Гражданлык кодексы;<br>РФ Торак кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар | Опекага алынган затның (эшкә яраксыз затның) милке турында Бердәм дәүләт хокукый реестрыннан (Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография Федераль хезмәте идарәсе) алынган мәгълүмат; | |

| | | |
|---|---|---|
| карамагында булган документларның тулы исемлеге | Опекага алынучы затның теркәлү урыныннан йорт (фатир) кенәгәсеннән өземтә. | |
| 2.7. Норматив хокукый актлар белән каралган очракларда хезмәт күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган һәм хезмәт күрсәтә торган башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла торган дәүләт хакимияте һәм аның структур бүлекчәләре исемлеге | Килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Гражданинның тору урыны буенча мөрәҗәгать итмәве | 48-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>- гариза бирүче тарафыннан әлеге Административ регламентның 2.5 пукнтында күрсәтелгән документларны тапшырмавы;<br>- опекага алынучы затның гражданлык һәм милек хокукларын кысу | РФ Конституциясе;<br>РФ Гражданлык кодексы;<br>РФ Торак кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>210-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>1046 номерлы ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы әмере |
| 2.10. Хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә. | |
| 2.11. Әлеге түләүне исәпләү турында мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр таләп ителми | |
| 2.12. Хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алган вакытта чиратта көтүнең максималь вакыты | Аерым категория кешеләр өчен чират билгеләнмәгән. Көтеп утыруның (хезмәт күрсәтүнең) максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты | Гариза кергән көнне | |
| 2.14. Хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр | 1. Гариза түбәндәге адрес буенча тапшырыла:<br>Арча шәһәре, Советлар мәйданы урамы, 12 йорт, опека һәм попечительлек секторы.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазланган бинада башкарыла;<br>3. Бинада гаризалар кабул итү өчен сектор белгеченең эш урыны хезмәтне тулысынча күрсәтергә мөмкинлек бирүче электрон белешмә-хокукый системалар, оргтехника белән тәэмин ителгән шәхси компьютер белән җиһазландырыла.<br>4. Документлар тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазлана һәм документлар тутыру үрнәкләре белән тәэмин ителә.<br>5. Инвалидларга хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыкларсыз керү тәэмин | |

| | | |
|---|---|---|
| | ителә, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм чыгу юлларына, дәүләт хезмәте күрсәтү урынына барып җитү максатында объект буйлап мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итү тәэмин ителә.<br>6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны исәпкә алып, урнаштырыла. | |
| 2.15. Хезмәт күрсәтүнең мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Хезмәт күрсәтүнең аңлаешлылыгы күрсәткечләре:<br>- бинаның җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы;<br>- гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү өчен бина булуы;<br>- мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә башкарма комитетның мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү бердәм порталында хезмәт күрсәтү тәртибе, ысуллары, вакыты турында тулы мәгълүмат булу.<br>Хезмәт күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре:<br>-хезмәт күрсәтү вакытын бозмау;<br>- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирмәү;<br>- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә игътибарсызлык күрсәтүенә шикаять бирәү.<br>Хезмәт күпфункцияле үзәктә күрсәтелми. | |
| 2.16. Хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Хезмәт күрсәтү тәртибе турында консультацияне башкарма комитетның Интернет-кабул итү бүлмәсе аркылы алырга мөмкин.<br>Хезмәт электрон формада күрсәтелми | |

## 3. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкару составы, эзлеклелеге һәм вакыты, аларны башкару тәртибенә таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау:

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- опекага алучыларга һәм попечительләргә опекага алынган кешенең гражданлык һәм милек хокукларын яклау мәсьләләре буенча мәгълүмат һәм консультация бирү; опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзү мәсьәләләре буенча мәгълүмат һәм консультация бирү;
- гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;
- кабул итү яки баш тарту нигезләрен билгеләү өчен тапшырылган документларның әлеге Административ регламент таләпләренә туры килүен тикшерү;
- Бердәм дәүләт хокукый реестрыннан (Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсе) опекага алынган кешенең милке турында мәгълүмат соратып алу;
- дәүләт хезмәте күрсәтү яки күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема әлеге Административ регламентка 3 кушымтада бирелә.

3.2. Консультация бирү

Мәгълүмат һәм консультация бирү буенча процедуралар кысаларында гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибен җайлаучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;
- мөрәҗәгать итүчеләрне, шулай ук аларның законлы вәкилләрен, опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән таныштыра;
- опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеген бирә.

Консультация гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Процедура нәтиҗәсе: документлар составы һәм хезмәт күрсәтү буенча башка сораулар буенча консультация.

Консультация һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедуралар башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

Гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирүче белгеч, шәхси мәгълүматларны исәпкә алып, консультациянең грамоталыгы, тулылыгы һәм ачыклыгы өчен шәхси җавап бирә.

3.3. Гариза бирүче, 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән үзе гариза тапшыра.

Гаризалар һәм документлар кабул итү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- гражданинның шәхесен, опекага алынган кешенең тору урынын билгели;
- опекага алучы (попечитель) һәм рента түләүче булырга теләгән гражданин тапшырган кирәкле документларның барлыгын тикшерә. Кирәкле документлар булмаган очракта җитмәгән документларны тапшырырга тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларны кабул итүне таләп итсә, документлар кабул ителә.
- документлар пакеты формалаштыра.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән документлар.

Гамәлләрне башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

Документларны кабул итеп алу өчен җаваплы белгеч консультациянең грамоталыгы, тулылыгы һәм ачыклыгы өчен шәхси җавап бирә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта опека һәм попечительлек, күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелсә) белгече гариза бирүчегә гариза һәм документлар алу, теркәлү номеры турында хәбәр итә, аннан соң әлеге Регламентның 3.3.1. подпунктында күрсәтелгән процедуралар башкарыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән вакыттан соң 1 көн эчендә 15 минут вакыт аралыгында башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язмасы.

Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч, конфиденциаль мәгълүматларны исәпкә алып, документларны кабул итү буенча процедураларны башкаруның дөреслеге өчен шәхси җавап бирә.

3.4 Опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүче тапшырган документлардагы мәгълүматны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергәннән соң 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәт бирү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратып алу әзерләү һәм җибәрү.

3.5.1 Опека һәм попечительлек белгече (гариза бирүче белән килештереп) ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү системасы аркылы әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны җибәрү турында электрон формада соратып алу юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән көннән 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында юлланган соратып алу.

3.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы опека һәм попечительлек секторы органнары соратуы буенча автоматлаштырылган режимда башкарыла:

- соратып алуны эшкәртү һәм соратылган мәгълүматны эзләү;

- ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү аркылы соратып алынган мәгълүматны формалаштыру, соратып алынган мәгълүмат булмаган очракта, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, соратып алынган мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар опека һәм попечительлек органнарына соратып алу кергән вакыттан 5 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: соратып алуга җавап яки әлеге Регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.6.1. Тапшырылган документлар нигезендә опека һәм попечительлек секторы белгече опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзү турында боерык проекты әзерли һәм аны килештерү һәм раслату өчен опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә җибәрә яки тиешле аныклау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт бирү турында боерык яки 3.8 пункты нигезендә әзерләнгән хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.7. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен тапшыру.

3.7.1. Опека һәм попечительлек секторы белгече, имзаланган боерыкны алгач, аны терки һәм гариза бирүчегә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.5.1 подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.8. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат тапшыру.

3.8.1 Опека һәм попечительлек секторы белгече боерык бирүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты әзерли.

Әзерләнгән баш тарту турында хат проектын Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар баш тарту өчен нигезләр ачыкланган көннән соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзалауга юлланган баш тарту турында хат проекты.

3.8.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек секторы белгеченә кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзаланган баш тарту турында хат.

3.8.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече баш тарту турында хатны аны имзалаган көннән соң 1 эш көне эчендә гариза бирүчегә юллый. Шул ук вакытта гариза бирүчегә карарны шикаять итү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.7.2. подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формасы

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларын үтәүне тикшерүне, карар кабул итүне һәм күпфункцияле үзәкнең (хезмәт күпфункцияле үзәк аркылы күрсәтелсә), опека һәм попечительлек бүлегенең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап бирүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларының хокукый экспертизасын үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау;

- кабул итлегән тәртиптә делопроизводство алып баруны тикшерү;

- кабул ителгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү үткәрү процедураларына контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерү үткәргән вакытта дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык сораулар каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта һәм карар кабул иткән вакытта гамәлләрне башкаруны тикшерүне башкару максатында күпфункцияле үзәк, опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затлар исемлеге күпфункцияле үзәкнең, опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы гариза бирүченең мөрәҗәгатен вакытында карамаган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезләнмәгән рәвештә баш тарткан өчен җавап бирә.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, аларның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелгән очракта), опека һәм попечительлек секторы хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Арча муниципаль районы башкарма комитетына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итәргә мөкин:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган документлар, мәгълүмат яки гамәл кылу таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү вакыты яки тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылганда, әгәр туктатылу нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта мөрәҗәгать итүчедән беренче тапкыр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документлар тапшырган вакытта булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү.

5.2. Шикаять почта аркылы язма рәвештә кәгазь битендә яки электрон формада җибәрелергә, шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәткән очракта шикаять күпфункцияле үзәк аркылы җибәрелә ала.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең документларны кабул итүдән баш тартуына яки киткән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять биргән очракта яки мондый төзәтүләрне башкаруның кабул ителгән вакыты бозылуга шикаять биргән очракта – аны теркәгән көннән соң 5 эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исемен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки муниципаль хезмәткәрнең исемен;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән риза булмавына дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә тасвирланган вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре теркәлгән булырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документлар исемлеге бирелә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәте күрсәтелүче зат тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу

Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта Башкарма комитет тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта ачыкланган бозуларны кичекмәстән бетерү максатында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле гамәлләр турында әйтелә.

5.9. Әгәр шикаять канәгатьләндерелмәсә, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул итлегән карарга нигезләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында аңлатма бирелә.

5.10. Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Опекага алынган кеше мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
1 Кушымта

**(форма)**

_____________районы Башкарма комитеты җитәкчесе
___________________________________________________
(фамилиясе, инициаллары)
____________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең исеме, фамилиясе, әтисенең исеме, туу көне, тору урыны)
________________________________
________________________________
(йорт телефоны, кәрәзле телефон)
__________________________________
(паспорт мәгълүматлары)

ГАРИЗА

Опекага алынган зат ______________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
мәнфәгатьләрендә ____________________________________адресы буенча урнашкан
_______________________________________________________, гомуми мәйданы __________ кв.м, торак мәйданы
(приватизацияләнгән, милеккә алынган, кооператив, дәүләт)

_______ кв.м, бүлмәләр саны _______ булган фатирга, торак йортка гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт бирүегезне сорыйм.

Фатир милекчеләре (фамилияләре, исемнәре, әтиләренең исемнәре, өлешләрен күрсәтергә)
____________________________________________________________________________________,
Шул исәптән эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраксыз__________________________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, өлешен күрсәтергә)
Милек һәм торак хокуклары кысылмый.
Рента килешүен ТР буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсендә теркәгәннән соң ике атна эчендә опека һәм попечительлек бүлегенә рента килешүе күчермәсен тапшырырга үземә йөкләмә алам.
Минем шәхси мәгълүматлар белән эшләргә рөхсәт бирәм.

_____________________ _______________________
(дата) (имза)

Опекага алынган кеше мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
2 Кушымта

**Техник хатаны төзәтү турында гариза**

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ________________________________________________________(хата төре)

Язылган:_______________________________________________________

Дөрес мәгълүмат:____________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документка түбәндәге үзгәрешләрне кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итмәү турында карар кабул иткән очракта мондый карарны түбәндәге юл белән җибәрүегезне сорыйм:

Электрон документ җибәрү юлы белән E-mail адреска:_________________

Почта аша кәгазь вариантта расланган күчермә формасында __________________________ адресы буенча.

Үземнең һәм мин вәкиле булып торган затның шәхси мәгълүматны эшкәртүгә (шәхси мәгълүматны җыю, системалаштыру, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), туктату, юкка чыгару, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматны эшкәртү өчен кирәк булган башка гамәлләр кылу), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, дәүләт хезмәте күрсәтү максатында алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан карар кабул итүне кертеп, ризалыгымны раслыйм.

Әлеге низедә раслыйм: гаризага кертелгән, минем һәм мин вәкиле булып торган затның шәхесенә кагылучы мәгълүматның, шулай ук минем тарафтан кертелгән түбәндәге мәгълүматның дөреслеген. Гаризага теркәлгән документлар (документ күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза тапшырган вакытка әлеге документлар гамәлдә һәм дөрес мәгълүматны үз эченә ала.

Түбәндәге телефон буенча миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәте сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашуга үземнең ризалыгымны бирәм: _______________________.

Дата_________________Имза_______________/________________________

Хезмәт билгеләре Гариза керде: Дата:

Теркәү №

Гаризаны алган затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме һәм имзасы.

Опекага алынган кеше мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
3 Кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү БЛОК-СХЕМАСЫ**

Опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзү мәсьәләләре буенча мәгълүмат һәм консультация бирү

//

Гариза һәм документлар кабул итү

//

Тапшырылган документларның дөреслеген тикшерү

//    \\

Нигезләр булмаган очракта опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт бирү турында боерык әзерли

Опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт бирүдән баш тарту турында хат әзерләү

//    \\

Опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт бирү турында Боерык бирү

Опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүдән баш тарту кәгазе бирү

Опекага алынган кеше мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
Кушымта (мәгълүмати)

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне агымдагы контрольдә тотучы җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |
| Сектор белгече | (8-884366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-84366) 3-00-44 | Ispolkom.Arsk@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының
«__»_________, 2019 ел, №_____
Карарына
4 Кушымта

**Опекага алынган кеше мәнфәгатьләрендә опекага алучыга торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү**
**Административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге регламент Арча муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Арча муниципаль районында яшәүче опекага алынган кеше мәнфәгатьләрендә опекага алучыга торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – хезмәт күрсәтү) стандарты һәм тәртипләрен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар: опекага алынган кеше мәнфәгатьләрендә опекага алучыга торакны приватизацияләүгә рөхсәт алырга теләүче Россия Федерациясе гражданнары.

1.3. Дәүләт хезмәте ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен башкаручы – балигъ булмаган затның яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (алга таба – опека һәм попечительлек органы).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

1.3.2. Опека һәм попечительлек органы урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

Эш режимы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш.

Төшке аш вакыты – 12.00 – 13.00.

Эчкә үтү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне аныклаучы документ буенча.

1.3.3. Опека һәм попечительлек органы телефоны: (84366)3–13–81.

1.3.4. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайты (алга таба – «Интернет» челтәре): http://www.arsk.tatarstan.ru.

1.3.5. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы бинасында урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аркылы;

2) «Интернет» челтәре аша:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында http://www.arsk.tatarstan.ru;

3) опека һәм попечительлек секторына шәхси мөрәҗәгать итеп;

4) күпфункцияле үзәктә (хезмәт күрсәтүне күпфункцияле үзәк аркылы алып булган очракта).

1.4. Хезмәт күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә башкарыла:

- Россия Федерациясе Конституциясе (алга таба – РФ Конституциясе) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 26.01.2009, №4, 445 маддә);

- Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы (беренче бүлеге) 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гражданлык кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 04.08.2014, №31, 4398 маддә);

- Россия Федерациясе Торак кодексы 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы (алга таба РФ Торак кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 03.01.2005, №1, (1 бүлек), 14 маддә);

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 маддә);

- «Күчемсез милеккә хокукларны дәүләт теркәве һәм аның белән бәйле килешүләр башкару турында» 1997 елның 21 июлендәге 122-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – дәүләт теркәве турында Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 28.07.1997, №30, 3594 маддә);

- «Россия Федерациясендә торак фондын приватизацияләү турында» 1991 елның 04 июлендәге 1541-I номерлы Россия Федерациясе законы (алга таба – 1541-I номерлы Закон) («РСФСРның Халык депутатлары Съезды һәм Югары Советы ведомосте», 11.07.1992, №28, 959 маддә);

- «Психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткән вакытта гражданнар хокуклары гарантияләре турында» 1992 елның 02 июлендәге 3185-1 номерлы Россия Федерациясе законы (алга таба – 3185-1 номерлы РФ Законы) («Россия Федерациясенең халык депутатлары Советы һәм Югары Советы ведомосте», 20.08.1992, №33, 1913 маддә);

- «Шәхси мәгълүмат турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 152-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 31.07.2006, №31 (1 бүлек), 3451 маддә);

- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 28.04.2008, №17, 1755 маддә);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №43-44, 02.03.2004);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №60-61, 25.03.2008);

- «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 880 нче номерлы Карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары җыелмасы, 08.12.2010, №46, 2144 маддә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 15 августындагы боерыгы белән расланган Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында Нигезләмәсе (алга таба – опека секторы турнда Нигезләмә).

1.5.Әлеге Регламентта түбәндәге термин һәм билгеләмәләр кулланыла:

- опека – суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган гражданнарның төзелеш формасы, опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (опекуннар) аларның законлы вәкилләре булып санала һәм алар исеменнән һәм алар мәнфәгате буенча юридик әһәмияткә ия булган гамәлләр башкара ала;

- опекага алынган зат – аңа карата опека яки попечительлек билгеләнгән гражданин (эшкә яраксыз яки өлешчә эшкт яраксыз гражданин);

- тәрбиягә алу белән гомерлек карау килешүе – әлеге килешү нигезендә гражданин үзенең күчемсез милкен рента түләүче милкенә күчерә, ә соңгысы үз чиратында гражданинны һәм (яки) ул күрсәткән өченче затны тәрбиягә алу белән гомер буе карап торырга үзенә йөкләмә ала.

- административ регламент –Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралар һәм административ эшчәнлек вакытын һәм эзлеклелеген, структур бүлекчәләр һәм вазыйфаи затлар арасындагы хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хакимияте башкарма органнарының физик яки юридик затлар (алга таба – дәүләт хезмәте алучылар), башка дәүләт хезмәте һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгеләүче норматив хокукый документ;

- дәүләт хезмәте – дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән чикләрдә мөрәҗәгать итүче соравы буенча башкарыла торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарган вакытта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек;

- дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе $1^1$ бүлегендә каралган оешмалар яки аларның эшчеләре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта бозылган хокукларны яки законлы мәнфәгатьләрне кире кайтару яки саклау турында таләбе.

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яки муниципаль учреждениенең оештыру-хокукый формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирүче һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча, вәкаләтле оешма;

- «бер тәрәзә» принцибы – мөрәҗәгать итүче 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ маддәсендә күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү, ә дәүләт хезмәт күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар белән күпфункцияле үзәк тарафыннан мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актлар һәм хезмәттәшлек итү турында килешү нигезендә хезмәттәшлек алып бару принцибы.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбе исеме | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Хезмәт күрсәтү исеме | Опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә опекага алучыга торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирү | РФ Гражданлык кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>1541-I номерлы Федераль закон;<br>122-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.2. Хезмәт күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты (опекага алынган кешенең яшәү урыны буенча) | Устав;<br>7-ТРЗ номерлы ТР Законы |
| 2.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Балигъ булган эшкә яраксыз зат мәнфәгатьләрендә опекага алучыга торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирү турында боерык яки опекага алынган зат катнашыннан башка торакны приватизацияләү турында боерык яки торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирүдән баш тарту | РФ Гражданлык кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.4. Хезмәт күрсәтү вакыты | Мөрәҗәгать итүчедән барлык кирәкле документларны алганнан соң 15 көн эчендә | 927 нче номерлы Карар |
| 2.5. Закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларның тулы исемлеге | 1. опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирү турында опекага алучының гаризасы;<br>2. эшкә яраксыз затка карата опекага алучы вазыйфаларын башкаручы, әлеге зат торган сәламәтлек саклау дәвалау учреждениесе администрациясенең опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирү турында гаризасы;<br>3. опека билгеләү һәм опекага алучыны билгеләү турында хокукый акт күчермәсе (карар, боерык һ.б.);<br>4. законлы көченә кергән гражданинны эшкә яраксыз дип тану турында суд органы карары күчермәсе;<br>5. опекага алынган затның паспорт күчермәсе;<br>6. приватизацияләнә торган фатирга ордер яки социаль найм килешүе күчермәсе;<br>7. эшкә яраксыз зат милекчесе булган торак бинага хокук билгеләүче документ күчермәсе (опекага алынган зат катнашыннан башка приватизацияләгән очракта). | РФ Гражданлык кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>1541-I номерлы Федераль закон |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган документларның тулы исемлеге | Опекага алынган затның (эшкә яраксыз затның) милке турында Бердәм дәүләт хокукый реестрыннан (Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография Федераль хезмәте идарәсе) алынган мәгълүмат;<br>Опекага алынучы затның теркәлү урыныннан йорт (фатир) кенәгәсеннән өземтә. | |
| 2.7. Норматив хокукый актлар белән каралган очракларда хезмәт күрсәтү өчен килештерү таләп | Килештерү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| итеlә торган һәм хезмәт күрсәтә торган башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла торган дәүләт хакимияте һәм аның структур бүлекчәләре исемлеге | | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Гражданинның тору урыны буенча мөрәҗәгать итмәве | |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>- гариза бирүче тарафыннан әлеге Административ регламентның 2.5 пунутында күрсәтелгән документларны тапшырмавы;<br>- опекага алынучы затның гражданлык һәм милек хокукларын кысу | |
| 2.10. Хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә. | |
| 2.11. Әлеге түләүне исәпләү турында мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр таләп ителми | |
| 2.12. Хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алган вакытта чиратта көтүнең максималь вакыты | Аерым категория кешеләр өчен чират билгеләнмәгән. Көтеп утыруның (хезмәт күрсәтүнең) максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты | Гариза кергән көнне | |
| 2.14. Хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр | 1. Гариза түбәндәге адрес буенча тапшырыла:<br>Арча шәһәре, Советлар мәйданы урамы, 12 йорт, опека һәм попечительлек секторы.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазланган бинада башкарыла;<br>3. Бинада гаризалар кабул итү өчен сектор белгеченең эш урыны хезмәтне тулысынча күрсәтергә мөмкинлек бирүче электрон белешмә-хокукый системалар, оргтехника белән тәэмин ителгән шәхси компьютер белән җиһазландырыла.<br>4. Документлар тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазлана һәм документлар тутыру үрнәкләре белән тәэмин ителә.<br>5. Инвалидларга хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыкларсыз керү тәэмин ителә, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм чыгу юлларына, дәүләт хезмәте күрсәтү урынына барып җитү максатында объект буйлап мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итү тәэмин ителә.<br>6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны исәпкә алып, урнаштырыла. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Хезмәт күрсәтүнең мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Хезмәт күрсәтүнең аңлаешлылыгы күрсәткечләре:<br>- бинаның җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы;<br>- гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү өчен бина булуы;<br>- мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә башкарма комитетның мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү бердәм порталында хезмәт күрсәтү тәртибе, ысуллары, вакыты турында тулы мәгълүмат булу.<br>Хезмәт күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре:<br>- хезмәт күрсәтү вакытын бозу;<br>- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирү;<br>- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә игътибарсызлык күрсәтүенә шикаять бирү.<br>Хезмәт күпфункцияле үзәктә күрсәтелми. | |
| 2.16. Хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Хезмәт электрон формада күрсәтелми | |

## 3. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкару составы, эзлеклелеге һәм вакыты, аларны башкару тәртибенә таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау:

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- опекага алучыларга һәм попечительләргә опекага алынган кеше мәнфәгатьләрендә торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирү мәсьәләләре буенча мәгълүмт һәм консультация бирү; опекага алынган зат элегрәк торакны приватизацияләү хокукыннан файдаланган булса, опекага алынган зат катнашыннан башка опекага алучыларны опекага алынган зат катнашынна башка торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирү мәсьәләләре буенча мәгълүмат һәм консультация бирү;

- гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

- кабул итү яки баш тарту нигезләрен билгеләү өчен тапшырылган документларның әлеге Административ регламент таләпләренә туры килүен тикшерү;

- дәүләт хезмәте күрсәтү яки күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема әлеге Административ регламентка 1 Кушымтада бирелә.

3.2. Консультация бирү

Мәгълүмат һәм консультация бирү буенча процедуралар кысаларында гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибен җайлаучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;

- опекага алынган затларның законлы вәкилләрен опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән таныштыра;

- опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеген бирә.

Консультация гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Процедура нәтиҗәсе: документлар составы һәм хезмәт күрсәтү буенча башка сораулар буенча консультация.

Консультация һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедуралар башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

Гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирүче белгеч, шәхси мәгълүматларны исәпкә алып, консультациянең грамоталыгы, тулылыгы һәм ачыклыгы өчен шәхси җавап бирә.

3.3. Гариза бирүче, 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән үзе гариза тапшыра.

Гаризалар һәм документлар кабул итү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- гражданинның шәхесен, опекага алынган кешенең тору урынын билгели;

- опекага алучы (попечитель) һәм рента түләүче булырга теләгән гражданин тапшырган кирәкле документларның барлыгын тикшерә. Кирәкле документлар булмаган очракта җитмәгән документларны тапшырырга тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларны кабул итүне таләп итсә, документлар кабул ителә.

- документлар пакеты формалаштыра.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән документлар.

Гамәлләрне башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

Документларны кабул итеп алу өчен җаваплы белгеч консультациянең грамоталыгы, тулылыгы һәм ачыклыгы өчен шәхси җавап бирә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта опека һәм попечительлек, күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелсә) белгече гариза бирүчегә гариза һәм документлар алу, теркәлү номеры турында хәбәр итә, аннан соң әлеге Регламентның 3.3.1. подпунктында күрсәтелгән процедуралар башкарыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән вакыттан соң 1 көн эчендә 15 минут вакыт аралыгында башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язмасы.

Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч, конфиденциаль мәгълүматларны исәпкә алып, документларны кабул итү буенча процедураларны башкаруның дөреслеге өчен шәхси җавап бирә.

3.4 Опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүче тапшырган документлардагы мәгълүматны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергәннән соң 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәт бирү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратып алу әзерләү һәм җибәрү.

3.5.1 Опека һәм попечительлек белгече (гариза бирүче белән килештереп) ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү системасы аркылы әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны җибәрү турында электрон формада соратып алу юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән көннән 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында юлланган соратып алу.

3.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы опека һәм попечительлек секторы органнары соратуы буенча автоматлаштырылган режимда башкарыла:

- соратып алуны эшкәртү һәм соратылган мәгълүматны эзләү;

- ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү аркылы соратып алынган мәгълүматны формалаштыру, соратып алынган мәгълүмат булмаган очракта, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, соратып алынган мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар опека һәм попечительлек органнарына соратып алу кергән вакыттан 5 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: соратып алуга җавап яки әлеге Регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.6.1. Тапшырылган документлар нигезендә опека һәм попечительлек секторы белгече опекага алынган зат мәнфәгатьләләрендә торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирү турында боерык проекты әзерли һәм аны килештерү һәм раслату өчен опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә җибәрә яки тиешле аныклау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирү турында боерык яки 3.8 пункты нигезендә әзерләнгән хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.7. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен тапшыру.

3.7.1. Опека һәм попечительлек секторы белгече, имзаланган боерыкны алгач, аны терки һәм гариза бирүчегә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.5.1 подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.8. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат тапшыру.

3.8.1 Опека һәм попечительлек секторы белгече боерык бирүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты әзерли.

Әзерләнгән баш тарту турында хат проектын Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар баш тарту өчен нигезләр ачыкланган көннән соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзалауга юлланган баш тарту турында хат проекты.

3.8.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек секторы белгеченә кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзаланган баш тарту турында хат.

3.8.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече баш тарту турында хатны аны имзалаган көннән соң 1 эш көне эчендә гариза бирүчегә юллый. Шул ук вакытта гариза бирүчегә карарны шикаять итү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.8.2. подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формасы

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларын үтәүне тикшерүне, карар кабул итүне һәм күпфункцияле үзәкнең (хезмәт күпфункцияле үзәк аркылы күрсәтелсә), опека һәм попечительлек бүлегенең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап бирүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларының хокукый экспертизасын үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау;

- кабул итлегән тәртиптә делопроизводство алып баруны тикшерү;

- кабул ителгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү үткәрү процедураларына контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерү үткәргән вакытта дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык сораулар каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта һәм карар кабул иткән вакытта гамәлләрне башкаруны тикшерүне башкару максатында күпфункцияле үзәк, опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затлар исемлеге күпфункцияле үзәкнең, опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы гариза бирүченең мөрәҗәгатен вакытында карамаган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезләнмәгән рәвештә баш тарткан өчен җавап бирә.

**5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, аларның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү**

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелгән очракта), опека һәм попечительлек секторы хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Арча муниципаль районы башкарма комитетына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итәргә мөкин:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган документлар, мәгълүмат яки гамәл кылу таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү вакыты яки тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылганда, әгәр туктатылу нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта мөрәҗәгать итүчедән беренче тапкыр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документлар тапшырган вакытта булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү.

5.2. Шикаять почта аркылы язма рәвештә кәгазь битендә яки электрон формада җибәрелергә, шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәткән очракта шикаять күпфункцияле үзәк аркылы җибәрелә ала.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең документларны кабул итүдән баш тартуына яки киткән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять биргән очракта яки мондый төзәтүләрне башкаруның кабул ителгән вакыты бозылуга шикаять биргән очракта – аны теркәгән көннән соң 5 эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исемен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки муниципаль хезмәткәрнең исемен;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән риза булмавына дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә тасвирланган вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре теркәлгән булырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документлар исемлеге бирелә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәте күрсәтелүче зат тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта Башкарма комитет тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта ачыкланган бозуларны кичекмәстән бетерү максатында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле гамәлләр турында әйтелә.

5.9. Әгәр шикаять канәгатьләндерелмәсә, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул итлегән карарга нигезләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында аңлатма бирелә.

5.10. Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Опекага алынган кеше мәнфәгатьләрендә опекага алучыга торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
1 Кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү БЛОК-СХЕМАСЫ**

Опекага алынган затлар мәнфәгатьләрен исәпкә алып, торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирү мәсьәләләре буенча гражданнарга мәгълүмат һәм консультация бирү

//

Тапшырылган документларны кабул итү

//

Документларга тикшерү үткәрү

//

Дәүләт хезмәте күрсәтү яки күрсәтүдән баш тарту нигезләрен билгеләү

// // \\

Опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирү турында карар әзерләү

//

Опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә торакны приватизацияләүгә карар бирү

Опекага алынган зат катнашыннан башка торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирү турында карар әзерләү

//

Опекага алынган зат катнашыннан башка торакны приватизацияләүгә карар бирү

Торакны приватизацияләүдән баш тарту турында хат әзерләү

\\

Торакны приватизацияләүдән баш тарту турында хат бирү

Опекага алынган кеше мәнфәгатьләрендә опекага алучыга торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
2 Кушымта

**Техник хатаны төзәтү турында гариза**

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ______________________________________________________________(хата төре)

Язылган:_____________________________________________________________

Дөрес мәгълүмат:_______________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документка түбәндәге үзгәрешләрне кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итмәү турында карар кабул иткән очракта мондый карарны түбәндәге юл белән җибәрүегезне сорыйм:

Электрон документ җибәрү юлы белән E-mail адреска:___________________

Почта аша кәгазь вариантта расланган күчермә формасында _____________________________ адресы буенча.

Үземнең һәм мин вәкиле булып торган затның шәхси мәгълүматны эшкәртүгә (шәхси мәгълүматны җыю, системалаштыру, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), туктату, юкка чыгару, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматны эшкәртү өчен кирәк булган башка гамәлләр кылу), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, дәүләт хезмәте күрсәтү максатында алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан карар кабул итүне кертеп, ризалыгымны раслыйм.

Әлеге низедә раслыйм: гаризага кертелгән, минем һәм мин вәкиле булып торган затның шәхесенә кагылучы мәгълүматның, шулай ук минем тарафтан кертелгән түбәндәге мәгълүматның дөреслеген. Гаризага теркәлгән документлар (документ күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза тапшырган вакытка әлеге документлар гамәлдә һәм дөрес мәгълүматны үз эченә ала.

Түбәндәге телефон буенча миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәте сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашуга үземнең ризалыгымны бирәм: ________________________.

Дата___________________Имза_________________/__________________________

Хезмәт билгеләре Гариза керде: Дата:

Теркәү №

Гаризаны алган затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме һәм имзасы.

Опекага алынган кеше мәнфәгатьләрендә опекага алучыга торакны приватизацияләүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
Кушымта (мәгълүмати)

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне агымдагы контрольдә тотучы җаваплы вазыйфаи затларның**
**РЕКВИЗИТЛАРЫ**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |
| Сектор белгече | (8-884366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-84366) 3-00-44 | Ispolkom.Arsk@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының
«__»_________, 2019 ел, №_____
Карарына
5 Кушымта

**Опекага алучыга опекага алынган кешенеке булган торакны наймга бирүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү**
**Административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге регламент Арча муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Арча муниципаль районында яшәүче опекага алучыга опекага алынган кешенеке булган торакны наймга бирүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – хезмәт күрсәтү) стандарты һәм тәртипләрен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар: опекага алучыга опекага алынган кешенеке булган торакны наймга бирүгә рөхсәт алырга теләүче Россия Федерациясе гражданнары.

1.3. Дәүләт хезмәте ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен башкаручы – балигъ булмаган затның яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (алга таба – опека һәм попечительлек органы).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

1.3.2. Опека һәм попечительлек органы урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

Эш режимы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш.

Төшке аш вакыты – 12.00 – 13.00.

Эчкә үтү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне аныклаучы документ буенча.

1.3.3. Опека һәм попечительлек органы телефоны: (84366)3–13–81.

1.3.4. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайты (алга таба – «Интернет» челтәре): http://www.arsk.tatarstan.ru.

1.3.5. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы бинасында урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аркылы;

2) «Интернет» челтәре аша:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында http://www.arsk.tatarstan.ru;

3) опека һәм попечительлек секторына шәхси мөрәҗәгать итеп;

4) күпфункцияле үзәктә (хезмәт күрсәтүне күпфункцияле үзәк аркылы алып булган очракта).

1.4. Хезмәт күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә башкарыла:

- Россия Федерациясе Конституциясе (алга таба – РФ Конституциясе) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 26.01.2009, №4, 445 маддә);

- Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы (беренче бүлеге) 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гражданлык кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 05.12.1994, №32, 3301 маддә);

- Россия Федерациясе Торак кодексы 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы (алга таба РФ Торак кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 03.01.2005, №1, (1 бүлек), 14 маддә);

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 маддә);

- «Күчемсез милеккә хокукларны дәүләт теркәве һәм аның белән бәйле килешүләр башкару турында» 1997 елның 21 июлендәге 122-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – дәүләт теркәве турында Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 28.07.1997, №30, 3594 маддә);

- «Шәхси мәгълүмат турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 152-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 31.07.2006, №31 (1 бүлек), 3451 маддә);

- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 28.04.2008, №17, 1755 маддә);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №43-44, 02.03.2004);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2008 елның 20

мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №60-61, 25.03.2008);

- «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 880 нче номерлы Карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары җыелмасы, 08.12.2010, №46, 2144 маддә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 15 августындагы боерыгы белән расланган Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында Нигезләмәсе (алга таба – опека секторы турнда Нигезләмә).

1.5.Әлеге Регламентта түбәндәге термин һәм билгеләмәләр кулланыла:

- опека – суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган гражданнарның төзелеш формасы, опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (опекуннар) аларның законлы вәкилләре булып санала һәм алар исеменнән һәм алар мәнфәгате буенча юридик әһәмияткә ия булган гамәлләр башкара ала;

- опекага алынган зат – аңа карата опека яки попечительлек билгеләнгән гражданин (эшкә яраксыз яки өлешчә эшкт яраксыз гражданин);

- административ регламент –Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралар һәм административ эшчәнлек вакытын һәм эзлеклелеген, структур бүлекчәләр һәм вазыйфаи затлар арасындагы хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хакимияте башкарма органнарының физик яки юридик затлар (алга таба – дәүләт хезмәте алучылар), башка дәүләт хезмәте һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгеләүче норматив хокукый документ;

- дәүләт хезмәте – дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән чикләрдә мөрәҗәгать итүче соравы буенча башкарыла торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарган вакытта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек;

- дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе $1^1$ бүлегендә каралган оешмалар яки аларның эшчеләре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта бозылган хокукларны яки законлы мәнфәгатьләрне кире кайтару яки саклау турында таләбе.

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яки муниципаль учреждениенең оештыру-хокукый формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирүче һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча, вәкаләтле оешма;

- «бер тәрәзә» принцибы – мөрәҗәгать итүче 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ маддәсендә күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү, ә дәүләт хезмәт күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар белән күпфункцияле үзәк тарафыннан мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актлар һәм хезмәттәшлек итү турында килешү нигезендә хезмәттәшлек алып бару принцибы.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбе исеме | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Хезмәт күрсәтү исеме | Опекага алучыга опекага алынган затныкы булган торакны наймга бирүгә рөхсәт бирү | РФ Гражданлык кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.2. Хезмәт күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты (опекага алынган кешенең яшәү урыны буенча) | Устав;<br>7-ТРЗ номерлы ТР Законы |
| 2.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Опекага алучыга опекага алынган затныкы булган торакны наймга бирүгә рөхсәт бирү турында боерык яки опекага алынган затныкы булган торакны наймга бирүгә рөхсәт бирүдән баш тарту | РФ Гражданлык кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.4. Хезмәт күрсәтү вакыты | Мөрәҗәгать итүчедән барлык кирәкле документларны алганнан соң 15 көн эчендә | |
| 2.5. Закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларның тулы исемлеге | 1. опекага алынган затныкы булган торакны наймга бирү (опекага алынган затның милкенә хокук алмыйча) турында опекага алучының гаризасы;<br>2. милек уртак өлеш милкендә булса, опекага алынган затныкы булган торакны наймга бирүгә ризалык турында милекченең (булган очракта) гаризасы;<br>3. опека билгеләү һәм опекага алучы билгеләү турында хокукый акт күчермәсе (карар, боерык);<br>4. законлы көченә кергән гражданинны эшкә яраксыз (өлешчә эшкә яраксыз) дип тану трында суд органы карары күчермәсе;<br>5. опекага алынган затның (эшкә яраксыз затның) паспорт күчермәсе;<br>6. опекага алынган зат милекчесе булып торган торак бинага хокук билгеләүче документлар күчермәсе;<br>7. опекага алынган затныкы булган торакны наймга бирү турында килешү проекты (булган очракта);<br>8. торакны наймга бирү килешүе буенча акча күчерү өчен опекага алынган зат исеменә ачылган саклау кенәгәсе. | РФ Гражданлык кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон; |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган документларның тулы исемлеге | Опекага алынган затның (эшкә яраксыз затның) милке турында Бердәм дәүләт хокукый реестрыннан (Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография Федераль хезмәте идарәсе) алынган мәгълүмат;<br>Опекага алынучы затның теркәлү урыныннан йорт (фатир) кенәгәсеннән өземтә. | |
| 2.7. Норматив хокукый актлар белән каралган очракларда хезмәт күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган һәм хезмәт күрсәтә торган башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла торган | Килештерү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| дәүләт хакимияте һәм аның структур бүлекчәләре исемлеге | | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Гражданинның тору урыны буенча мөрәҗәгать итмәве | |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>- гариза бирүче тарафыннан әлеге Административ регламентның 2.5 пукнтында күрсәтелгән документларны тапшырмавы;<br>- опекага алынучы затның гражданлык һәм милек хокукларын кысу | 48-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.10. Хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә. | |
| 2.11. Әлеге түләүне исәпләү турында мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр таләп ителми | |
| 2.12. Хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алган вакытта чиратта көтүнең максималь вакыты | Аерым категория кешеләр өчен чират билгеләнмәгән. Көтеп утыруның (хезмәт күрсәтүнең) максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты | Гариза кергән көнне | |
| 2.14. Хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр | 1. Гариза түбәндәге адрес буенча тапшырыла:<br>Арча шәһәре, Советлар мәйданы урамы, 12 йорт, опека һәм попечительлек секторы.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазланган бинада башкарыла;<br>3. Бинада гаризалар кабул итү өчен сектор белгеченең эш урыны хезмәтне тулысынча күрсәтергә мөмкинлек бирүче электрон белешмә-хокукый системалар, оргтехника белән тәэмин ителгән шәхси компьютер белән җиһазландырыла.<br>4. Документлар тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазлана һәм документлар тутыру үрнәкләре белән тәэмин ителә.<br>5. Инвалидларга хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыкларсыз керү тәэмин ителә, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм чыгу юлларына, дәүләт хезмәте күрсәтү урынына барып җитү максатында объект буйлап мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итү тәэмин ителә.<br>6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны исәпкә алып, урнаштырыла. | |
| 2.15. Хезмәт күрсәтүнең мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Хезмәт күрсәтүнең аңлаешлылыгы күрсәткечләре:<br>- бинаның җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы; | |

| | | |
|---|---|---|
| | - мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә башкарма комитетның мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү бердәм порталында хезмәт күрсәтү тәртибе, ысуллары, вакыты турында тулы мәгълүмат булу.<br>Хезмәт күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре:<br>-хезмәт күрсәтү вакытын бозмау;<br>- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять булмау;<br>- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә игътибарсызлык күрсәтүенә шикаять булмау.<br>Хезмәт күпфункцияле үзәктә күрсәтелми. | |
| 2.16. Хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Хезмәт электрон формада күрсәтелми | |

## 3. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкару составы, эзлеклелеге һәм вакыты, аларны башкару тәртибенә таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау:

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- опекага алучыларга опекага алынган затныкы булган тоаркны наймга бирүгә (милеккә хокук барлыкка килмичә) рөхсәт бирү мәсьләләре буенча мәгълүмат һәм консультация бирү;
- гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;
- кабул итү яки баш тарту нигезләрен билгеләү өчен тапшырылган документларның әлеге Административ регламент таләпләренә туры килүен тикшерү;
- дәүләт хезмәте күрсәтү яки күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема әлеге Административ регламентка кушымтада бирелә.

3.2. Консультация бирү

Мәгълүмат һәм консультация бирү буенча процедуралар кысаларында гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибен җайлаучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;
- опекага алынган затларның законлы вәкилләрен опекага алынган затныкы булган торакны наймга бирүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән таныштыра;
- опекага алынган затныкы булган торакны наймга бирүгә рөхсәт бирү өчен кирәк булган документлар исемлеге бирә .

Консультация гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Процедура нәтиҗәсе: документлар составы һәм хезмәт күрсәтү буенча башка сораулар буенча консультация.

Консультация һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедуралар башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

Гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирүче белгеч, шәхси мәгълүматларны исәпкә алып, консультациянең грамоталыгы, тулылыгы һәм ачыклыгы өчен шәхси җавап бирә.

3.3. Гариза бирүче, 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән үзе гариза тапшыра.

Гаризалар һәм документлар кабул итү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- гражданинның шәхесен, опекага алынган кешенең тору урынын билгели;
- опекага алучы (попечитель) һәм рента түләүче булырга теләгән гражданин тапшырган кирәкле документларның барлыгын тикшерә. Кирәкле документлар булмаган очракта җитмәгән документларны тапшырырга тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларны кабул итүне таләп итсә, документлар кабул ителә.
- документлар пакеты формалаштыра.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән документлар.

Гамәлләрне башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

Документларны кабул итеп алу өчен җаваплы белгеч консультациянең грамоталыгы, тулылыгы һәм ачыклыгы өчен шәхси җавап бирә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта опека һәм попечительлек, күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелсә) белгече гариза бирүчегә гариза һәм документлар алу, теркәлү номеры турында хәбәр итә, аннан соң әлеге Регламентның 3.4. подпунктында күрсәтелгән процедуралар башкарыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән вакыттан соң 1 көн эчендә 15 минут вакыт аралыгында башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язмасы.

Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч, конфиденциаль мәгълүматларны исәпкә алып, документларны кабул итү буенча процедураларны башкаруның дөреслеге өчен шәхси җавап бирә.

3.4 Опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүче тапшырган документлардагы мәгълүматны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергәннән соң 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе:  документларны тикшерү һәм рөхсәт бирү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратып алу әзерләү һәм җибәрү.

3.5.1 Опека һәм попечительлек белгече (гариза бирүче белән килештереп) ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү системасы аркылы әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны җибәрү турында электрон формада соратып алу юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән көннән 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында юлланган соратып алу.

3.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы опека һәм попечительлек секторы органнары соратуы буенча автоматлаштырылган режимда башкарыла:

- соратып алуны эшкәртү һәм соратылган мәгълүматны эзләү;

- ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү аркылы соратып алынган мәгълүматны формалаштыру, соратып алынган мәгълүмат булмаган очракта, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, соратып алынган мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар опека һәм попечительлек органнарына соратып алу кергән вакыттан 5 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: соратып алуга җавап яки әлеге Регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.6.1. Тапшырылган документлар нигезендә опека һәм попечительлек секторы белгече опекага алынган затныкы булган торакны наймга бирүгә рөхсәт бирү турында боерык проекты әзерли һәм аны килештерү һәм раслату өчен опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә җибәрә яки тиешле аныклау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: опекага алынган затныкы булган торакны наймга бирүгә рөхсәт бирү турында боерык яки 3.8 пункты нигезендә әзерләнгән хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.7. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен тапшыру.

3.7.1. Опека һәм попечительлек секторы белгече, имзаланган боерыкны алгач, аны терки һәм гариза бирүчегә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.6.1 подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.8. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат тапшыру.

3.8.1 Опека һәм попечительлек секторы белгече боерык бирүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты әзерли.

Әзерләнгән баш тарту турында хат проектын Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар баш тарту өчен нигезләр ачыкланган көннән соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзалауга юлланган баш тарту турында хат проекты.

3.8.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек секторы белгеченә кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзаланган баш тарту турында хат.

3.8.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече баш тарту турында хатны аны имзалаган көннән соң 1 эш көне эчендә гариза бирүчегә юллый. Шул ук вакытта гариза бирүчегә карарны шикаять итү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.7.2. подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формасы

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларын үтәүне тикшерүне, карар кабул итүне һәм күпфункцияле үзәкнең (хезмәт күпфункцияле үзәк аркылы күрсәтелсә), опека һәм попечительлек бүлегенең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап бирүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларының хокукый экспертизасын үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау;

- кабул итлегән тәртиптә делопроизводство алып баруны тикшерү;

- кабул ителгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү үткәрү процедураларына контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерү үткәргән вакытта дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык сораулар каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта һәм карар кабул иткән вакытта гамәлләрне башкаруны тикшерүне башкару максатында күпфункцияле үзәк, опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затлар исемлеге күпфункцияле үзәкнең, опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы гариза бирүченең мөрәҗәгатен вакытында карамаган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезләнмәгән рәвештә баш тарткан өчен җавап бирә.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, аларның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелгән очракта), опека һәм попечительлек секторы хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Арча муниципаль районы башкарма комитетына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итәргә мөкин:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар, мәгълүмат яки гамәл кылу таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү вакыты яки тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылганда, әгәр туктатылу нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса.

5.2. Шикаять почта аркылы язма рәвештә кәгазь битендә яки электрон формада җибәрелергә, шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәткән очракта шикаять күпфункцияле үзәк аркылы җибәрелә ала.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең документларны кабул итүдән баш тартуына яки киткән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять биргән очракта яки мондый төзәтүләрне башкаруның кабул ителгән вакыты бозылуга шикаять биргән очракта – аны теркәгән көннән соң 5 эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исемен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки муниципаль хезмәткәрнең исемен;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән риза булмавына дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә тасвирланган вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре теркәлгән булырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документлар исемлеге бирелә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәте күрсәтелүче зат, аның законлы вәкиле тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча опека һәм попечительлек органы җитәкчесе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

5.8. Карар кабул иткән көннән соңгы көннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән җавап җибәрелә.

5.9. Шикаять тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелсә, Башкарма комитет җитәкчесе бозуны бетерү максатында күрелергә тиешле чараларны билгели

5.9. Әгәр шикаять канәгатьләндерелмәсә, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул итлегән карарга нигезләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында аңлатма бирелә.

Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.10. Мөрәҗәгать итүчеләр башкарма комитетның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәк һәм күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять итәргә хокуклы.

Опекага алучыга опекага алынган кешенеке
булган торакны наймга бирүгә
рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
1 Кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү БЛОК-СХЕМАСЫ**

Опекага алынган затныкы булган торакны наймга бирүгә рөхсәт бирү буенча гражданнарга мәгълүмат һәм консультация бирү

//

Тапшырылган документларны кабул итү

//

Документларга тикшерү үткәрү

//

Опекага алынган затның (эшкә яраксыз, өлешчә эшкә яраксыз затның) милке турында Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә бирү турында соратып алу җибәрү

//

Мәгълүмат бирүче ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аркылы кергән соратып алу нигезендә соратып алынган документларны (мәгълүматны) бирә яки бирүдән баш тарта

// \\

| Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен нигезләр билгеләү | Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр билгеләү |
|---|---|
| // | \\ |
| Опекага алынган затныкы булган торакны наймга бирүгә боерык әзерләү | Опекага алынган затныкы булган торакны наймга бирүдән баш тарту турында хат әзерләү |
| // | \\ |
| Опекага алынган затныкы булган торакны наймга бирүгә рөхсәт бирү | Опекага алынган затныкы булган торакны наймга бирүдән баш тарту турында хат бирү |

Опекага алучыга опекага алынган кешенеке булган торакны наймга бирүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
2 Кушымта

**Техник хатаны төзәтү турында гариза**

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ___________________________________________________________(хата төре)

Язылган:_______________________________________________________

Дөрес мәгълүмат:____________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документка түбәндәге үзгәрешләрне кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итмәү турында карар кабул иткән очракта мондый карарны түбәндәге юл белән җибәрүегезне сорыйм:

Электрон документ җибәрү юлы белән E-mail адреска:_________________

Почта аша кәгазь вариантта расланган күчермә формасында ___________________________ адресы буенча.

Үземнең һәм мин вәкиле булып торган затның шәхси мәгълүматны эшкәртүгә (шәхси мәгълүматны җыю, системалаштыру, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), туктату, юкка чыгару, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматны эшкәртү өчен кирәк булган башка гамәлләр кылу), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, дәүләт хезмәте күрсәтү максатында алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан карар кабул итүне кертеп, ризалыгымны раслыйм.

Әлеге низедә раслыйм: гаризага кертелгән, минем һәм мин вәкиле булып торган затның шәхесенә кагылучы мәгълүматның, шулай ук минем тарафтан кертелгән түбәндәге мәгълүматның дөреслеген. Гаризага теркәлгән документлар (документ күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза тапшырган вакытка әлеге документлар гамәлдә һәм дөрес мәгълүматны үз эченә ала.

Түбәндәге телефон буенча миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәте сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашуга үземнең ризалыгымны бирәм: ________________________.

Дата_________________Имза________________/________________________

Хезмәт билгеләре Гариза керде: Дата:

Теркәү №

Гаризаны алган затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме һәм имзасы.

Опекага алучыга опекага алынган кешенеке булган торакны наймга бирүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
Кушымта (мәгълүмати)

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне агымдагы контрольдә тотучы җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |
| Сектор белгече | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-84366) 3-00-44 | Ispolkom.Arsk@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының
«__»_________, 2019 ел, №_____
Карарына
6 Кушымта

**Опекага алынган кешеләрнең милке белән килешүләр башкаруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү**
**Административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге регламент Арча муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Арча муниципаль районында яшәүче опекага алынган кешеләрнең милке белән килешүләр башкаруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – хезмәт күрсәтү) стандарты һәм тәртипләрен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар: опекага алынган кешеләрнең милке белән килешүләр башкаруга рөхсәт алырга теләүче Россия Федерациясе гражданнары.

1.3. Дәүләт хезмәте ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен башкаручы – балигъ булмаган затның яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (алга таба – опека һәм попечительлек органы).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

1.3.2. Опека һәм попечительлек органы урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

Эш режимы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш.

Төшке аш вакыты – 12.00 – 13.00.

Эчкә үтү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне аныклаучы документ буенча.

1.3.3. Опека һәм попечительлек органы телефоны: (84366)3–13–81.

1.3.4. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайты (алга таба – «Интернет» челтәре): http://www.arsk.tatarstan.ru.

1.3.5. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы бинасында урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аркылы;

2) «Интернет» челтәре аша:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында http://www.arsk.tatarstan.ru;

3) опека һәм попечительлек секторына шәхси мөрәҗәгать итеп;

4) күпфункцияле үзәктә (хезмәт күрсәтүне күпфункцияле үзәк аркылы алып булган очракта).

1.4. Хезмәт күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә башкарыла:

- Россия Федерациясе Конституциясе (алга таба – РФ Конституциясе) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 26.01.2009, №4, 445 маддә);

- Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы (беренче бүлеге) 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гражданлык кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 05.12.1994, №32, 3301 маддә);

- Россия Федерациясе Торак кодексы 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Торак кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2005 елның 03 гыйнвары, №1 (1 бүлек), 14 маддә);

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 маддә);

- «Психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткән вакытта гражданнар хокуклары гарантияләре турында» 1992 елның 02 июлендәге 3185-1 номерлы Россия Федерациясе законы (алга таба – 3185-1 номерлы РФ Законы) («Россия Федерациясенең халык депутатлары Советы һәм Югары Советы ведомосте», 20.08.1992, №33, 1913 маддә);

- «Күчемсез милеккә хокук һәм аның белән килешүләрне дәүләт теркәве турында» 1997 елның 21 июлендәге 122-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба дәүләт теркәве турында ФЗ) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 28.07.1997, №30, 3594 маддә);

- «Шәхси мәгълүмат турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 152-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 31.07.2006, №31 (1 бүлек), 3451 маддә);

- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 28.04.2008, №17, 1755 маддә);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №43-44, 02.03.2004);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №60-61, 25.03.2008);

- «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 880 нче номерлы Карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары җыелмасы, 08.12.2010, №46, 2144 маддә);

- «Опека һәм попечительлек өлкәсендә җирле үзидарә органнарына бирелгән вәкаләтләр буенча типлаштырылган дәүләт хезмәтләре күрсәтү административ регламентларын раслау турында» 2011 елның 29 июлендәге 1046 нчы номерлы Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы әмере;

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 15 августындагы боерыгы белән расланган Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында Нигезләмәсе (алга таба – опека секторы турнда Нигезләмә).

1.5.Әлеге Регламентта түбәндәге термин һәм билгеләмәләр кулланыла:

- опека – суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган гражданнарның төзелеш формасы, опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (опекуннар) аларның законлы вәкилләре булып санала һәм алар исеменнән һәм алар мәнфәгате буенча юридик әһәмияткә ия булган гамәлләр башкара ала;

- опекага алынган зат – аңа карата опека яки попечительлек билгеләнгән гражданин (эшкә яраксыз яки өлешчә эшкө яраклы гражданин);

- административ регламент –Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралар һәм административ эшчәнлек вакытын һәм эзлеклелеген, структур бүлекчәләр һәм вазыйфаи затлар арасындагы хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хакимияте башкарма органнарының физик яки юридик затлар (алга таба – дәүләт хезмәте алучылар), башка дәүләт хезмәте һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгеләүче норматив хокукый документ;

- дәүләт хезмәте – дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән чикләрдә мөрәҗәгать итүче соравы буенча башкарыла торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарган вакытта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек;

- дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе $1^1$ бүлегендә каралган оешмалар яки аларның эшчеләре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта бозылган хокукларны яки законлы мәнфәгатьләрне кире кайтару яки саклау турында таләбе.

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яки муниципаль учреждениенең оештыру-хокукый формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирүче һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча, вәкаләтле оешма;

- «бер тәрәзә» принцибы – мөрәҗәгать итүче 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ маддәсендә күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү, ә дәүләт хезмәт күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар белән күпфункцияле үзәк тарафыннан мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актлар һәм хезмәттәшлек итү турында килешү нигезендә хезмәттәшлек алып бару принцибы.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбе исеме | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Хезмәт күрсәтү исеме | Опекага алынган затларның милке белән килешүләр башкаруга рөхсәт бирү | РФ Гражданлык кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.2. Хезмәт күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты (опекага алынган кешенең яшәү урыны буенча) | 8-ТРЗ номерлы ТР Законы |
| 2.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Опекага алынган затларның милке белән килешүләр төзүгә рөхсәт бирү турында боерык яки опекага алынган затларның милке белән килешүләр башкаруга рөхсәт бирүдән баш тарту | 48-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.4. Хезмәт күрсәтү вакыты | Мөрәҗәгать итүчедән барлык кирәкле документларны алганнан соң 15 көн эчендә | |
| 2.5. Закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларның тулы исемлеге | 1. опекага алучы яки попечительнең (законлы вәкиленең) опекага алынган затның милке белән килешүләр башкаруга рөхсәт алу турында гаризасы (мәҗбүри таләп – опекага алынган затның мәнфәгатьләре саклану һәм килешүнең опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә башкарылуы). Опекага алынган затның милке кимегән очракта әлеге килешүгә китергән сәбәпләрне (документлар белән расланган) күрсәтергә;<br>2. опекага алынган затның дәүләт учреждениемсендә булуы турында белешмә;<br>3. опека яки попечительлек һәм опекага алучы яки попечитель билгеләү турында хокукый акт күчермәсе (карар, боерык һ.б.);<br>4. гражданинны эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы дип тану турында законлы көченә кергән суд органы карары;<br>5. опекага алынган затның торакка хокук билгеләүче документлары күчермәсе (торак бинаны гражданнарның милкенә күчерү килешүе, сату–алу килешүе һ.б.), шулай ук сатып алына торган торак өчен хокук билгеләүче документлар;<br>6. Техник инвентаризация бюросыннан белешмә яки сатыла һәм сатып алына торган торакка техник паспорт күчермәсе;<br>7. сатучының сатуга гариза-рөхсәте;<br>8. сатучының паспорт күчермәсе. | РФ Гражданлык кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган документларның тулы исемлеге | Опекага алынган затның (эшкә яраксыз затның) милке турында Бердәм дәүләт хокукый реестрыннан (Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография Федераль хезмәте идарәсе) алынган мәгълүмат;<br>Опекага алынучы затның теркәлү урыныннан йорт (фатир) кенәгәсеннән өземтә. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.7. Норматив хокукый актлар белән каралган очракларда хезмәт күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган һәм хезмәт күрсәтә торган башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла торган дәүләт хакимияте һәм аның структур бүлекчәләре исемлеге | Килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Гражданинның тору урыны буенча мөрәҗәгать итмәве | 48-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>- тапшырылган документларның әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>- опекага алынучы затның гражданлык һәм милек хокукларын кысу | РФ Гражданлык кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон; |
| 2.10. Хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә. | |
| 2.11. Әлеге түләүне исәпләү турында мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр таләп ителми | |
| 2.12. Хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алган вакытта чиратта көтүнең максималь вакыты | Аерым категория кешеләр өчен чират билгеләнмәгән. Көтеп утыруның (хезмәт күрсәтүнең) максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты | Гариза кергән көнне | |
| 2.14. Хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр | 1. Гариза түбәндәге адрес буенча тапшырыла:<br>Арча шәһәре, Советлар мәйданы урамы, 12 йорт, опека һәм попечительлек секторы.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазланган бинада башкарыла;<br>3. Бинада гаризалар кабул итү өчен сектор белгеченең эш урыны хезмәтне тулысынча күрсәтергә мөмкинлек бирүче электрон белешмә-хокукый системалар, оргтехника белән тәэмин ителгән шәхси компьютер белән җиһазландырыла.<br>4. Документлар тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазлана һәм документлар тутыру үрнәкләре белән тәэмин ителә.<br>5. Инвалидларга хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыкларсыз керү тәэмин ителә, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм чыгу юлларына, дәүләт хезмәте күрсәтү урынына барып җитү максатында объект буйлап мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итү тәэмин ителә.<br>6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм мультимедиа мәгълүматы | |

| | | |
|---|---|---|
| | гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны исәпкә алып, урнаштырыла. | |
| 2.15. Хезмәт күрсәтүнең мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Хезмәт күрсәтүнең аңлаешлылыгы күрсәткечләре:<br>- бинаның җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы;<br>- мәгълүмати стендларда, башкарма комитетның мәгълүмати ресурсларында хезмәт күрсәтү тәртибе, ысуллары, вакыты турында тулы мәгълүмат булу.<br>Хезмәт күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре:<br>- хезмәт күрсәтү вакытын бозмау;<br>- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирмәү;<br>- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә игътибарсызлык күрсәтүенә шикаять бирмәү.<br>Хезмәт күпфункцияле үзәктә күрсәтелми. | |
| 2.16. Хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Хезмәт электрон формада күрсәтелми | |

## 3. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкару составы, эзлеклелеге һәм вакыты, аларны башкару тәртибенә таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау:

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- опекага алучыларга һәм попечительләргә опекага алынган кешенең милке белән бәйле килешүләр башкаруга рөхсәт бирү буенча мәгълүмат һәм консультация бирү;
- гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;
- кабул итү яки баш тарту нигезләрен билгеләү өчен тапшырылган документларның әлеге Административ регламент таләпләренә туры килүен тикшерү;
- Бердәм дәүләт хокукый реестрыннан (Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсе) опекага алынган кешенең милке турында мәгълүмат соратып алу;
- дәүләт хезмәте күрсәтү яки күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема әлеге Административ регламентка кушымтада бирелә.

3.2. Консультация бирү

Мәгълүмат һәм консультация бирү буенча процедуралар кысаларында гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибен җайлаучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;
- опекага алынган затның законлы вәкилен опекага алынган зат милке белән бәйле килешүләр башкаруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән таныштыра;
- опекага алынган затның милке белән бәйле килешүләр башкаруга рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеген бирә.

Консультация гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Процедура нәтиҗәсе: документлар составы һәм хезмәт күрсәтү буенча башка сораулар буенча консультация.

Консультация һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедуралар башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

Гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирүче белгеч, шәхси мәгълүматларны исәпкә алып, консультациянең грамоталыгы, тулылыгы һәм ачыклыгы өчен шәхси җавап бирә.

3.3. Гариза бирүче, 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән үзе гариза тапшыра.

Гаризалар һәм документлар кабул итү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- гражданинның шәхесен, опекага алынган кешенең тору урынын билгели;
- опекага алучы (попечитель) булырга теләгән гражданин килешү башкаруга рөхсәт алу өчен тапшырган кирәкле документларның барлыгын тикшерә. Кирәкле документлар булмаган очракта җитмәгән документларны тапшырырга тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларны кабул итүне таләп итсә, документлар кабул ителә.
- документлар пакеты формалаштыра.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән документлар.

Гамәлләрне башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

Документларны кабул итеп алу өчен җаваплы белгеч консультациянең грамоталыгы, тулылыгы һәм ачыклыгы өчен шәхси җавап бирә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта опека һәм попечительлек, күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелсә) белгече гариза бирүчегә гариза һәм документлар алу, теркәлү номеры турында хәбәр итә, аннан соң әлеге Регламентның 3.3.1. подпунктында күрсәтелгән процедуралар башкарыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән вакыттан соң 1 көн эчендә 15 минут вакыт аралыгында башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язмасы.

Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч, конфиденциаль мәгълүматларны исәпкә алып, документларны кабул итү буенча процедураларны башкаруның дөреслеге өчен шәхси җавап бирә.

3.4 Опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүче тапшырган документлардагы мәгълүматны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергәннән соң 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәт бирү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратып алу әзерләү һәм җибәрү.

3.5.1 Опека һәм попечительлек белгече (гариза бирүче белән килештереп) ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү системасы аркылы әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны җибәрү турында электрон формада соратып алу юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән көннән 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында юлланган соратып алу.

3.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы опека һәм попечительлек секторы органнары соратуы буенча автоматлаштырылган режимда башкарыла:

- соратып алуны эшкәртү һәм соратылган мәгълүматны эзләү;

- ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү аркылы соратып алынган мәгълүматны формалаштыру, соратып алынган мәгълүмат булмаган очракта, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, соратып алынган мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар опека һәм попечительлек органнарына соратып алу кергән вакыттан 5 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: соратып алуга җавап яки әлеге Регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.6.1. Тапшырылган документлар нигезендә опека һәм попечительлек секторы белгече опекага алынган зат милке белән бәйле килешүләр башкаруга рөхсәт бирү турында боерык проекты әзерли һәм аны килештерү һәм раслату өчен опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә җибәрә яки тиешле аныклау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: опекага алынган зат милке белән бәйле килешүләр башкаруга рөхсәт бирү турында боерык яки 3.8 пункты нигезендә әзерләнгән хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.7. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен тапшыру.

3.7.1. Опека һәм попечительлек секторы белгече, имзаланган боерыкны алгач, аны терки һәм гариза бирүчегә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.5.1 подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.8. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат тапшыру.

3.8.1 Опека һәм попечительлек секторы белгече боерык бирүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты әзерли.

Әзерләнгән баш тарту турында хат проектын Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар баш тарту өчен нигезләр ачыкланган көннән соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзалауга юлланган баш тарту турында хат проекты.

3.8.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек секторы белгеченә кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзаланган баш тарту турында хат.

3.8.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече баш тарту турында хатны аны имзалаган көннән соң 1 эш көне эчендә гариза бирүчегә юллый. Шул ук вакытта гариза бирүчегә карарны шикаять итү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.7.2. подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формасы

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларын үтәүне тикшерүне, карар кабул итүне һәм күпфункцияле үзәкнең (хезмәт күпфункцияле үзәк аркылы күрсәтелсә), опека һәм попечительлек бүлегенең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап бирүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларының хокукый экспертизасын үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау;

- кабул итлегән тәртиптә делопроизводство алып баруны тикшерү;

- кабул ителгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү үткәрү процедураларына контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерү үткәргән вакытта дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык сораулар каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта һәм карар кабул иткән вакытта гамәлләрне башкаруны тикшерүне башкару максатында күпфункцияле үзәк, опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затлар исемлеге күпфункцияле үзәкнең, опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы гариза бирүченең мөрәҗәгатен вакытында карамаган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезләнмәгән рәвештә баш тарткан өчен җавап бирә.

**5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, аларның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү**

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелгән очракта), опека һәм попечительлек секторы хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Арча муниципаль районы башкарма комитетына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итәргә мөкин:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган документлар, мәгълүмат яки гамәл кылу таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү вакыты яки тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылганда, әгәр туктатылу нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта мөрәҗәгать итүчедән беренче тапкыр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документлар тапшырган вакытта булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү.

5.2. Шикаять почта аркылы язма рәвештә кәгазь битендә яки электрон формада җибәрелергә, шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәткән очракта шикаять күпфункцияле үзәк аркылы җибәрелә ала.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең документларны кабул итүдән баш тартуына яки киткән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять биргән очракта яки мондый төзәтүләрне башкаруның кабул ителгән вакыты бозылуга шикаять биргән очракта – аны теркәгән көннән соң 5 эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исемен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки муниципаль хезмәткәрнең исемен;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән риза булмавына дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә тасвирланган вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре теркәлгән булырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документлар исемлеге бирелә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәте күрсәтелүче зат тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта Башкарма комитет тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта ачыкланган бозуларны кичекмәстән бетерү максатында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле гамәлләр турында әйтелә.

5.9. Әгәр шикаять канәгатьләндерелмәсә, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул итлегән карарга нигезләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында аңлатма бирелә.

5.10. Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Опекага алынган кешеләрнең милке белән
килешүләр башкаруга
рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
1 Кушымта

______________районы Башкарма комитеты җитәкчесе
______________________________________________________

(фамилиясе, инициаллары)

_______________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең исеме, фамилиясе, әтисенең исеме, туу көне, тору урыны)

__________________________________
__________________________________

(йорт телефоны, кәрәзле телефон)

____________________________________

(паспорт мәгълүматлары)

ГАРИЗА

Миңа ______________________________________________________________________адресы буенча урнашкан, гомуми мәйданы ______ кв.м, торак мәйданы ________ кв.м, бүлмәләр саны ______ булган (приватизацияләнгән, милкекә сатып алынган, кооператив, дәүләтнеке булган)________________________________________________________________ фатирны, торак йортны алуга (сату-алу, сату, алыштыру) ________________________________________________________ рөхсәт бирүегезне сорыйм.

Алына торган милекнең милекчеләре (фамилияләре, исемнәре, әтиләренең исемнәре, өлешләрен күрсәтергә)_________________________________________________________________________________________

Шул исәптән эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы (фамилияләре, исемнәре, әтиләренең исемнәре, өлешләрен күрсәтергә)___________________________________________________________________________________.

_______________________________________________ (торак шартларын яхшырту, күчеп китү һ.б.) белән бәйле рәвештә _________________________________________________________________________ адресы буенча урнашкан, ________________________________(гомуми мәйданы)___________(торак мәйданы)____________(бүлмәләр саны)___________ булган _________________________(фатир, җир участогында урнашкан торак йорт) сатып алабыз, анда эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы затка __________ өлеш бүлеп бирелә.

Өстәмә мәгълүмат (кредит алу, сатып алына торган фатирны залогка бирү һәм башка чикләүләр)____________________________________________________.

Милек һәм башка хокуклар кысылмый.

Сату-алу килешүен ТР буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсендә теркәгәннән соң ике атна эчендә опека һәм попечительлек бүлегенә сату-алу килешүе һәм хокукны дәүләт теркәве таныклыгы күчермәләрен тапшырырга үземә йөкләмә алам.

Минем шәхси мәгълүматлар белән эшләргә рөхсәт бирәм.

______________________ ________________________

(дата) (имза)

Опекага алынган кешеләрнең милке белән
килешүләр башкаруга
рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
2 Кушымта

_____________районы Башкарма комитеты җитәкчесе
_______________________________________________
(фамилиясе, инициаллары)
_______________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең исеме, фамилиясе, әтисенең исеме, туу көне, тору урыны)
______________________________
______________________________
(йорт телефоны, кәрәзле телефон)
________________________________
(паспорт мәгълүматлары)

ГАРИЗА

_________________________________________________________________________ торган күчемле милекне сатуга рөхсәт бирүегезне сорыйм.
Милекнең техник характеристикасы_________________________________________________________.
Агымдагы елга милекнең бәяүләү хакы________________________________________________.
Милекче булып опекага алынган___________________________________________________________

___________________________________________________________________________ тора.
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
___________________________________________________________________________ нигезендә
(закон буенча мираска хокук турында таныклык яки башкалар)
Югалта торган милек өчен опекага алынган зат исәбенә_____________________________________________
_________________________________________________сум күләмендә акча күчә.
Опекага алынган затның хокуклары кысылмый.
Балигъ булмаган затның шәхси мәгълүматлары белән эшләүгә рөхсәт бирәм.
Өстәмә мәгълүмат:________________________________________________________________
_______________________
(дата) (имза)

Опекага алынган кешеләрнең милке белән
килешүләр башкаруга
рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
3 Кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү БЛОК-СХЕМАСЫ**

Опекага алынган затларның милке белән бәйле килешүләр башкаруга рөхсәт бирү мәсьләләре буенча мәгълүмат һәм консультация бирү

//

Гариза һәм документлар кабул итү

//

Документларны тикшерү

//

Опекага алынган затның (эшкә яраксыз затның) милке турында Бердәм хокукларны дәүләт теркәве ресстрына соратып алу юллау

//

Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аркылы кергән соратып алу нигезендә мәгълүмат бирүче соратыла торган мәгълүматны бирә яки бирүдән баш тарта

// \\

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен нигезләр билгеләү

//

Опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган зат милке белән бәйле килешүләр башкаруга рөхсәт бирү турында карар проекты әзерләү

//

Опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган затларның милке белән бәйле килешүләр башкару турында боерык бирү

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр билгеләү

\\

Опекага алынган затларның милке белән бәйле килешүләр башкаруга рөхсәт бирүдән баш тарту турында нәтиҗә бирү

\\

Опекага алынган затның милке белән бәйле килешүләр башкаруга рөхсәт бирүдән баш тарту турында нәтиҗә бирү

Опекага алынган кешеләрнең милке белән
килешүләр башкаруга
рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
4 Кушымта

**Техник хатаны төзәтү турында гариза**

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ____________________________________________________(хата төре)

Язылган:____________________________________________________

Дөрес мәгълүмат:_________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документка түбәндәге үзгәрешләрне кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итмәү турында карар кабул иткән очракта мондый карарны түбәндәге юл белән җибәрүегезне сорыйм:

Электрон документ җибәрү юлы белән E-mail адреска:_________________

Почта аша кәгазь вариантта расланган күчермә формасында __________________________ адресы буенча.

Үземнең һәм мин вәкиле булып торган затның шәхси мәгълүматны эшкәртүгә (шәхси мәгълүматны җыю, системалаштыру, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), туктату, юкка чыгару, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматны эшкәртү өчен кирәк булган башка гамәлләр кылу), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, дәүләт хезмәте күрсәтү максатында алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан карар кабул итүне кертеп, ризалыгымны раслыйм.

Әлеге низедә раслыйм: гаризага кертелгән, минем һәм мин вәкиле булып торган затның шәхесенә кагылучы мәгълүматның, шулай ук минем тарафтан кертелгән түбәндәге мәгълүматның дөреслеген. Гаризага теркәлгән документлар (документ күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза тапшырган вакытка әлеге документлар гамәлдә һәм дөрес мәгълүматны үз эченә ала.

Түбәндәге телефон буенча миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәте сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашуга үземнең ризалыгымны бирәм: _______________________.

Дата_________________Имза_______________/________________________

Хезмәт билгеләре Гариза керде: Дата:

Теркәү №

Гаризаны алган затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме һәм имзасы.

Опекага алынган кешеләрнең милке белән
килешүләр башкаруга
рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
Кушымта (мәгълүмати)

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне агымдагы контрольдә тотучы җаваплы вазыйфаи затларның**
**РЕКВИЗИТЛАРЫ**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**

| **Вазыйфа** | **Телефон** | **Электрон адрес** |
| --- | --- | --- |
| Сектор мөдире | (8-84366 ) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |
| Сектор белгече | (8-84366 ) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы (шәһәр округы) Башкарма комитеты**

| **Вазыйфа** | **Телефон** | **Электрон адрес** |
| --- | --- | --- |
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-84366) 3-00-44 | Ispolkom.Arsk@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының
«__»_________, 2019 ел, №_____
Карарына
7 Кушымта

**Яшәү урынын алыштыру белән бәйле рәвештә опекага алучыга (попечительгә) опекага алынган кешене яшәү урыны буенча теркәү исәбеннән төшерүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү**
**Административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге регламент яшәү урынын алыштыру белән бәйле рәвештә опекага алучыга (попечительгә) Арча муниципаль районында яшәүче опекага алынган кешене яшәү урыны буенча теркәү исәбеннән төшерүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – хезмәт күрсәтү) стандарты һәм тәртипләрен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар: яшәү урынын алыштыру белән бәйле рәвештә опекага алынган кешене яшәү урыны буенча теркәү исәбеннән төшерергә теләүче балигъ булмаган опекага алынган кешеләрне һәм суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган опекага алынган затларны опекага алучылар (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр).

1.3. Дәүләт хезмәте ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен башкаручы – балигъ булмаган затның яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (алга таба – опека һәм попечительлек органы).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

1.3.2. Опека һәм попечительлек органы урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

Эш режимы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш.

Төшке аш вакыты – 12.00 – 13.00.

Эчкә үтү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне аныклаучы документ буенча.

1.3.3. Опека һәм попечительлек органы телефоны: (84366)3–13–81.

1.3.4. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайты (алга таба – «Интернет» челтәре): http://www.arsk.tatarstan.ru.

1.3.5. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы биналарында урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аркылы;

2) «Интернет» челтәре аша:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында http://www.arsk.tatarstan.ru;

3) опека һәм попечительлек секторына шәхси мөрәҗәгать итеп;

4) күпфункцияле үзәктә (хезмәт күрсәтүне күпфункцияле үзәк аркылы алып булган очракта).

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә башкарыла:

- Россия Федерациясе Конституциясе (алга таба – РФ Конституциясе) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 26.01.2009, №4, 445 маддә);

- Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гражданлык кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 05.12.1994, №32, 3301 маддә);

- Россия Федерациясенең Гаилә кодексы 1995 елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гаилә кодексы) (РФ Законнар җыентыгы, 01.01.1996, №1, 16 маддә);

- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 28.04.2008, №17, 1755 маддә);

- Татарстан Республикасы Гаилә кодексы 2009 елныңө 13 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы (алга таба – ТР Гаилә кодексы) (Республика Татарстан, 16.01.2009, №8);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №43-44, 02.03.2004, ТР Министрлар кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, №21, 26 май, 2004 ел);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №60-61, 25.03.2008);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 15 августындагы боерыгы белән расланган Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында Нигезләмәсе (алга таба – опека секторы турнда Нигезләмә).

1.5.Әлеге Регламентта түбәндәге термин һәм билгеләмәләр кулланыла:

- опека – ятим балаларның, караучысыз калган балаларның, суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган гражданнарның төзелеш формасы, опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (опекуннар) аларның законлы вәкилләре булып санала һәм алар исеменнән һәм алар мәнфәгате буенча юридик әһәмияткә ия булган гамәлләр башкара ала;

- опекага алынган зат – аңа карата опека яки попечительлек билгеләнгән гражданин яки балигъ булмаган зат;

- административ регламент –Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралар һәм административ эшчәнлек вакытын һәм эзлеклелеген, структур бүлекчәләр һәм вазыйфаи затлар арасындагы хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хакимияте башкарма органнарының физик яки юридик затлар (алга таба – дәүләт хезмәте алучылар), башка дәүләт хезмәте һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгеләүче норматив хокукый документ;

- дәүләт хезмәте – дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән чикләрдә мөрәҗәгать итүче соравы буенча башкарыла торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарган вакытта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек;

- дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе $1^1$ бүлегендә каралган оешмалар яки аларның эшчеләре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта бозылган хокукларны яки законлы мәнфәгатьләрне кире кайтару яки саклау турында таләбе.

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яки муниципаль учреждениенең оештыру-хокукый формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирүче һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча, вәкаләтле оешма;

- «бер тәрәзә» принцибы – мөрәҗәгать итүче 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ маддәсендә күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү, ә дәүләт хезмәт күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар белән күпфункцияле үзәк тарафыннан мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актлар һәм хезмәттәшлек итү турында килешү нигезендә хезмәттәшлек алып бару принцибы.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбе исеме | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте исеме | Яшәү урынын алыштыру белән бәйле рәвештә опекага алучыга (попечительгә) опекага алынган кешене яшәү урыны буенча теркәү исәбеннән төшерүгә рөхсәт бирү | РФ Гаилә кодексы;<br>РФ Гражданлык кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>8-ТРЗ номерлы ТР Законы |
| 2.2. Хезмәт күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты (опекага алынган кешенең яшәү урыны буенча) | 8-ТРЗ номерлы ТР Законы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Яшәү урынын алыштыру белән бәйле рәвештә опекага алучыга (попечительгә) опекага алынган кешене яшәү урыны буенча теркәү исәбеннән төшерүгә рөхсәт | РФ Гаилә кодексы;<br>РФ Гражданлык кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон<br>8-ТРЗ номерлы ТР Законы |
| 2.4. Хезмәт күрсәтү вакыты | Мөрәҗәгать итүчедән барлык кирәкле документларны алганнан соң 15 көн эчендә | РФ Гаилә кодексы;<br>РФ Гражданлык кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон<br>8-ТРЗ номерлы ТР Законы |
| 2.5. Закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларның, шулай ук гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең тулы исемлеге | 1. яшәү урынын алыштыру белән бәйле рәвештә опекага алучының (попечительнең) опекага алынган затны яшәү урыны буенча теркәү исәбеннән төшерү турында гаризасы, сәбәпләрен һәм опекага алынган затның яңа тору урынын күрсәтеп (1 Кушымта);<br>2. законлы вәкиленең паспорт күчермәсе (1 бит + теркәлү),<br>3. балигъ булмаган опекага алынган затның туу турында таныклык күчермәсе,<br>4. балигъ булган опекага алынган затның паспорт күчермәсе,<br>5. опека (попечительлек) билгеләү һәм опекага алучы (попечитель) билгеләү турында хокукый акт (карар, боерык һ.б.),<br>6. гражданинны эшкә яраксыз (өлешчә эшкә яраксыз) дип тану турында законлы көченә кергән суд органы карары.<br>Документлар күчермәләре төп нөсхәләре булган очракта 1әр нөсхәдә тапшырыла. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган документларның тулы исемлеге | Әлеге категориягә кертергә мөмкин булган документлар юк | |
| 2.7. Норматив хокукый актлар белән каралган очракларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган һәм дәүләт хезмәте күрсәтә торган башкарма хакимият органы тарафыннан | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| башкарыла торган дәүләт хакимияте һәм аның структур бүлекчәләре исемлеге | | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Гражданинның тору урыны буенча мөрәҗәгать итмәве | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>- тапшырылган документларның әлеге Административ регламентның 2.5 пукнтында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Түләүсез нигездә | |
| 2.11. Әлеге түләүне исәпләү турында мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргән вакытта һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алган вакытта чиратта көтүнең максималь вакыты | Аерым категория кешеләр өчен чират билгеләнмәгән. Көтеп утыруның (хезмәт күрсәтүнең) максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Аерым категория дәүләт хезмәте алучылар өчен чират каралмаган. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты | Гариза кергән көнне | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | 1. Гариза түбәндәге адрес буенча тапшырыла:<br>Арча шәһәре, Советлар мәйданы урамы, 12 йорт, опека һәм попечительлек секторы.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазланган бинада башкарыла;<br>3. Бинада гаризалар кабул итү өчен сектор белгеченең эш урыны хезмәтне тулысынча күрсәтергә мөмкинлек бирүче электрон белешмә-хокукый системалар, оргтехника белән тәэмин ителгән шәхси компьютер белән җиһазландырыла.<br>4. Документлар тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазлана һәм документлар тутыру үрнәкләре белән тәэмин ителә.<br>5. Инвалидларга хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыкларсыз керү тәэмин ителә, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм чыгу юлларына, дәүләт хезмәте күрсәтү урынына барып җитү максатында объект буйлап мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итү тәэмин ителә.<br>6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны исәпкә алып, урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Хезмәт күрсәтүнең аңлаешлылыгы күрсәткечләре:<br>- бинаның җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы;<br>- мәгълүмати стендларда, башкарма комитетның мәгълүмати ресурсларында | |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәт күрсәтү тәртибе, ысуллары, вакыты турында тулы мәгълүмат булу.<br>Хезмәт күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре:<br>- хезмәт күрсәтү вакытын бозмау;<br>- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять булмау;<br>- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә игътибарсызлык күрсәтүенә шикаять булмау. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелми | |

## 3. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкару составы, эзлеклелеге һәм вакыты, аларны башкару тәртибенә таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау:

3.1.1. Яшәү урынын алыштыру белән бәйле рәвештә опекага алучыга (попечительгә) опекага алынган затны яшәү урыны бенча теркәү исәбеннән төшерүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- опекага алучыларга яшәү урынын алыштыру белән бәйле рәвештә опекага алучыга (попечительгә) опекага алынган затны яшәү урыны буенча теркәү исәбеннән төшерүгә рөхсәт бирү буенча мәгълүмат һәм консультация бирү;
- гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;
- кабул итү яки баш тарту нигезләрен билгеләү өчен тапшырылган документларның әлеге Административ регламент таләпләренә туры килүен тикшерү;
- дәүләт хезмәте күрсәтү яки күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема әлеге Административ регламентка кушымтада бирелә.

3.2. Консультация бирү

Мәгълүмат һәм консультация бирү буенча процедуралар кысаларында гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибен җайлаучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;
- опекага алынган затның законлы вәкилен яшәү урынын алыштыру белән бәйле рәвештә опекага алучыга (попечительгә) опекага алынган затны яшәү урыны буенча теркәү исәбеннән төшерүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән таныштыра;
- яшәү урынын алыштыру белән бәйле рәвештә опекага алучыга (попечительгә) опекага алынган затны яшәү урыны буенча теркәү исәбеннән төшерүгә рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеген бирә.

Консультация гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Процедура нәтиҗәсе: документлар составы һәм хезмәт күрсәтү буенча башка сораулар буенча консультация.

Консультация һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедуралар башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

Гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирүче белгеч, шәхси мәгълүматларны исәпкә алып, консультациянең грамоталыгы, тулылыгы һәм ачыклыгы өчен шәхси җавап бирә.

3.3. Гариза бирүче, 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән үзе гариза тапшыра.

Гаризалар һәм документлар кабул итү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- гражданинның шәхесен, опекага алынган кешенең тору урынын билгели;
- опекага алучы (попечитель) булырга теләгән гражданин тапшырган кирәкле документларның барлыгын тикшерә. Кирәкле документлар булмаган очракта җитмәгән документларны тапшырырга тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларны кабул итүне таләп итсә, документлар кабул ителә.
- документлар пакеты формалаштыра.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән документлар.

Гамәлләрне башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

Документларны кабул итеп алу өчен җаваплы белгеч консультациянең грамоталыгы, тулылыгы һәм ачыклыгы өчен шәхси җавап бирә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта опека һәм попечительлек, күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелсә) белгече гариза бирүчегә гариза һәм документлар алу, теркәлү номеры турында хәбәр итә, аннан соң әлеге Регламентның 3.3.1. подпунктында күрсәтелгән процедуралар башкарыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән вакыттан соң 1 көн эчендә 15 минут вакыт аралыгында башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язмасы.

Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч, конфиденциаль мәгълүматларны исәпкә алып, документларны кабул итү буенча процедураларны башкаруның дөреслеге өчен шәхси җавап бирә.

3.4 Опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүче тапшырган документлардагы мәгълүматны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергәннән соң 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәт бирү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.5.1. Тапшырылган документлар нигезендә опека һәм попечительлек секторы белгече яшәү урынын алыштыру белән бәйле рәвештә опекага алучыга (попечительгә) опекага алынучыны яшәү урыны буенча теркәү исәбеннән төшерүгә рөхсәт бирү проектын әзерли һәм аны килештерү һәм раслату өчен опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә җибәрә яки тиешле аныклау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: опекага алучыга (попечительгә) опекага алынган затны яшәү урыны буенча теркәү исәбеннән төшерүгә рөхсәт яки 3.7 пункты нигезендә әзерләнгән хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.6. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен тапшыру.

3.6.1. Опека һәм попечительлек секторы белгече, имзаланган боерыкны алгач, аны терки һәм гариза бирүчегә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.4 подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.7. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат тапшыру.

3.7.1 Опека һәм попечительлек секторы белгече рөхсәтк бирүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты әзерли.

Әзерләнгән баш тарту турында хат проектын опека һәм попечительлек секторы җитәкчесенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар баш тарту өчен нигезләр ачыкланган көннән соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзалауга юлланган баш тарту турында хат проекты.

3.7.2. Опека һәм попечительлек секторы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек секторы белгеченә кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзаланган баш тарту турында хат.

3.7.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече баш тарту турында хатны аны имзалаган көннән соң 1 эш көне эчендә гариза бирүчегә юллый. Шул ук вакытта гариза бирүчегә карарны шикаять итү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.7.2. подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формасы

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларын үтәүне тикшерүне, карар кабул итүне һәм күпфункцияле үзәкнең (хезмәт күпфункцияле үзәк аркылы күрсәтелсә), опека һәм попечительлек бүлегенең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап бирүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларының хокукый экспертизасын үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау;
- кабул итлегән тәртиптә делопроизводство алып баруны тикшерү;
- кабул ителгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү үткәрү процедураларына контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерү үткәргән вакытта дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык сораулар каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта һәм карар кабул иткән вакытта гамәлләрне башкаруны тикшерүне башкару максатында күпфункцияле үзәк, опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затлар исемлеге күпфункцияле үзәкнең, опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы гариза бирүченең мөрәҗәгатен вакытында карамаган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезләнмәгән рәвештә баш тарткан өчен җавап бирә.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, аларның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелгән очракта), опека һәм попечительлек секторы хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Арча муниципаль районы башкарма комитетына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итәргә мөкин:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган документлар, мәгълүмат яки гамәл кылу таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү вакыты яки тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылганда, әгәр туктатылу нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта мөрәҗәгать итүчедән беренче тапкыр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документлар тапшырган вакытта булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү.

5.2. Шикаять почта аркылы язма рәвештә кәгазь битендә яки электрон формада җибәрелергә, шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәткән очракта шикаять күпфункцияле үзәк аркылы җибәрелә ала.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең документларны кабул итүдән баш тартуына яки киткән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять биргән очракта яки мондый төзәтүләрне башкаруның кабул ителгән вакыты бозылуга шикаять биргән очракта – аны теркәгән көннән соң 5 эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исемен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки муниципаль хезмәткәрнең исемен;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән риза булмавына дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә тасвирланган вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре теркәлгән булырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документлар исемлеге бирелә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәте күрсәтелүче зат тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.


5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта Башкарма комитет тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта ачыкланган бозуларны кичекмәстән бетерү максатында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле гамәлләр турында әйтелә.

5.9. Әгәр шикаять канәгатьләндерелмәсә, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул итлегән карарга нигезләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында аңлатма бирелә.

5.10. Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Яшәү урынын алыштыру белән бәйле рәвештә
опекага алучыга (попечительгә) опекага
алынган кешене яшәү урыны буенча теркәү
исәбеннән төшерүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
1 Кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге Блок-схемасы**



Яшәү урынын алыштыру белән бәйле рәвештә опекага алучыга (попечительгә) опекага алынган кешене яшәү урыны буенча теркәү исәбеннән төшерүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
2 Кушымта

**Техник хатаны төзәтү турында гариза**

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ________________________________________________________(хата төре)

Язылган:___________________________________________________

Дөрес мәгълүмат:___________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документка түбәндәге үзгәрешләрне кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итмәү турында карар кабул иткән очракта мондый карарны түбәндәге юл белән җибәрүегезне сорыйм:

Электрон документ җибәрү юлы белән E-mail адреска:____________________

Почта аша кәгазь вариантта расланган күчермә формасында _______________________________ адресы буенча.

Үземнең һәм мин вәкиле булып торган затның шәхси мәгълүматны эшкәртүгә (шәхси мәгълүматны җыю, системалаштыру, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), туктату, юкка чыгару, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматны эшкәртү өчен кирәк булган башка гамәлләр кылу), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, дәүләт хезмәте күрсәтү максатында алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан карар кабул итүне кертеп, ризалыгымны раслыйм.

Әлеге низедә раслыйм: гаризага кертелгән, минем һәм мин вәкиле булып торган затның шәхесенә кагылучы мәгълүматның, шулай ук минем тарафтан кертелгән түбәндәге мәгълүматның дөреслеген. Гаризага теркәлгән документлар (документ күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза тапшырган вакытка әлеге документлар гамәлдә һәм дөрес мәгълүматны үз эченә ала.

Түбәндәге телефон буенча миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәте сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашуга үземнең ризалыгымны бирәм: ____________________________.

Дата____________________Имза__________________/____________________________

Хезмәт билгеләре Гариза керде: Дата:

Теркәү №

Гаризаны алган затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме һәм имзасы.

Яшәү урынын алыштыру белән бәйле рәвештә опекага алучыга (попечительгә) опекага алынган кешене яшәү урыны буенча теркәү исәбеннән төшерүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
Кушымта (мҗгълүмати)

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне агымдагы контрольдә тотучы җаваплы вазыйфаи затларның**
**РЕКВИЗИТЛАРЫ**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |
| Сектор белгече | (8-884366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-84366) 3-00-44 | Ispolkom.Arsk@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының
«__»_________, 2019 ел, №_____
Карарына
8 Кушымта

**Опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган кешенең милек хокукларына керүенә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү**
**Административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге регламент опекага алучыга яки попечительгә Арча муниципаль районында яшәүче опекага алынган кешенең милек хокукларына керүенә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – хезмәт күрсәтү) стандарты һәм тәртипләрен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар: опекага алынган затның мирас хокукына керергә теләүче Россия Федерациясе гражданнары.

1.3. Дәүләт хезмәте ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен башкаручы – балигъ булмаган затның яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (алга таба – опека һәм попечительлек органы).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

1.3.2. Опека һәм попечительлек органы урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

Эш режимы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш.

Төшке аш вакыты – 12.00 – 13.00.

Эчкә үтү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне аныклаучы документ буенча.

1.3.3. Опека һәм попечительлек органы телефоны: (84366)3–13–81.

1.3.4. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайты (алга таба – «Интернет» челтәре): http://www.arsk.tatarstan.ru.

1.3.5. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы бинасында урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аркылы;

2) «Интернет» челтәре аша:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында http://www.arsk.tatarstan.ru;

3) опека һәм попечительлек секторына шәхси мөрәҗәгать итеп;

4) күпфункцияле үзәктә (хезмәт күрсәтүне күпфункцияле үзәк аркылы алып булган очракта).

1.4. Хезмәт күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә башкарыла:

- Россия Федерациясе Конституциясе (алга таба – РФ Конституциясе) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 26.01.2009, №4, 445 маддә);

- Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы (беренче бүлеге) 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гражданлык кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 05.12.1994, №32, 3301 маддә);

- Россия Федерациясе Торак кодексы 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Торак кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2005 елның 03 гыйнвары, №1 (1 бүлек), 14 маддә);

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 маддә);

- «Психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткән вакытта гражданнар хокуклары гарантияләре турында» 1992 елның 02 июлендәге 3185-1 номерлы Россия Федерациясе законы (алга таба – 3185-1 номерлы РФ Законы) («Россия Федерациясенең халык депутатлары Советы һәм Югары Советы ведомосте», 20.08.1992, №33, 1913 маддә);

- «Шәхси мәгълүмат турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 152-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 31.07.2006, №31 (1 бүлек), 3451 маддә);

- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 28.04.2008, №17, 1755 маддә);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №43-44, 02.03.2004);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №60-61, 25.03.2008);

- «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 880 нче номерлы Карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары җыелмасы, 08.12.2010, №46, 2144 маддә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 15 августындагы боерыгы белән расланган Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында Нигезләмәсе (алга таба – опека секторы турнда Нигезләмә).

1.5.Әлеге Регламентта түбәндәге термин һәм билгеләмәләр кулланыла:

- опека – суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган гражданнарның төзелеш формасы, опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (опекуннар) аларның законлы вәкилләре булып санала һәм алар исеменнән һәм алар мәнфәгате буенча юридик әһәмияткә ия булган гамәлләр башкара ала;

- опекага алынган зат – аңа карата опека яки попечительлек билгеләнгән гражданин;

- административ регламент –Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралар һәм административ эшчәнлек вакытын һәм эзлеклелеген, структур бүлекчәләр һәм вазыйфаи затлар арасындагы хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хакимияте башкарма органнарының физик яки юридик затлар (алга таба – дәүләт хезмәте алучылар), башка дәүләт хезмәте һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгеләүче норматив хокукый документ;

- дәүләт хезмәте – дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән чикләрдә мөрәҗәгать итүче соравы буенча башкарыла торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарган вакытта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек;

- дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе $1^1$ бүлегендә каралган оешмалар яки аларның эшчеләре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта бозылган хокукларны яки законлы мәнфәгатьләрне кире кайтару яки саклау турында таләбе.

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яки муниципаль учреждениенең  оештыру-хокукый формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирүче һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча, вәкаләтле оешма;

- «бер тәрәзә» принцибы – мөрәҗәгать итүче 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ маддәсендә күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү, ә дәүләт хезмәт күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар белән күпфункцияле үзәк тарафыннан мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актлар һәм хезмәттәшлек итү турында килешү нигезендә хезмәттәшлек алып бару принцибы.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбе исеме | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Хезмәт күрсәтү исеме | Опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган затның мирас хокукларына керүгә рөхсәт бирү | РФ Гражданлык кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.2. Хезмәт күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты (опекага алынган кешенең яшәү урыны буенча) | 8-ТРЗ номерлы ТР Законы |
| 2.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган затның мирас хокукларына керүенә Боерык формасында рөхсәт яки хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат | 48-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.4. Хезмәт күрсәтү вакыты | Мөрәҗәгать итүчедән барлык кирәкле документларны алганнан соң 15 көн эчендә | 48-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.5. Закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларның тулы исемлеге | 1. опекага алучы яки попечительнең опекага алынган затның (варисның) мирас хокукларына керүенә рөхсәт бирү турында гаризасы;<br>2. опека һәм попечительлек яки опекага алучы яки попечитель билгеләү турында хокукый акт күчермәсе (карар, боерык);<br>3. гражданинны эшкә яраксыз (өлешчә эшкә яраксыз) дип тану турында законлы көченә кергән суд органы карары күчермәсе;<br>4. мирас калдыручының үлү турында таныклык күчермәсе;<br>5. опекага алынган зат исеменҗ закон буенча мираска хокук турында таныклык күчермәсе. | РФ Гражданлык кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган документларның тулы исемлеге | Әлеге категориягә кертелергә мөмкин булган документлар тапшыру таләп ителми. | |
| 2.7. Норматив хокукый актлар белән каралган очракларда хезмәт күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган һәм хезмәт күрсәтә торган башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла торган дәүләт хакимияте һәм аның структур бүлекчәләре исемлеге | Килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Гражданинның тору урыны буенча мөрәҗәгать итмәве | |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора: | 48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>8-ТРЗ номерлы ТР Законы |

| | | |
|---|---|---|
| | - тапшырылган документларның әлеге Административ регламентның 2.5 пукнтында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>- опекага алынучы затның гражданлык һәм милек хокукларын кысу | |
| 2.10. Хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә. | |
| 2.11. Әлеге түләүне исәпләү турында мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр таләп ителми | |
| 2.12. Хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алган вакытта чиратта көтүнең максималь вакыты | Аерым категория кешеләр өчен чират билгеләнмәгән. Көтеп утыруның (хезмәт күрсәтүнең) максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты | Гариза кергән көнне | |
| 2.14. Хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр | 1. Гариза түбәндәге адрес буенча тапшырыла:<br>Арча шәһәре, Советлар мәйданы урамы, 12 йорт, опека һәм попечительлек секторы.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазланган бинада башкарыла;<br>3. Бинада гаризалар кабул итү өчен сектор белгеченең эш урыны хезмәтне тулысынча күрсәтергә мөмкинлек бирүче электрон белешмә-хокукый системалар, оргтехника белән тәэмин ителгән шәхси компьютер белән җиһазландырыла.<br>4. Документлар тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазлана һәм документлар тутыру үрнәкләре белән тәэмин ителә.<br>5. Инвалидларга хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыкларсыз керү тәэмин ителә, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм чыгу юлларына, дәүләт хезмәте күрсәтү урынына барып җитү максатында объект буйлап мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итү тәэмин ителә.<br>6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны исәпкә алып, урнаштырыла. | |
| 2.15. Хезмәт күрсәтүнең мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Хезмәт күрсәтүнең аңлаешлылыгы күрсәткечләре:<br>- бинаның җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы;<br>- мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә башкарма комитетның мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт бердәи порталында хезмәт күрсәтү тәртибе, ысуллары, вакыты турында тулы мәгълүмат булу.<br>Хезмәт күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре:<br>- хезмәт күрсәтү вакытын бозмау;<br>- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) | |

| | | |
|---|---|---|
| | шикаять булмау;<br>- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә игътибарсызлык күрсәтүенә шикаять булмау.<br>Хезмәт күпфункцияле үзәктә күрсәтелми. | |
| 2.16. Хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Хезмәт электрон формада күрсәтелми | |

## 3. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкару составы, эзлеклелеге һәм вакыты, аларны башкару тәртибенә таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау:

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- опекага алучыларга һәм попечительләргә опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган затның мирас хокукларына керү сораулары буенча мәгълүмат һәм консультация бирү;
- гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;
- кабул итү яки баш тарту нигезләрен билгеләү өчен тапшырылган документларның әлеге Административ регламентның 2.5 пункты таләпләренә туры килүен тикшерү;
- дәүләт хезмәте күрсәтү яки күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема әлеге Административ регламентка кушымтада бирелә.

3.2. Консультация бирү

Мәгълүмат һәм консультация бирү буенча процедуралар кысаларында гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибен җайлаучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;
- опекага алынган затның законлы вәкилен опекага алынган кешенең милек хокукларына керүенә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән таныштыра;
- опекага алынган кешенең милек хокукларына керүенә рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеген бирә.

Консультация гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Процедура нәтиҗәсе: документлар составы һәм хезмәт күрсәтү буенча башка сораулар буенча консультация.

Консультация һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедуралар башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

Гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирүче белгеч, шәхси мәгълүматларны исәпкә алып, консультациянең грамоталыгы, тулылыгы һәм ачыклыгы өчен шәхси җавап бирә.

3.3. Гариза бирүче, 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән үзе гариза тапшыра.

Гаризалар һәм документлар кабул итү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- гражданинның шәхесен, опекага алынган кешенең тору урынын билгели;
- опекага алучы (попечитель) тапшырган кирәкле документларның барлыгын тикшерә. Кирәкле документлар булмаган очракта җитмәгән документларны тапшырырга тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларны кабул итүне таләп итсә, документлар кабул ителә.
- документлар пакеты формалаштыра.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән документлар.

Гамәлләрне башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

Документларны кабул итеп алу өчен җаваплы белгеч консультациянең грамоталыгы, тулылыгы һәм ачыклыгы өчен шәхси җавап бирә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта опека һәм попечительлек, күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелсә) белгече гариза бирүчегә гариза һәм документлар алу, теркәлү номеры турында хәбәр итә, аннан соң әлеге Регламентның 3.3.1. подпунктында күрсәтелгән процедуралар башкарыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән вакыттан соң 1 көн эчендә 15 минут вакыт аралыгында башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язмасы.

Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч, конфиденциаль мәгълүматларны исәпкә алып, документларны кабул итү буенча процедураларны башкаруның дөреслеге өчен шәхси җавап бирә.

3.4 Опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүче тапшырган документлардагы мәгълүматны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергәннән соң 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәт бирү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.5.1. Тапшырылган документлар нигезендә опека һәм попечительлек секторы белгече опекага алынган кешенең милек хокукларына керүенә рөхсәт бирү турында боерык проекты әзерли һәм аны килештерү һәм раслату өчен опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә җибәрә яки тиешле аныклау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: опекага алынган кешенең милек хокукларына керүенә рөхсәт бирү турында боерык яки 3.7 пункты нигезендә әзерләнгән хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.6 Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен тапшыру.

3.6.1. Опека һәм попечительлек секторы белгече, имзаланган боерыкны алгач, аны терки һәм гариза бирүчегә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.4 подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.7. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат тапшыру.

3.7.1 Опека һәм попечительлек секторы белгече боерык бирүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты әзерли.

Әзерләнгән баш тарту турында хат проектын опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар баш тарту өчен нигезләр ачыкланган көннән соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзалауга юлланган баш тарту турында хат проекты.

3.7.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек секторы белгеченә кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзаланган баш тарту турында хат.

3.7.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече баш тарту турында хатны аны имзалаган көннән соң 1 эш көне эчендә гариза бирүчегә юллый. Шул ук вакытта гариза бирүчегә карарны шикаять итү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.7.2. подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формасы

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларын үтәүне тикшерүне, карар кабул итүне һәм күпфункцияле үзәкнең (хезмәт күпфункцияле үзәк аркылы күрсәтелсә), опека һәм попечительлек бүлегенең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап бирүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларының хокукый экспертизасын үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау;

- кабул итлегән тәртиптә делопроизводство алып баруны тикшерү;

- кабул ителгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү үткәрү процедураларына контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерү үткәргән вакытта дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык сораулар каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта һәм карар кабул иткән вакытта гамәлләрне башкаруны тикшерүне башкару максатында күпфункцияле үзәк, опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затлар исемлеге күпфункцияле үзәкнең, опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы гариза бирүченең мөрәҗәгатен вакытында карамаган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезләнмәгән рәвештә баш тарткан өчен җавап бирә.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, аларның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелгән очракта), опека һәм попечительлек секторы хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Арча муниципаль районы башкарма комитетына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итәргә мөкин:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган документлар, мәгълүмат яки гамәл кылу таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү вакыты яки тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылганда, әгәр туктатылу нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта мөрәҗәгать итүчедән беренче тапкыр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документлар тапшырган вакытта булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү.

5.2. Шикаять почта аркылы язма рәвештә кәгазь битендә яки электрон формада җибәрелергә, шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәткән очракта шикаять күпфункцияле үзәк аркылы җибәрелә ала.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең документларны кабул итүдән баш тартуына яки киткән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять биргән очракта яки мондый төзәтүләрне башкаруның кабул ителгән вакыты бозылуга шикаять биргән очракта – аны теркәгән көннән соң 5 эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исемен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки муниципаль хезмәткәрнең исемен;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән риза булмавына дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә тасвирланган вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре теркәлгән булырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документлар исемлеге бирелә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәте күрсәтелүче зат тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта Башкарма комитет тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта ачыкланган бозуларны кичекмәстән бетерү максатында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле гамәлләр турында әйтелә.

5.9. Әгәр шикаять канәгатьләндерелмәсә, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул итлегән карарга нигезләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында аңлатма бирелә.

5.10. Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган кешенең милек хокукларына керүенә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
1 Кушымта

______________районы Башкарма комитеты җитәкчесе
_____________________________________________________
(фамилиясе, инициаллары)
_______________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең исеме, фамилиясе, әтисенең исеме, туу көне, тору урыны)
_________________________________
_________________________________
(йорт телефоны, кәрәзле телефон)
___________________________________
(паспорт мәгълүматлары)

ГАРИЗА

Мин опекага алган зат ___________________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________________
(опекага алынган затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, тору урыны һәм теркәлү урыны)
исеменнән мирас хокукларына керүгә рөхсәт бирүегезне сорыйм.

Суд карары "__" _________ ____ ел.

Дата "__" _________ ____ ел. Имза ________________

Опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган кешенең милек хокукларына керүенә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
2 Кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү БЛОК-СХЕМАСЫ**

Опекага алынган затның мирас хокукларына керүенә рөхсәт бирү мәсьәләләре буенча гражданнарга мәгълүмат һәм консультация бирү

//

Тапшырылган документларны кабул итү

//

Документларны тикшерү

//

Дәүләт хезмәте күрсәтү яки күрсәтүдән баш тарту нигезләрен билгеләү

// \\

Опекага алынган затның мирас хокукларына керүгә рөхсәт бирү турында боерык әзерләү

//

Опекага алынган затның мирас хокукларына керүенә боерык бирү

Опекага алынган затның мирас хокукларына керүенә рөхсәт бирүдән баш тарту турында нәтиҗә әзерләү

\\

Опекага алынган затның мирас хокукларына керүенә рөхсәт бирүдән баш тарту турында нәтиҗә бирү

Опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган кешенең милек хокукларына керүенә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
3 Кушымта

**Техник хатаны төзәтү турында гариза**

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ______________________________________________________________(хата төре)

Язылган:______________________________________________________________

Дөрес мәгълүмат:_____________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документка түбәндәге үзгәрешләрне кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итмәү турында карар кабул иткән очракта мондый карарны түбәндәге юл белән җибәрүегезне сорыйм:

Электрон документ җибәрү юлы белән E-mail адреска:_________________

Почта аша кәгазь вариантта расланган күчермә формасында __________________________ адресы буенча.

Үземнең һәм мин вәкиле булып торган затның шәхси мәгълүматны эшкәртүгә (шәхси мәгълүматны җыю, системалаштыру, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), туктату, юкка чыгару, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматны эшкәртү өчен кирәк булган башка гамәлләр кылу), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, дәүләт хезмәте күрсәтү максатында алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан карар кабул итүне кертеп, ризалыгымны раслыйм.

Әлеге низедә раслыйм: гаризага кертелгән, минем һәм мин вәкиле булып торган затның шәхесенә кагылучы мәгълүматның, шулай ук минем тарафтан кертелгән түбәндәге мәгълүматның дөреслеген. Гаризага теркәлгән документлар (документ күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза тапшырган вакытка әлеге документлар гамәлдә һәм дөрес мәгълүматны үз эченә ала.

Түбәндәге телефон буенча миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәте сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашуга үземнең ризалыгымны бирәм: _______________________.

Дата_________________Имза_______________/________________________

Хезмәт билгеләре  Гариза керде:  Дата:

Теркәү №

Гаризаны алган затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме һәм имзасы.

Опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган кешенең милек хокукларына керүенә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
Кушымта (мәгълүмати)

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне агымдагы контрольдә тотучы җаваплы вазыйфаи затларның**
**РЕКВИЗИТЛАРЫ**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |
| Сектор белгече | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-84366) 3-00-44 | Ispolkom.Arsk@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының
«__»_________, 2019 ел, №_____
Карарына
9 Кушымта

**Опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган кешенең саклык исәп-хисап счеты белән куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү**
**Административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге регламент Арча муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан опекага алучыга яки попечительгә Арча муниципаль районында яшәүче опекага алынган кешенең саклык исәп-хисап счеты белән куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – хезмәт күрсәтү) стандарты һәм тәртипләрен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар: опекага алынган затның исәп-хисап счеты белән кулланырга теләүче Россия Федерациясе гражданнары.

1.3. Дәүләт хезмәте ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен башкаручы – опекага алынган затның яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (алга таба – опека һәм попечительлек органы).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

1.3.2. Опека һәм попечительлек органы урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

Эш режимы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш.

Төшке аш вакыты – 12.00 – 13.00.

Эчкә үтү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне ачыклаучы документ буенча.

1.3.3. Опека һәм попечительлек органы телефоны: (84366)3–13–81.

1.3.4. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайты (алга таба – «Интернет» челтәре): http://www.arsk.tatarstan.ru.

1.3.5. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы бинасында урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аркылы;

2) «Интернет» челтәре аша:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында http://www.arsk.tatarstan.ru;

3) опека һәм попечительлек секторына шәхси мөрәҗәгать итеп;

4) күпфункцияле үзәктә (хезмәт күрсәтүне күпфункцияле үзәк аркылы алып булган очракта).

1.4. Хезмәт күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә башкарыла:

- Россия Федерациясе Конституциясе (алга таба – РФ Конституциясе) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 26.01.2009, №4, 445 маддә);

- Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы (беренче бүлеге) 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гражданлык кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 05.12.1994, №32, 3301 маддә);

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 маддә);

- «Психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткән вакытта гражданнар хокуклары гарантияләре турында» 1992 елның 02 июлендәге 3185-1 номерлы Россия Федерациясе законы (алга таба – 3185-1 номерлы РФ Законы) («Россия Федерациясенең халык депутатлары Советы һәм Югары Советы ведомосте», 20.08.1992, №33, 1913 маддә);

- «Шәхси мәгълүмат турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 152-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2006, №31 (1 бүлек), 3451 маддә);

- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 28.04.2008, №17, 1755 маддә);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №43-44, 02.03.2004);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №60-61, 25.03.2008);

- «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 880 нче номерлы Карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары җыелмасы, 08.12.2010, №46, 2144 маддә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 15 августындагы боерыгы белән расланган Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында Нигезләмәсе (алга таба – опека секторы турнда Нигезләмә).

1.5.Әлеге Регламентта түбәндәге термин һәм билгеләмәләр кулланыла:

- опека – суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган гражданнарның төзелеш формасы, опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (опекуннар) аларның законлы вәкилләре булып санала һәм алар исеменнән һәм алар мәнфәгате буенча юридик әһәмияткә ия булган гамәлләр башкара ала;

- опекага алынган зат – аңа карата опека яки попечительлек билгеләнгән гражданин;

- эшкә яраксыз гражданин – РФ Гражданлык кодексының 29 маддәсе нигезендә суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган гражданин;

- өлешчә эшкә яраклы – РФ Гражданлык кодексының 30 маддәсе нигезендә суд тарафыннан өлешчә эшкә яраклы дип танылган гражданин;

- административ регламент –Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралар һәм административ эшчәнлек вакытын һәм эзлеклелеген, структур бүлекчәләр һәм вазыйфаи затлар арасындагы хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хакимияте башкарма органнарының физик яки юридик затлар (алга таба – дәүләт хезмәте алучылар), башка дәүләт хезмәте һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгеләүче норматив хокукый документ;

- дәүләт хезмәте – дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән чикләрдә мөрәҗәгать итүче соравы буенча башкарыла торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарган вакытта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек;

- дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе $1^1$ бүлегендә каралган оешмалар яки аларның эшчеләре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта бозылган хокукларны яки законлы мәнфәгатьләрне кире кайтару яки саклау турында таләбе.

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яки муниципаль учреждениенең оештыру-хокукый формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирүче һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча, вәкаләтле оешма;

- «бер тәрәзә» принцибы – мөрәҗәгать итүче 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ маддәсендә күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү, ә дәүләт хезмәт күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар белән күпфункцияле үзәк тарафыннан мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актлар һәм хезмәттәшлек итү турында килешү нигезендә хезмәттәшлек алып бару принцибы.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбе исеме | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Хезмәт күрсәтү исеме | Опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган затның исәп-хисап счеты белән куллануга рөхсәт бирү | РФ Гражданлык кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.2. Хезмәт күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты (опекага алынган кешенең яшәү урыны буенча) | 8-ТРЗ номерлы ТР Законы |
| 2.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган затның исәп-хисап счеты белән куллануга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты рөхсәте яки опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган затның исәп-хисап счеты белән куллануга рөхсәт бирүдән баш тарту | 48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>8-ТРЗ номерлы ТР Законы;<br>Устав, ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә 2014 елның 15 августындагы |
| 2.4. Хезмәт күрсәтү вакыты | Мөрәҗәгать итүчедән барлык кирәкле документларны алганнан соң 15 көн эчендә | |
| 2.5. Закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларның тулы исемлеге | 1. опекага алучы яки попечительнең опекага алынган затның исәп-хисап счеты белән куллануга рөхсәт бирү турында гаризасы, акчаларны куллану турында хисап (мөмкинлектән чыгып – счетлар, чек күчермәләре) бирү шарты белән, опекага алынган затның мәнфәгатьләрендә конкрет чыгымнарны күрсәтеп (1 Кушымта);<br>2. Опека яки попечительлек билгеләү, опекага алучы яки попечитель билгеләү турында хокукый акт күчермәсе;<br>3. гражданинны эшкә яраксыз (өлешчә эшкә яраклы) дип тану турында законлы көченә кергән суд органы карары күчермәсе;<br>4. опекага алынучы затның саклык кенәгәсе күчермәсе;<br>5. опекага алучының (попечительнең) һәм опекага алынган затның паспорт күчермәсе | РФ Гражданлык кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган документларның тулы исемлеге | Әлеге категориягә кертергә мөмкин булган документлар тапшыру таләп ителми | |
| 2.7. Норматив хокукый актлар белән каралган очракларда хезмәт күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган һәм хезмәт күрсәтә торган башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла торган | Килештерү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| дәүләт хакимияте һәм аның структур бүлекчәләре исемлеге | | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Гражданинның тору урыны буенча мөрәҗәгать итмәве | |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>- тапшырылган документларның әлеге Административ регламентның 2.5 пукнтында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>- опекага алынучы затның гражданлык һәм милек хокукларын кысу | РФ Гражданлык кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.10. Хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә. | |
| 2.11. Әлеге түләүне исәпләү турында мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр таләп ителми | |
| 2.12. Хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алган вакытта чиратта көтүнең максималь вакыты | Аерым категория кешеләр өчен чират билгеләнмәгән. Көтеп утыруның (хезмәт күрсәтүнең) максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты | Гариза кергән көнне | |
| 2.14. Хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр | 1. Гариза түбәндәге адрес буенча тапшырыла:<br>Арча шәһәре, Советлар мәйданы урамы, 12 йорт, опека һәм попечительлек секторы.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазланган бинада башкарыла;<br>3. Бинада гаризалар кабул итү өчен сектор белгеченең эш урыны хезмәтне тулысынча күрсәтергә мөмкинлек бирүче электрон белешмә-хокукый системалар, оргтехника белән тәэмин ителгән шәхси компьютер белән җиһазландырыла.<br>4. Документлар тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазлана һәм документлар тутыру үрнәкләре белән тәэмин ителә.<br>5. Инвалидларга хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыкларсыз керү тәэмин ителә, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм чыгу юлларына, дәүләт хезмәте күрсәтү урынына барып җитү максатында объект буйлап мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итү тәэмин ителә.<br>6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны исәпкә алып, урнаштырыла. | |
| 2.15. Хезмәт күрсәтүнең мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Хезмәт күрсәтүнең аңлаешлылыгы күрсәткечләре:<br>- бинаның җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы; | |

| | | |
|---|---|---|
| | - мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә башкарма комитетның мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталында хезмәт күрсәтү тәртибе, ысуллары, вакыты турында тулы мәгълүмат булу.<br>Хезмәт күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре:<br>- хезмәт күрсәтү вакытын бозмау;<br>- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять булмау;<br>- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә игътибарсызлык күрсәтүенә шикаять булмау.<br>Хезмәт күпфункцияле үзәктә күрсәтелми. | |
| 2.16. Хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Хезмәт электрон формада күрсәтелми | |

## 3. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкару составы, эзлеклелеге һәм вакыты, аларны башкару тәртибенә таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау:

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- опекага алучыларга һәм попечительләргә опекага алучыларга яки попечительләргә опекага алынган затның исәп-хисап счеты белән куллану мәсьәләләре буенча мәгълүмат һәм консультация бирү;
- гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;
- кабул итү яки баш тарту нигезләрен билгеләү өчен тапшырылган документларның әлеге Административ регламент таләпләренә туры килүен тикшерү;
- дәүләт хезмәте күрсәтү яки күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема әлеге Административ регламентка 3 Кушымтада бирелә.

3.2. Консультация бирү

Мәгълүмат һәм консультация бирү буенча процедуралар кысаларында гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибен җайлаучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;
- опекага алынган затның законлы вәкилен опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган кешенең саклык исәп-хисап счеты белән куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән таныштыра;
- опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган кешенең саклык исәп-хисап счеты белән куллануга рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеген бирә.

Консультация гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Процедура нәтиҗәсе: документлар составы һәм хезмәт күрсәтү буенча башка сораулар буенча консультация.

Консультация һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедуралар башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

3.3. Гариза бирүче, 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән үзе гариза тапшыра.

Гаризалар һәм документлар кабул итү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- гражданинның шәхесен, опекага алынган кешенең тору урынын билгели;
- опекага алучы (попечитель) тапшырган кирәкле документларның барлыгын тикшерә. Кирәкле документлар булмаган очракта җитмәгән документларны тапшырырга тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларны кабул итүне таләп итсә, документлар кабул ителә.
- документлар пакеты формалаштыра.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән документлар.

Гамәлләрне башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта опека һәм попечительлек, күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелсә) белгече гариза бирүчегә гариза һәм документлар алу, теркәлү номеры турында хәбәр итә, аннан соң әлеге Регламентның 3.4. подпунктында күрсәтелгән процедуралар башкарыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән вакыттан соң 1 көн эчендә 15 минут вакыт аралыгында башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язмасы.

3.4 Опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүче тапшырган документлардагы мәгълүматны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергәннән соң 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәт бирү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.5.1. Тапшырылган документлар нигезендә опека һәм попечительлек секторы белгече опекага алынган кешенең саклык исәп-хисап счеты белән куллануга рөхсәт бирү турында боерык проекты әзерли һәм аны килештерү һәм раслату өчен опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә җибәрә яки тиешле аныклау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган кешенең саклык исәп-хисап счеты белән куллануга рөхсәт бирү турында боерык яки 3.7 пункты нигезендә әзерләнгән хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.6. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен тапшыру.

3.6.1. Опека һәм попечительлек секторы белгече, имзаланган боерыкны алгач, аны терки һәм гариза бирүчегә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.4 подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.7. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат тапшыру.

3.7.1 Опека һәм попечительлек секторы белгече боерык бирүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты әзерли.

Әзерләнгән баш тарту турында хат проектын опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар баш тарту өчен нигезләр ачыкланган көннән соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзалауга юлланган баш тарту турында хат проекты.

3.7.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек секторы белгеченә кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзаланган баш тарту турында хат.

3.7.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече баш тарту турында хатны аны имзалаган көннән соң 1 эш көне эчендә гариза бирүчегә юллый. Шул ук вакытта гариза бирүчегә карарны шикаять итү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.7.2. подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формасы

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларын үтәүне тикшерүне, карар кабул итүне һәм күпфункцияле үзәкнең (хезмәт күпфункцияле үзәк аркылы күрсәтелсә), опека һәм попечительлек бүлегенең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап бирүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларының хокукый экспертизасын үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау;

- кабул итлегән тәртиптә делопроизводство алып баруны тикшерү;

- кабул ителгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү үткәрү процедураларына контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерү үткәргән вакытта дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык сораулар каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта һәм карар кабул иткән вакытта гамәлләрне башкаруны тикшерүне башкару максатында күпфункцияле үзәк, опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затлар исемлеге күпфункцияле үзәкнең, опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы гариза бирүченең мөрәҗәгатен вакытында карамаган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезләнмәгән рәвештә баш тарткан өчен җавап бирә.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, аларның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелгән очракта), опека һәм попечительлек секторы хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Арча муниципаль районы башкарма комитетына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итәргә мөкин:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган документлар, мәгълүмат яки гамәл кылу таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү вакыты яки тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылганда, әгәр туктатылу нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта мөрәҗәгать итүчедән беренче тапкыр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документлар тапшырган вакытта булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү.

5.2. Шикаять почта аркылы язма рәвештә кәгазь битендә яки электрон формада җибәрелергә, шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәткән очракта шикаять күпфункцияле үзәк аркылы җибәрелә ала.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең документларны кабул итүдән баш тартуына яки киткән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять биргән очракта яки мондый төзәтүләрне башкаруның кабул ителгән вакыты бозылуга шикаять биргән очракта – аны теркәгән көннән соң 5 эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исемен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки муниципаль хезмәткәрнең исемен;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән риза булмавына дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә тасвирланган вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре теркәлгән булырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документлар исемлеге бирелә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәте күрсәтелүче зат тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта Башкарма комитет тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта ачыкланган бозуларны кичекмәстән бетерү максатында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле гамәлләр турында әйтелә.

5.9. Әгәр шикаять канәгатьләндерелмәсә, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул итлегән карарга нигезләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында аңлатма бирелә.

5.10. Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган кешенең саклык исәп-хисап счеты белән куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
1 Кушымта

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлек Башкарма комитеты опека һәм попечительлек секторы җитәкчесенә
_______________________________________________
(җитәкченең фамилиясе, инициаллары)
____________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең исеме, фамилиясе, әтисенең исеме, туу көне, тору урыны)
________________________________
________________________________
(йорт телефоны, кәрәзле телефон)
__________________________________
(паспорт мәгълүматлары)

ГАРИЗА

Мин опекага алучы (попечитель) (тиешлесенең астына сызарга) булып торган эшкә яраксыз (өлешчә эшкә яраклы) затның
______________________________________________________________________________________________
(эшкә яраксыз, өлешчә эшкә яраклы затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
______________________________________________________________________________________________
(сүз белән)
сум күләмендә акчалары белән куллануга (счеттан алуга) рөхсәт бирүегезне сорыйм.

Әлеге акчалар белән куллану түбәндәге максатлар өчен кирәк:____________________
______________________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________________

Дата "__" __________ ____ ел                                        Имза ________________________

Опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган кешенең саклык исәп-хисап счеты белән куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
2 Кушымта

**КАРАР**

№_______________ _________ ________ ________ел

**Опекага алынган затның сакылк счеты белән куллану турында**

_________ елда туган, ___________________________________________________________ адресы
(даими яшәү адресы – өлкә, шәһәр, район, урам, йорт №, фатир №)
буенча яшәүче опекага алучының (попечитель) _____________________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туу датасы)
________ елда туган, __________________________ ел, ____________________ суд карары белән эшкә
(суд карары датасы) (суд исеме)
яраксыз (өлешчә эшкә яраклы) дип танылган эшкә яраксыз (өлешчә эшкә яраклы) гражданинның _________
______________________________________________________________________________________________
(эшкә яраксыз (өлешчә эшкә яраклы) гражданинның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

акчалары белән куллану турында гаризасын карап,

Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 37 маддәсе нигезендә һәм, _________ елның
_________________дәге опека һәм попечительлек буенча Комиссия нәтиҗәсенә таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Опекага алучыга (попечитель) ___________________________________________________________
(опекага алучының, попечительнең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

__________________________________________________________________________________ максатында
эшкә яраксыз (өлешчә эшкә яраклы) гражданинның ____________________________________________
______________________________________________________________________________________________
(эшкә яраксыз (өлешчә эшкә яраклы) гражданинның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

_____________________________________________________________________________________ сум
(сүз белән)
күләмендә акчалары белән кулланырга рөхсәт бирәм.

2. Опекага алучыга ай саен _________________ елда туган опекага алынган затның ________________________
______________________________________________________________________________________________
(опекага алынган затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
пенсия акчаларын һәм башка социаль түләүләрен ________________________________________________ вакыт
(1 елга, тик пенсия билгеләнгән вакыттан да күбрәк түгел)
белән ________________________________________________________________________________________
(тапшыру оешмасы исеме – почта бүлекчәсе, башка оешма, кредит учреждениесе исеме, опекага алынган затның кертем счеты номеры)

алырга рөхсәт итәргә.

3. Опекага алучыга, попечительгә ел саен 1 февральдән дә соңга калмыйча опека һәм попечительлек органына үткән ел өчен опекага алынган затның милкеен саклау, куллану һәм идарә итү турында хисап тапшырырга.

---

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль берәмлек башкарма комитеты җитәкчесе
___________________________________ йөкләргә.
(фамилиясе, инициаллары)

Җитәкче ______________/ ____________________________
(имза) (фамилия, инициаллар)

М.П.

Опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган кешенең саклык исәп-хисап счеты белән куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
3 Кушымта

**Пенсия акчаларын һәм башка социаль түләүләрне алуга**
**РӨХСӘТ**

________________________________________________ опекага алучы, попечитель булып билгеләнгән
(документ исеме, дата, номер)
_______________________________________________________________________________________________
(опекага алучының, попечительнең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

ай саен ________________ елда туган опекага алынган затның ________________________________
_______________________________________________________________________________________________,
(опекага алынган затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
пенсия акчаларын һәм башка социаль түләүләрен
___________________________________________________________________
(тапшыру оешмасы исеме – почта бүлекчәсе,
____________________________________________________________________________________________
башка оешма, кредит учреждениесе исеме, опекага алынган затның кертем счеты номеры)

алып барырга рөхсәт итәргә.

Рөхсәтнең гамәлдә булу вакыты______________________________________
(1 елга, тик пенсия билгеләнгән вакыттан да соңрак вакытка түгел)

Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе _____________ ( ____________)
(имза) (фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
М.П.

Опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган кешенең саклык исәп-хисап счеты белән куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
4 Кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү БЛОК-СХЕМАСЫ**

Опекага алучыларга һәм попечительләргә опекага алынган затның саклык счеты (пенсияләрен алу) белән куллануга рөхсәт бирү турында мәгълүмат һәм консультация бирү

//

Гариза һәм документлар кабул итү

//

Документларны тикшерү.

| // | \\ |
|---|---|
| Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен нигезләр билгеләү. | Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр билгеләү. |
| // | \\ |
| Опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган затның саклык счеты белән куллануга рөхсәт әзерләү | Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында нәтиҗә әзерләү |
| // | |
| Опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган затның саклык счеты белән куллануга рөхсәт бирү | Опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган затның саклык счеты белән куллануга рөхсәт бирүдән баш тарту турында нәтиҗә бирү |

Опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган кешенең саклык исәп-хисап счеты белән куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
5 Кушымта

**Техник хатаны төзәтү турында гариза**

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ____________________________________________________________(хата төре)

Язылган:_______________________________________________________

Дөрес мәгълүмат:____________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документка түбәндәге үзгәрешләрне кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итмәү турында карар кабул иткән очракта мондый карарны түбәндәге юл белән җибәрүегезне сорыйм:

Электрон документ җибәрү юлы белән E-mail адреска:__________________

Почта аша кәгазь вариантта расланган күчермә формасында ___________________________ адресы буенча.

Үземнең һәм мин вәкиле булып торган затның шәхси мәгълүматны эшкәртүгә (шәхси мәгълүматны җыю, системалаштыру, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), туктату, юкка чыгару, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматны эшкәртү өчен кирәк булган башка гамәлләр кылу), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, дәүләт хезмәте күрсәтү максатында алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан карар кабул итүне кертеп, ризалыгымны раслыйм.

Әлеге ниседә раслыйм: гаризага кертелгән, минем һәм мин вәкиле булып торган затның шәхесенә кагылучы мәгълүматның, шулай ук минем тарафтан кертелгән түбәндәге мәгълүматның дөреслеген. Гаризага теркәлгән документлар (документ күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза тапшырган вакытка әлеге документлар гамәлдә һәм дөрес мәгълүматны үз эченә ала.

Түбәндәге телефон буенча миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәте сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашуга үземнең ризалыгымны бирәм: ________________________.

Дата__________________Имза________________/_________________________

Хезмәт билгеләре Гариза керде: Дата:

Теркәү №

Гаризаны алган затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме һәм имзасы.

Опекага алучыга яки попечительгә опекага алынган кешенең саклык исәп-хисап счеты белән куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
Кушымта (мәгълүмати)

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне агымдагы контрольдә тотучы җаваплы вазыйфаи затларның**
**РЕКВИЗИТЛАРЫ**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |
| Сектор белгече | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-84366) 3-00-44 | Ispolkom.Arsk@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының
«__»_________, 2019 ел, №_____
Карарына
10 Кушымта

.

**Ятим балалар өчен оешмаларда яшәүче һәм эти-әнисез калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча бирү мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү**
**Административ регламенты**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге регламент ятим балалар өчен оешмаларда яшәүче һәм эти-әнисез калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча бирү мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – хезмәт күрсәтү) стандарты һәм тәртипләрен билгели.

1.2. Хезмәт алучылар: ятим балалар өчен оешмаларда яшәүче һәм эти-әнисез калган балаларны балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча бирү мөмкинлеге турында нәтиҗә алырга теләүче Россия Федерациясе гражданнары.

1.3. Дәүләт хезмәте ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен башкаручы – опекага алынган затның яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (алга таба – опека һәм попечительлек органы).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

1.3.2. Опека һәм попечительлек органы урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

Эш режимы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш.

Төшке аш вакыты – 12.00 – 13.00.

Эчкә үтү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне аныклаучы документ буенча.

1.3.3. Опека һәм попечительлек органы телефоны: (84366)3–13–81.

1.3.4. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайты (алга таба – «Интернет» челтәре): http://www.arsk.tatarstan.ru.

1.3.5. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы бинасында урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аркылы;

2) «Интернет» челтәре аша:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында http://www.arsk.tatarstan.ru;

3) опека һәм попечительлек секторына шәхси мөрәҗәгать итеп;

4) күпфункцияле үзәктә (хезмәт күрсәтүне күпфункцияле үзәк аркылы алып булган очракта).

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә башкарыла:

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 маддә);

- «Ятим балалар өчен оешмаларда яшәүче һәм эти-әнисез калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча бирү мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында» 432 нче номерлы 2009 елның 19 маендагы РФ Хөкүмәте карары белән расланган Ятим балалар өчен оешмаларда яшәүче һәм эти-әнисез калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча бирү мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Кагыйдәләре (алга таба – 432 нче Кагыйдәләр) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 25.05.2009, №21, 2581 маддә);

- «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 25 маендагы 432 нче номерлы карарын гамәлгә ашыру турында» 2009 елның 18 июнендәге 212 нче номерлы РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы әмере;

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыелмасы, 26.05.2004, №21, 2021 маддә);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №60-61, 25.03.2008, «Татарстан Дәүләт Советы ведомосте», 2008, №3, 212 маддә);
- «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары;
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 15 августындагы боерыгы белән расланган Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында Нигезләмәсе (алга таба – опека секторы турнда Нигезләмә).
1.5.Әлеге Регламентта түбәндәге термин һәм билгеләмәләр кулланыла:
- административ регламент –Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралар һәм административ эшчәнлек вакытын һәм эзлеклелеген, структур бүлекчәләр һәм вазыйфаи затлар арасындагы хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хакимияте башкарма органнарының физик яки юридик затлар (алга таба – дәүләт хезмәте алучылар), башка дәүләт хезмәте һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгеләүче норматив хокукый документ;
- дәүләт хезмәте – дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән чикләрдә мөрәҗәгать итүче соравы буенча башкарыла торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарган вакытта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек;
- дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе $1^1$ бүлегендә каралган оешмалар яки аларның эшчеләре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта бозылган хокукларны яки законлы мәнфәгатьләрне кире кайтару яки саклау турында таләбе.
- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яки муниципаль учреждениенең  оештыру-хокукый формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирүче һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча, вәкаләтле оешма;
- «бер тәрәзә» принцибы – мөрәҗәгать итүче 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ маддәсендә күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү, ә дәүләт хезмәт күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар белән күпфункцияле үзәк тарафыннан мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актлар һәм хезмәттәшлек итү турында килешү нигезендә хезмәттәшлек алып бару принцибы.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбе исеме | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Хезмәт күрсәтү исеме | Ятим балалар өчен оешмаларда яшәүче һәм әти-әнисез калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча бирү мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү | 432 нче номерлы Кагыйдәләр |
| 2.2. Хезмәт күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты (опекага алынган кешенең яшәү урыны буенча) | |
| 2.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Рөхсәт яки баш тарту турында опека һәм попечительлек секторы нәтиҗәсе | 432 нче Кагыйдәләр |
| 2.4. Хезмәт күрсәтү вакыты | Мөрәҗәгать итүчедән барлык кирәкле документларны алганнан соң 15 көн эчендә | |
| 2.5. Закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәте өчен кирәк һәм мәҗбүри булган документларның тулы исемлеге | 1) гариза (1 Кушымта)<br>2) паспорт яки шәхесне раслаучы башка документ күчермәсе (төп нөсхәсен күрсәтеп)<br>3) дәвалау-профилактика учреждениесеннән гражданинда авырулар булмау турында белешмә (медицина нәтиҗәсе)<br>Гражданин бала тәрбияләү һәм укыту буенча белемнәрен раслаучы башка документлар, шул исәптән белем алу, профессиональ эшчәнлек, опекага алучы яки попечительлеккә кандидатлар әзерләү программаларын үтү турында документлар<br><br>*3 пункт белән каралган документ опека һәм попечительлек секторы тарафыннан аны биргән көннән соң 6 ай эчендә кабул ителә.* | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм алар бирергә хокуклы булган документларның тулы исемлеге | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:<br>- гражданинның кеше тормышына һәм сәламәтлегенә каршы алдан уйланылган җинаять кылган өчен хөкемгә тартылмавы турында эчке эшләр органыннан белешмә (гариза бирүче рөхсәте белән);<br>- гражданин белән бергә яшәүче балигъ булган һәм балигъ булмаган гаилә әгъзалары турында мәгълүмат кертелгән йорт (фатир) кенәгәсеннән өземтә;<br>- гражданинның яшәү урыны буенча торак-көнкүреш шартларын тикшерү акты (әгәр бала (балалар) вакытлыча яшәячәк торак бинасы гражданинның яшәү урыны булып тормаса) | |
| 2.7. Норматив хокукый актлар белән каралган очракларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган һәм хезмәт күрсәтә торган башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла торган дәүләт хакимияте һәм аның структур | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| бүлекчәләре исемлеге | | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Гражданинның яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итмәве | |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Опека һәм попечительлек органына гариза белән мөрәҗәгать иткән гражданинга (гражданнарга) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту, әгәр гариза бирүче (ләр) түбәндәге категорияләргә караса:<br>а) суд тарафыннан эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы дип танылган затлар;<br>б) суд тарафыннан әти-әни хокукыннан мәхрүм ителгән яки әти-әни хокукы чикләнгән затлар;<br>в) элек уллыкка алучылар, әгәр уллыкка алу суд тарафыннан алар гаебе белән кире кагылса;<br>г) закон тарафыннан йөкләнгән вазыйфаларны тиешенчә үтәмәгән өчен опекага алучы (попечитель) вазыйфаларыннан читләштерелгән затлар;<br>е) ачык формада йогышлы авырулар яки психик авырулар, наркомания, токсикомания, эчкечелек белән авыручы затлар;<br>ж) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәү урыны булмаган затлар.<br>2. Тапшырылган документларның 2.5. пунктындагы документлар исемлегенә туры килмәве.<br>3. Гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокук бирергә нигез булып торучы тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүмат бирү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган. | 432 нче Кагыйдәләр |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә. | |
| 2.11. Әлеге түләүне исәпләү турында мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргән вакытта һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алган вакытта чиратта көтүнең максималь вакыты | Көтеп утыруның (хезмәт күрсәтүнең) максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Аерым категория кешеләр өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты | Гариза кергән көнне | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | 1. Гариза түбәндәге адрес буенча тапшырыла:<br>Арча шәһәре, Советлар мәйданы урамы, 12 йорт, опека һәм попечительлек секторы.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазланган бинада башкарыла;<br>3. Бинада гаризалар кабул итү өчен сектор белгеченең эш урыны хезмәтне тулысынча күрсәтергә мөмкинлек бирүче электрон белешмә-хокукый | Вазыйфаи регламентлар, вазыйфаи күрсәтмәләр |

| | | |
|---|---|---|
| | системалар, оргтехника белән тәэмин ителгән шәхси компьютер белән җиһазландырыла.<br>4. Документлар тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазлана һәм документлар тутыру үрнәкләре белән тәэмин ителә.<br>5. Инвалидларга хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыкларсыз керү тәэмин ителә, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм чыгу юлларына, дәүләт хезмәте күрсәтү урынына барып җитү максатында объект буйлап мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итү тәэмин ителә.<br>6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны исәпкә алып, урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Хезмәт күрсәтүнең аңлаешлылыгы һәм сыйфаты күрсәткечләре:<br>1) документларны кабул итү һәм карау вакытын саклау;<br>2) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу вакытын саклау;<br>3) гариза бирүченең яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек секторы урнашуы.<br>Хезмәт күпфункцияле үзәктә күрсәтелми. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Хезмәт электрон формада күрсәтелми | |

## 3. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкару составы, эзлеклелеге һәм вакыты, аларны башкару тәртибенә таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау:
3.1.1. Ятим балалар өчен оешмаларда яшәүче һәм эти-әнисез калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча бирү мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:
1) гариза бирүчеләргә консультация бирү;
2) гариза бирүчене кабул итү, документларны теркәү (әлеге регламентның 2.5 пунктын кара);
3) гариза бирүченең торак-көнкүреш шартларын тикшерү (2 Кушымта);
4) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратып алулар эшләү һәм җибәрү;
5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булуын тикшерү;
6) ятим балалар өчен оешмаларда яшәүче һәм эти-әнисез калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча бирү мөмкинлеге турында нәтиҗә әзерләү;
7) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү (3 Кушымта);
8) нигезләр булган очракта гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү (җибәрү).
3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема әлеге Административ регламентка 5 Кушымтада бирелә.

3.2. Консультация күрсәтү
Мәгълүмат һәм консультация бирү буенча процедуралар кысаларында гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:
- дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибен җайлаучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;
- ятим балалар өчен оешмаларда яшәүче һәм эти-әнисез калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча бирү мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән таныштыра;
- ятим балалар өчен оешмаларда яшәүче һәм эти-әнисез калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча бирүгә нәтиҗә бирү өчен кирәкле документлар исемлеген бирә.
Консультация гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.
Процедура нәтиҗәсе: документлар составы һәм хезмәт күрсәтү буенча башка сораулар буенча консультация.
Гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирүче белгеч, шәхси мәгълүматларны исәпкә алып, консультациянең грамоталыгы, тулылыгы һәм ачыклыгы өчен шәхси җавап бирә.
3.3. Гариза бирүче, 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән үзе гариза тапшыра.
Опека һәм попечительлек секторы белгече:
- гражданинның шәхесен, опекага алынган кешенең тору урынын билгели;
- документларның барлыгын тикшерә. Кирәкле документлар булмаган очракта җитмәгән документларны тапшырырга тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларны кабул итүне таләп итсә, документлар кабул ителә.
Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта опека һәм попечительлек, күпфункцияле үзәк белгече гариза бирүчегә гариза һәм документлар алу, теркәлү номеры турында хәбәр итә, аннан соң әлеге Регламентның 3.4. подпунктында күрсәтелгән процедуралар башкарыла.
Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән вакыттан соң 1 көн эчендә 15 минут вакыт аралыгында башкарыла.
Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язмасы.
Гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирүче белгеч, шәхси мәгълүматларны исәпкә алып, консультациянең грамоталыгы, тулылыгы һәм ачыклыгы өчен шәхси җавап бирә.
3.4 Опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүче тапшырган документлардагы мәгълүматны тикшерә.
Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергәннән соң 2 эш көне эчендә башкарыла.
Процедуралар нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәт бирү яки баш тарту турында карар кабул итү.
3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратып алу әзерләү һәм җибәрү.
3.5.1 Опека һәм попечительлек белгече (гариза бирүче белән килештереп) ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү системасы аркылы әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны җибәрү турында электрон формада соратып алу юллый.
Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән көннән 2 эш көне эчендә башкарыла.
Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында юлланган соратып алу.
3.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы опека һәм попечительлек секторы органнары соратуы буенча автоматлаштырылган режимда башкарыла:
- соратып алуны эшкәртү һәм соратылган мәгълүматны эзләү;
- ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү аркылы соратып алынган мәгълүматны формалаштыру, соратып алынган мәгълүмат булмаган очракта, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, соратып алынган мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе җибәрү.
Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар опека һәм попечительлек органнарына соратып алу кергән вакыттан 5 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: соратып алуга җавап яки әлеге Регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе.
3.6. Гариза бирүченең торак-көнкүреш шартларын тикшерү.
3.6.1. Опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүченең торак-көнкүреш шартларын, сәбәпләрен, аның бала тәрбияләүгә сәләтен, гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләрне тикшерә.
Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң 3 эш көне эчендә башкарыла.
Процедуралар нәтиҗәсе: гариза бирүченең торак-көнкүреш шартларын тикшерү.
3.6.2. Гражданинның тормыш шартларын тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерү акты рәсмиләштерелә, ул тикшерү үткәргән затларның имзалары белән һәм сектор җитәкчесе тарафыннан раслана.
Әгәр гражданинның тормыш шартларын тикшерү үткәргән вакытта баланың гомеренә һәм сәламәтлегенә, аның физик һәм рухи үсешенә куркыныч тудыручы яки тудырырга мөмкин булган яки аның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозарга мөмкин булган очраклар ачыкланса, опека һәм попечительлек органы гражданиннан өстәмә рәвештә язмача соратып алырга мөмкин:
а) бала вакытлыча яшәячәк торак бинага гражданинның милек хокукын яки куллану хокукын раслаучы документлар күчермәләрен;
б) гражданин белән бергә яшәүче гаилә әгъзаларының ачык формадагы йогышлы авырулар, психик авырулар белән авырмавы турында дәвалау-профилактика учреждениесе белешмәсе. Белешмә урынына гаилә әгъзалары дәвалау-профилактика учреждениесе тарафыннан бирелгән медицина нәтиҗәсен бирергә хокуклы. Әлеге документлар опека һәм попечительлек органы тарафыннан аларны биргән көннән соң 6 ай эчендә кабул ителә.
Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә башкарыла.
Процедуралар нәтиҗәсе: вакытлыча балаларны алырга теләгән гражданинның тормыш шартларын тикшерү акты (әлеге Регламентка 2 Кушымта) яки гариза бирүчедән 3.6.2 пункты «а» һәм «б» подпунктлары белән каралган документларны язмача соратып алу.
3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.
3.7.1. Тапшырылган документлар нигезендә опека һәм попечительлек секторы белгече ятим балалар өчен оешмаларда яшәүче һәм әти-әнисез калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча бирү мөмкинлеге турында нәтиҗә проекты әзерли һәм аны килештерү һәм раслату өчен опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә җибәрә яки тиешле аныклау белән баш тарту турында хат әзерли.
Әгәр гражданинның яшәү урыны буенча торак бинасы торак пункт шартларына карата төзекләндерелгән булмаса, яки баланы әлеге торак бинада калдыру аның тормышына, сәламәтлегенә, физик һәм рухи үсешенә куркыныч тудырса, гражданинның яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органы баланы (балаларны) әлеге торак бинада яшәмәү шарты белән вакытлыча бирү мөмкинлеге турында нәтиҗә чыгарырга хокуклы. Шул ук вакытта гражданин хокуклы:
ятим балалар өчен һәм әти-әнисез калган балалар өчен оешмаларның көн тәртибе нигезендә көндезге сәгатьләрдә баланы (балаларны) алырга;
ятим балалар һәм әти-әнисез калган балалар өчен оешмага туристик юллама күрсәтеп, бала (балалар) белән санатор-курорт һәм ял, дәвалау-савыктыру, физкультура-спорт һәм башка объектлар территорияләренә ял (савыктыру) итәргә барырга;
бала (балалар) белән гражданинның яшәү урыны булмаган торак бинада булырга.
Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң 1 көн эчендә башкарыла.
Процедуралар нәтиҗәсе: 3.9 пункты нигезендә ятим балалар өчен оешмаларда яшәүче һәм әти-әнисез калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча бирү мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү.
3.8. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен тапшыру.
3.8.1. Опека һәм попечительлек секторы белгече, имзаланган боерыкны алгач, аны терки һәм гариза бирүчегә тапшыра.
Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.7.1 подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 көн эчендә башкарыла.
Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.
3.9. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат тапшыру.
3.9.1 Опека һәм попечительлек секторы белгече рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты әзерли.
Әзерләнгән баш тарту турында хат проектын опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә юллый.
Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар баш тарту өчен нигезләр ачыкланган көннән соң 5 көн эчендә башкарыла.
Процедуралар нәтиҗәсе: имзалауга юлланган баш тарту турында хат проекты.
3.9.2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек секторы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек секторы белгеченә кайтара.
Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 1 эш көне эчендә башкарыла.
Процедуралар нәтиҗәсе: имзаланган баш тарту турында хат.
3.9.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече баш тарту турында хатны аны имзалаган көннән соң 1 эш көне эчендә гариза бирүчегә юллый. Шул ук вакытта гариза бирүчегә карарны шикаять итү тәртибе аңлатыла.
Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.7.2. подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә башкарыла.
Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формасы

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларын үтәүне тикшерүне, карар кабул итүне һәм күпфункцияле үзәкнең (хезмәт күпфункцияле үзәк аркылы күрсәтелсә), опека һәм попечительлек бүлегенең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап бирүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларының хокукый экспертизасын үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау;
- кабул итлегән тәртиптә делопроизводство алып баруны тикшерү;
- кабул ителгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү үткәрү процедураларына контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерү үткәргән вакытта дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык сораулар каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта һәм карар кабул иткән вакытта гамәлләрне башкаруны тикшерүне башкару максатында күпфункцияле үзәк, опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затлар исемлеге күпфункцияле үзәкнең, опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы гариза бирүченең мөрәҗәгатен вакытында карамаган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезләнмәгән рәвештә баш тарткан өчен җавап бирә.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, аларның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелгән очракта), опека һәм попечительлек секторы хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Арча муниципаль районы башкарма комитетына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итәргә мөкин:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;
2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;
3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган документлар, мәгълүмат яки гамәл кылу таләп ителгәндә;
4) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;
5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;
6) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;
7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;
8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү вакыты яки тәртибе бозылганда;
9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылганда, әгәр туктатылу нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса;
10) дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта мөрәҗәгать итүчедән беренче тапкыр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документлар тапшырган вакытта булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү.

5.2. Шикаять почта аркылы язма рәвештә кәгазь битендә яки электрон формада җибәрелергә, шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәткән очракта шикаять күпфункцияле үзәк аркылы җибәрелә ала.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең

документларны кабул итүдән баш тартуына яки киткән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять биргән очракта яки мондый төзәтүләрне башкаруның кабул ителгән вакыты бозылуга шикаять биргән очракта – аны теркәгән көннән соң 5 эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исемен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки муниципаль хезмәткәрнең исемен;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән риза булмавына дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә тасвирланган вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре теркәлгән булырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документлар исемлеге бирелә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәте күрсәтелүче зат тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта Башкарма комитет тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта ачыкланган бозуларны кичекмәстән бетерү максатында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле гамәлләр турында әйтелә.

5.9. Әгәр шикаять канәгатьләндерелмәсә, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул итлгән карарга нигезләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында аңлатма бирелә.

5.10. Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Ятим балалар өчен оешмаларда яшәүче һәм эти-әнисез калган
балаларны Россия Федерациясе территориясендә
даими рәвештә яшәүче балигъ булган гражданнар
гаиләләренә вакытлыча бирү мөмкинлеге турында
нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
1 Кушымта

Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитеты җитәкчесенә
_______________________________________________
(тулысынча фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
____________________________________________________
(тулы адрес)
адресы буенча яшәүче

телефон: ____________________________________________
паспорт:_____________________________________________
(серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

Опека һәм попечительлек органына
_____________________________________нән
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

**Баланы (балаларны) вакытлыча гаиләгә бирү мөмкинлеге турында опека һәм попечительлек органы нәтиҗәсе бирү турында гражданинның гаризасы**

Мин,_______________________________________________________________________
(фамилия, исем, әтисенең исеме)
Гражданлык________Шәхесне раслаучы документ:____________________
_________________________________________________________________________
(кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)
Адрес (теркәлү урыны буенча) ____________________________________________
_________________________________________________________________________
Адрес (яшәү урыны буенча)_______________________________________________
_________________________________________________________________________

☐ баланы (балаларны) вакытлыча гаиләгә бирү мөмкинлеге турында нәтиҗә бирүегезне сорыйм

☐ баланы (балаларны) вакытлыча гаиләгә бирү мөмкинлеге турында нәтиҗә бирүегезне сорыйм ____________________________________________________
____________________________________________________________________
(баланың (балаларның) фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туу көне, ае, елы)
_________________________________________________________________________
Торак шартлары, сәламәтлек һәм эш характеры миңа баланы (балаларны) вакытлыча гаиләгә алырга мөмкинлек бирә.
Өстәмә рәвештә үзем турында хәбәр итәм_____________________________
(гражданинның балалар тәрбияләү буенча
_________________________________________________________________________
белеме, шулай ук белем алу турында, профессиональ эшчәнлек,
_________________________________________________________________________
опекага алучы яки попечительлеккә кандидат программаларын үтү турында
_________________________________________________________________________
документлар, һ.б. күрсәтелә)
_________________________________________________________________________

Мин, ______________________________________________________________________,
(фамилия, исем, әтисенең исеме)

Әлеге гаризада һәм мин тапшырган документлардагы шәхси мәгълүматны эшкәртүгә һәм кулланугa рөхсәт бирәм.

__________________________

(имза, дата)

Гаризага түбәндәге документлар беркетелә:

☐ шәхесне раслаучы документ күчермәсе

☐ гражданинның гомеренә һәм сәламәтлегенә карата алдан уйланган җинаять өчен хөкемгә тартылмау турында эчке эшләр органы белешмәсе

☐ гражданин белән бергә яшәүче балигъ булган һәм балигъ булмаган гаилә әгъзалары турында мәгълүмат кертелгән йорт (фатир) кенәгәсеннән өземтә)

☐ ачык формада йогышлы авырулар, психик авырулар, наркомания, токсикомания, эчкечелек белән авырмау турында дәвалау-профилактика учреждениесе белешмәсе яки медицина нәтиҗәсе (баланы опекага (попечительлеккә) алырга яки тәрбиягә алырга теләүче гражданинны тикшерү медицина нәтиҗәсе)

Башка документлар:

1.

2.

3.

Ятим балалар өчен оешмаларда яшәүче һәм эти-әнисез
калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә
даими рәвештә яшәүче балигъ булган гражданнар
гаиләләренә вакытлыча бирү мөмкинлеге турында нәтиҗә
бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
2 Кушымта

**Форма N 164/у**
РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының
2014 елның 18 июнендәге 290 Н номерлы
әмере белән расланды

**Уллыкка (кызлыкка), опекага (попечительлеккә), тәрбиягә яки патронат гаиләгә ятим балаларны һәм эти-әнисез калган балаларны алырга теләгән гражданнарга медицина тикшерүе үткәрү нәтиҗәсе**

"__" ____________ 20__ ел

1. Бирелде____________________________________________________________
(медицина оешмасы исеме һәм адресы)
2. Нәтиҗә бирелә торган орган исеме ______________________
______________________________________________________________________
3. Фамилия, исем, әтисенең исеме _____________________________________________
(Уллыкка (кызлыкка), опекага (попечительлеккә), тәрбиягә яки патронат гаиләгә ятим балаларны һәм эти-әнисез калган балаларны алырга теләгән гражданинның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
4. Җенес (Хатын-кыз/ир-ат) ____________________________________________
5. Туу датасы ________________________________________________________
6. Яшәү урыны адресы ____________________________________________
7. Нәтиҗә (кирәкмәгәнен сызып ташларга):

Уллыкка (кызлыкка), опекага (попечительлеккә), тәрбиягә яки патронат гаиләгә ятим балаларны һәм эти-әнисез калган баланы алуга комачау итүче авырулар ачыкланды (ачыкланмады)<*>.

Табиблык комиссиясе рәисе: _____________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

_________________________ ______________________ ______________
(имза) (дата)

М.П.

--------------------------------
<*> "Уллыкка (кызлыкка), опекага (попечительлеккә), тәрбиягә яки патронат гаиләгә ятим балаларны һәм эти-әнисез калган балаларны алуга комачаулык итүче авырулар исемлеген раслау турында" 2013 елның 14 февралендәге 117 нче номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2013, №26, 4577 маддә).

Ятим балалар өчен оешмаларда яшәүче һәм эти-әнисез калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча бирү мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
3 Кушымта

**Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданинның тормыш шартларын тикшерү акты**

Тикшерү датасы "__" _________________ 20__ ел.

Тикшерү үткәргән кешенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), вазыйфасы ___________
_____________________________________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме

____________________________________________________________нең тормыш шартлары тикшерелде;

(булган очракта), туу көне)

Шәхесне раслаучы документ: ______________________________________________________
_____________________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________________

(кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)

Тору урыны (теркәү урыны буенча) _________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________

Яшәү урыны (яшәү урыны буенча)______________________________________________________________

Тикшерү барышында ачыкланды:

______________________________________________________________________ яшәүче торак мәйдан

фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта)

_____ кв. м тәшкил итә, _________________________ бүлмәдән тора, һәр бүлмәнең мәйданы: ___ кв.м, _____________ кв. м, ________ кв. м.

___этажда _______ этажлы йортта.

Йорт сыйфаты (кирпеч, панель, агач һ.б.; яхшы хәлдә, тузган, аварияле; бүлмәләр коры, якты, үтә торган, тәрәзәләр саны һ.б.) ____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________

Йорт һәм торак мәйданының төзекләндерелеше (су үткәргеч, канализация, җылыту, газ, ванна, лифт, телефон һ.б.):
_________________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________

Торак мәйданның санитар-гигиеник торышы (яхшы, канәгатьләнерлек, канәгатьләнерлек түгел)
_____________________________________________________________________________________

Бала өчен сектор бүлмәсе, җиһаз, уен урыны булу
_____________________________________________________________________________________

Торак мәйданда яши (тиешле тәртиптә теркәлгән һәм чынлап яши):

| Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта) | Туу елы | Эш урыны, вазыйфасы яки уку урыны | Туганлык мөнәсәбәтләре | Кайчаннан әлеге торак мәйданда яши |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

Гражданинның гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәт ____________________________________
_____________________________________________________________________________________

(гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәт характеры, балалар белән аралашу үзенчәлекләре, баланы
______________________________________________________________________

(балаларны) вакытлыча гаиләгә бирүгә туганнарның мөнәсәбәте һ.б.)

Тикшерүнең өстәмә мәгълүматы __________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________.

Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданинның тормыш шартлары
_____________________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________

(Канәгатьләнерлек/канәгатьләнерлек түгел конкрет шартларны күрсәтеп)

Тикшерү үткәргән затның имзасы ____________________________________

________________________________ ______________ _______________________

(опека һәм попечительлек органы җитәкчесе) (имза) (фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

М.П.

Ятим балалар өчен оешмаларда яшәүче һәм эти-әнисез
калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә
даими рәвештә яшәүче балигъ булган гражданнар
гаиләләренә вакытлыча бирү мөмкинлеге турында
нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
4 Кушымта

**Баланы (балаларны) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданин гаиләсенә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге урында опека һәм попечительлек органы нәтиҗәсе**

Фамилия, исем, әтисенең исеме_______________________________________________
Туу датасы____________________________________________________________
Адрес (теркәү урыны буенча)____________________________________________
_______________________________________________________________________
Адрес (яшәү урыны буенча)______________________________________________
_______________________________________________________________________
Гаилә характеристикасы (состав, балалар, яшьләрен күрсәтеп, балалар белән аралашу тәҗрибәсе, гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәт, якын туганнар булуы һәм аларның баланы (балаларны) вакытлыча гаиләгә тапшыруга мөнәсәбәте һ.б.)__________________________________________________
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________

Белеме һәм профессиональ эшчәнлеге______________________________

Сәламәтлеге(сәламәтлек буенча гомуми хәле, баланы (балаларны) вакытлыча гаиләгә тапшыруга комачаулаучы авырулар булмавы)
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
Баланы ваккытлыча гаиләгә тапшыру сәбәпләре____________________
_______________________________________________________________________
_______________________ гражданин тапшырган документларда
(фамилия, исем, әтисенең исеме)
баланы (балаларны) вакытлыча гаиләгә тапшыруга комачаулаучы шартлар
_______________________________________________________________________
(бар/юк, конкрет шартларны күрсәтеп)
_______________________________________________________________ гражданин
(фамилия, исем, әтисенең исеме)
гаиләсенә баланы (балаларны) вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында нәтиҗә
_______________________________________________________________________
(мөмкин/ гражданинның торак бинасында яшәмәү шарты белән мөмкин/
_______________________________________________________________________
мөмкин түгел, сәбәпләрне күрсәтеп)

______________________________ ______________________ ____________________
(опека һәм попечительлек органы җитәкчесе) (имза) (фамилия, исем, әтисенең исеме)

М.П.

Ятим балалар өчен оешмаларда яшәүче һәм эти-әнисез

калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә
даими рәвештә яшәүче балигъ булган гражданнар
гаиләләренә вакытлыча бирү мөмкинлеге турында
нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
Кушымта (мәгълүмати)

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне агымдагы контрольдә тотучы җаваплы вазыйфаи затларның**
**РЕКВИЗИТЛАРЫ**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**


| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-84366 ) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |
| Сектор белгече | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-84366) 3-00-44 | Ispolkom.Arsk@tatar.ru |

Ятим балалар өчен оешмаларда яшәүче һәм эти-әнисез
калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә
даими рәвештә яшәүче балигъ булган гражданнар
гаиләләренә вакытлыча бирү мөмкинлеге турында
нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
6 Кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы**



Татарстан Республикасы Арча
муниципаль районы башкарма комитетының
«__»_________, 2019 ел, №_____
Карарына
11 Кушымта

**Балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү**
**Административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге регламент Арча муниципаль районы территориясендә яшәүче балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандарты һәм тәртипләрен билгели.

1.2. Хезмәтне алучылар: ундүрт яше тулган балигъ булмаган Россия Федерациясе гражданнары яки балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт алырга теләүче балигъ булмаган гражданнарның законлы вәкилләре (алга таба – гариза бирүчеләр).

1.3. Дәүләт хезмәте ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен башкаручы – балигъ булмаган затның яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (алга таба – опека һәм попечительлек органы).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

1.3.2. Опека һәм попечительлек органы урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

Эш режимы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш.

Төшке аш вакыты – 12.00 – 13.00.

Эчкә үтү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне аныклаучы документ буенча.

1.3.3. Опека һәм попечительлек органы телефоны: (84366)3–13–81.

1.3.4. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайты (алга таба – «Интернет» челтәре): http://www.arsk.tatarstan.ru.

1.3.5. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы бинасында урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аркылы;

2) «Интернет» челтәре аша:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында http://www.arsk.tatarstan.ru;

3) опека һәм попечительлек секторына шәхси мөрәҗәгать итеп;

4) күпфункцияле үзәктә (хезмәт күрсәтүне күпфункцияле үзәк аркылы алып булган очракта).

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә башкарыла:

- Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гражданлык кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 05.12.1994, №32, 3301 маддә);

- Россия Федерациясе Гаилә кодексы 1995 елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гаилә кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 01.01.1996, №1, 16 маддә);

- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 01 гыйнварындагы 48-ФЗ номерлы Федераль законы (алга таба – 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 28.04.2008, №17, 1755 маддә);

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр  күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 маддә);

- Татарстан Республикасы Гаилә кодексы 2009 елның 13 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы (алга таба – ТР Гаилә кодексы) (Республика Татарстан, 16.01.2009, №8);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №43-44, 02.03.2004, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары җыелмасы, №21, 26.05.2004);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №60-61, 25.03.2008);

- «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым

карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары;

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 15 августындагы боерыгы белән расланган Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында Нигезләмәсе (алга таба – опека секторы турнда Нигезләмә).

1.5.Әлеге Регламентта түбәндәге термин һәм билгеләмәләр кулланыла:

- административ регламент –Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралар һәм административ эшчәнлек вакытын һәм эзлеклелеген, структур бүлекчәләр һәм вазыйфаи затлар арасындагы хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хакимияте башкарма органнарының физик яки юридик затлар (алга таба – дәүләт хезмәте алучылар), башка дәүләт хезмәте һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгеләүче норматив хокукый документ;

- дәүләт хезмәте – дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән чикләрдә мөрәҗәгать итүче соравы буенча башкарыла торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарган вакытта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек;

- дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе $1^1$ бүлегендә каралган оешмалар яки аларның эшчеләре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта бозылган хокукларны яки законлы мәнфәгатьләрне кире кайтару яки саклау турында таләбе.

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яки муниципаль учреждениенең оештыру-хокукый формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирүче һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча, вәкаләтле оешма;

- «бер тәрәзә» принцибы – мөрәҗәгать итүче 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ маддәсендә күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү, ә дәүләт хезмәт күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар белән күпфункцияле үзәк тарафыннан мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актлар һәм хезмәттәшлек итү турында килешү нигезендә хезмәттәшлек алып бару принцибы.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбе исеме | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте исеме | Балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү | РФ Гаилә кодексының 60 маддәсе;<br>РФ Гражданлык кодексының 26, 28 маддәләре;<br>РФ Гражданлык кодексының 37 маддәсе;<br>48-ФЗ номерлы Федераль законның 21 маддәсе |
| 2.2. Хезмәт күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (балигъ булмаган затның яшәү урыны буенча) | 8-ТРЗ номерлы ТР Законы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль законның 21 маддәсе |
| 2.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Боерык формасында балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү яки хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат | РФ Гаилә кодексының 60 маддәсе;<br>ТР Гражданлык кодексының 37 маддәсе;<br>48-ФЗ номерлы Федераль законның 21 маддәсе |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты | Гражданнарның дәүләт хезмәте күрсәтүгә кагылышлы язма мөрәҗәгатьләрен карау аларны теркәгәннән соң 18 көн эчендә башкарыла | |
| 2.5. Закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәте өчен кирәк һәм мәҗбүри булган документларның тулы исемлеге | 1. әти-әнисенең икесенең дә (яки аларны алыштыручыларның) гаризасы;<br>2. законлы вәкиле ризалыгы белән эш итә торган 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге баланың гаризасы (2 Кушымта);<br>3. гариза бирүчеләрнең яки аларны алыштыручыларның паспортлары күчермәсе (1 бит + теркәлү);<br>4. баланың (балаларның), шул исәптән 14 яшьтән өлкәнрәкләренең туу турында таныклык күчермәсе;<br>5. балигъ булмаган зат милкендә булган (милек өлеше булган) торак бинага хокук билгеләү документлары күчермәләре;<br>6. техник паспорт күчермәсе яки техник инвентаризация бюросыннан белешмә;<br>Документлар күчермәсе төп нөсхә булган очракта 1 нөсхәдә тапшырыла. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм алар бирергә хокуклы булган документларның тулы исемлеге | балигъ булмаган баланың теркәлү урыныннан йорт (фатир) кенәгәсеннән өземтә; | |
| 2.7. Норматив хокукый актлар белән каралган очракларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган һәм хезмәт күрсәтә торган | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла торган дәүләт хакимияте һәм аның структур бүлекчәләре исемлеге | | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Гражданинның яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итмәве | |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>- тапшырылган документларның әлеге Административ регламентның 2.5 пукнтында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>- балигъ булмаган затның хокукларын кысу. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә. | |
| 2.11. Әлеге түләүне исәпләү турында мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргән вакытта һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алган вакытта чиратта көтүнең максималь вакыты | Көтеп утыруның (хезмәт күрсәтүнең) максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Аерым категория кешеләр өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты | Гариза кергән көнне | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | 1. Гариза түбәндәге адрес буенча тапшырыла:<br>Арча шәһәре, Советлар мәйданы урамы, 12 йорт, опека һәм попечительлек секторы.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазланган бинада башкарыла;<br>3. Бинада гаризалар кабул итү өчен сектор белгеченең эш урыны хезмәтне тулысынча күрсәтергә мөмкинлек бирүче электрон белешмә-хокукый системалар, оргтехника белән тәэмин ителгән шәхси компьютер белән җиһазландырыла.<br>4. Документлар тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазлана һәм документлар тутыру үрнәкләре белән тәэмин ителә.<br>5. Инвалидларга хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыкларсыз керү тәэмин ителә, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм чыгу юлларына, дәүләт хезмәте күрсәтү урынына барып җитү максатында объект буйлап мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итү тәэмин ителә.<br>6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны исәпкә алып, урнаштырыла. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Хезмәт күрсәтүнең аңлаешлылыгы күрсәткечләре:<br>1) гариза бирүче яшәгән районда опека һәм попечительлек органы булуы;<br>2) бинаның җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы;<br>3) җитәрлек белгечләр булу, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>4) мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә башкарма комитетның мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү бердәм порталында хезмәт күрсәтү тәртибе, ысуллары, вакыты турында тулы мәгълүмат булу;<br>Хезмәт күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре:<br>1) документларны кабул итү һәм карау вакытын саклау;<br>2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын саклау; | |
| 2.16. Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Хезмәт электрон формада күрсәтелми | |

### 3. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкару составы, эзлеклелеге һәм вакыты, аларны башкару тәртибенә таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау:

3.1.1. Балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчеләргә консультация бирү;

2) гаризаны һәм документларны кабул итү (әлеге регламентның 2.5 пунктын кара);

3) балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирүгә рөхсәт әзерләү;

4) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

5) нигезләр булган очракта гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема әлеге Административ регламентка 3 кушымтада бирелә.

3.2. Консультация күрсәтү

Мәгълүмат һәм консультация бирү буенча процедуралар кысаларында гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибен җайлаучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;

- гариза бирүчеләрне балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән таныштыра;

- балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеген бирә.

Консультация гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне күрсәтелә.

Процедура нәтиҗәсе: документлар составы һәм хезмәт күрсәтү буенча башка сораулар буенча консультация.

Консультация һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедуралар башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

3.3. Гариза, документлар кабул итү.

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән үзе опека һәм попечительлек секторына, күпфункцияле үзәккә (хезмәт күпфункцияле үзәк аркылы күрсәтелгән очракта) гариза һәм 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыра.

Кабул итү алып баручы опека һәм попечительлек секторы, күпфункцияле үзәк белгече:

- гариза бирүченең шәхесен, балигъ булмаган затның яшәү урынын билгели;

- документларның барлыгын тикшерә. Кирәкле документлар булмаган очракта җитмәгән документларны тапшырырга тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларны кабул итүне таләп итсә, документлар кабул ителә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта опека һәм попечительлек, күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелсә) белгече гариза бирүчегә гариза һәм документлар алу, теркәлү номеры турында хәбәр итә, аннан соң әлеге Регламентның 3.3.3. подпунктында күрсәтелгән процедуралар башкарыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән вакыттан соң 1 көн эчендә 15 минут вакыт аралыгында башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язмасы.

3.3.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүче тапшырган документлардагы мәгълүматны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергәннән соң 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәт бирү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратып алу әзерләү һәм җибәрү.

3.4.1 Опека һәм попечительлек белгече (гариза бирүче белән килештереп) ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү системасы аркылы әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны җибәрү турында электрон формада соратып алу юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән көннән 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында юлланган соратып алу.

3.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы опека һәм попечительлек секторы органнары соратуы буенча автоматлаштырылган режимда башкарыла:

- соратып алуны эшкәртү һәм соратылган мәгълүматны эзләү;

- ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү аркылы соратып алынган мәгълүматны формалаштыру, соратып алынган мәгълүмат булмаган очракта, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, соратып алынган мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар опека һәм попечительлек органнарына соратып алу кергән вакыттан 5 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: соратып алуга җавап яки әлеге Регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.5.1. Тапшырылган документлар нигезендә опека һәм попечительлек секторы белгече балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча боерык проекты әзерли һәм аны килештерү һәм раслату өчен опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә җибәрә яки тиешле аныклау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү турында боерык яки 3.7 пункты нигезендә әзерләнгән хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.6. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен тапшыру.

3.6.1. Опека һәм попечительлек секторы белгече, имзаланган боерыкны алгач, аны терки һәм гариза бирүчегә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.5.1 подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.7. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат тапшыру.

3.7.1 Опека һәм попечительлек секторы белгече боерык бирүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты (алга таба – баш атрту турында хат) әзерли.

Әзерләнгән баш тарту турында хат проектын Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар баш тарту өчен нигезләр ачыкланган көннән соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзалауга юлланган баш тарту турында хат проекты.

3.7.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек секторы белгеченә кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзаланган баш тарту турында хат.

3.7.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече баш тарту турында хатны аны имзалаган көннән соң 1 эш көне эчендә гариза бирүчегә юллый. Шул ук вакытта гариза бирүчегә карарны шикаять итү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.7.2. подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формасы

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларын үтәүне тикшерүне, карар кабул итүне һәм күпфункцияле үзәкнең (хезмәт күпфункцияле үзәк аркылы күрсәтелсә), опека һәм попечительлек бүлегенең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап бирүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларының хокукый экспертизасын үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау;

- кабул итлегән тәртиптә делопроизводство алып баруны тикшерү;

- кабул ителгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү үткәрү процедураларына контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерү үткәргән вакытта дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык сораулар каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта һәм карар кабул иткән вакытта гамәлләрне башкаруны тикшерүне башкару максатында күпфункцияле үзәк, опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затлар исемлеге күпфункцияле үзәкнең, опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы гариза бирүченең мөрәҗәгатен вакытында карамаган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезләнмәгән рәвештә баш тарткан өчен җавап бирә.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, аларның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелгән очракта), опека һәм попечительлек секторы хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Арча муниципаль районы башкарма комитетына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итәргә мөкин:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган документлар, мәгълүмат яки гамәл кылу таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү вакыты яки тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылганда, әгәр туктатылу нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта мөрәҗәгать итүчедән беренче тапкыр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документлар тапшырган вакытта булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү.

5.2. Шикаять почта аркылы язма рәвештә кәгазь битендә яки электрон формада җибәрелергә, шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәткән очракта шикаять күпфункцияле үзәк аркылы җибәрелә ала.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең документларны кабул итүдән баш тартуына яки киткән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять биргән очракта яки мондый төзәтүләрне башкаруның кабул ителгән вакыты бозылуга шикаять биргән очракта – аны теркәгән көннән соң 5 эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исемен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки муниципаль хезмәткәрнең исемен;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән риза булмавына дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә тасвирланган вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре теркәлгән булырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документлар исемлеге бирелә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәте күрсәтелүче зат тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта Башкарма комитет тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта ачыкланган бозуларны кичекмәстән бетерү максатында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле гамәлләр турында әйтелә.

5.9. Әгәр шикаять канәгатьләндерелмәсә, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул итлгән карарга нигезләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында аңлатма бирелә.

5.10. Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
1 Кушымта

______________________________________________
______________________________________________
_____________адресы буенча яшәүче
(тулы адрес)
___________________________________________ннән
(тулысынча фамилиясе, исеме)
_____________________________
Телефон:_____________________________________
Паспорт:_____________________________________
(серия,номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

ГАРИЗА

Мин,____________________________________________________________,
(фамилия, исем, әтисенең исеме)
балигъ булмаган балалар:___________________________________________________
_______________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туу көне)
_________________________________________________________________ исеменнән эш итүче,
_______________________________________________________________________

адресы буенча урнашкан, гомуми мәйданы _________________________________булган
_______________________________________________________________________
өстенлекле алу хокукыннан баш тартам.
Сәбәбе: __________________________________________________________.
(искәрмә: ихтыяҗ булмау сәбәпле, акча булмау сәбәпле һ.б.)
Минем балигъ булмаган балаларымның ______________________________
(фамилия, исем, әтисенең исеме)
Хокуклары кысылмый, чөнки аларның,_____________________________________________________
(фамилия, исем, әтисенең исеме)
адресы буенча теркәлгән, ________________________________________________
адресы буенча урнашкан йортта (фатирда) ___________________өлешләре бар.

Минем шәхси мәгълүматларым белән эшләүгә ризалык бирәм.

____________________ ________________
(дата) (имза)

Балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән
сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан
рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
2 Кушымта

Әнисе (этисе, опекага алучы) ризалыгы белән эш итүче,
______________________________________________
______________________________________________
______________адресы буенча яшәүче
(тулы адрес)
___________________________________________ннән
(тулысынча фамилиясе, исеме)
_____________________________
Телефон:______________________________________
Паспорт:______________________________________
(серия,номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

ГАРИЗА

Мин,____________________________________________________________,
(фамилия, исем, этисенең исеме)
__________________________________________________________________________

адресы буенча урнашкан, гомуми мәйданы __________________________________булган
__________________________ өстенлек сатып алу хокукыннан баш тартуга рөхсәт бирүегезне сорыйм,

чөнки ____________________________________________________________адресы буенча
эти-әниләр белән яшим, _____________________________________________________
адресы буенча урнашкан йортта (фатирда) ____________________өлешем бар

Минем шәхси мәгълүматларым белән эшләүгә рөхсәт бирәм.

____________________ ________________

(дата) (имза)

Балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән
сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
Кушымта (мәгълүмати)

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне агымдагы контрольдә тотучы җаваплы вазыйфаи затларның**
**РЕКВИЗИТЛАРЫ**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**


| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-84366 ) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |
| Сектор белгече | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-84366) 3-00-44 | Ispolkom.Arsk@tatar.ru |

Балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән
сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан
рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
4 Кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтүбуенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы**



Татарстан Республикасы Арча
муниципаль районы башкарма комитетының
«__»_________, 2019 ел, №_____
Карарына
11 Кушымта

Балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү

Административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге регламент Арча муниципаль районы территориясендә яшәүче балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандарты һәм тәртипләрен билгели.

1.2. Хезмәтне алучылар: ундүрт яше тулган балигъ булмаган Россия Федерациясе гражданнары яки балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт алырга теләүче балигъ булмаган гражданнарның законлы вәкилләре (алга таба – гариза бирүчеләр).

1.3. Дәүләт хезмәте ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен башкаручы – балигъ булмаган затның яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (алга таба – опека һәм попечительлек органы).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

1.3.2. Опека һәм попечительлек органы урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

Эш режимы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш.

Төшке аш вакыты – 12.00 – 13.00.

Эчкә үтү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне аныклаучы документ буенча.

1.3.3. Опека һәм попечительлек органы телефоны: (84366)3–13–81.

1.3.4. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайты (алга таба – «Интернет» челтәре): http://www.arsk.tatarstan.ru.

1.3.5. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы бинасында урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аркылы;

2) «Интернет» челтәре аша:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында http://www.arsk.tatarstan.ru;

3) опека һәм попечительлек секторына шәхси мөрәҗәгать итеп;

4) күпфункцияле үзәктә (хезмәт күрсәтүне күпфункцияле үзәк аркылы алып булган очракта).

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә башкарыла:

- Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гражданлык кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 05.12.1994, №32, 3301 маддә);

- Россия Федерациясе Гаилә кодексы 1995 елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гаилә кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 01.01.1996, №1, 16 маддә);

- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 01 гыйнварындагы 48-ФЗ номерлы Федераль законы (алга таба – 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 28.04.2008, №17, 1755 маддә);

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр  күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 маддә);- Татарстан Республикасы Гаилә кодексы 2009 елның 13 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы (алга таба – ТР Гаилә кодексы) (Республика Татарстан, 16.01.2009, №8);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №43-44, 02.03.2004, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары җыелмасы, №21, 26.05.2004);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №60-61, 25.03.2008);

- «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары;

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 15 августындагы боерыгы белән расланган Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында Нигезләмәсе (алга таба – опека секторы турнда Нигезләмә).

1.5.Әлеге Регламентта түбәндәге термин һәм билгеләмәләр кулланыла:

- административ регламент –Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралар һәм административ эшчәнлек вакытын һәм эзлеклелеген, структур бүлекчәләр һәм вазыйфаи затлар арасындагы хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хакимияте башкарма органнарының физик яки юридик затлар (алга таба – дәүләт хезмәте алучылар), башка дәүләт хезмәте һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгеләүче норматив хокукый документ;

- дәүләт хезмәте – дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән чикләрдә мөрәҗәгать итүче соравы буенча башкарыла торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарган вакытта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек;

- дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе $1^1$ бүлегендә каралган оешмалар яки аларның эшчеләре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта бозылган хокукларны яки законлы мәнфәгатьләрне кире кайтару яки саклау турында таләбе.

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яки муниципаль учреждениенең оештыру-хокукый формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирүче һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча, вәкаләтле оешма;

- «бер тәрәзә» принцибы – мөрәҗәгать итүче 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ маддәсендә күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү, ә дәүләт хезмәт күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар белән күпфункцияле үзәк тарафыннан мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актлар һәм хезмәттәшлек итү турында килешү нигезендә хезмәттәшлек алып бару принцибы.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбе исеме | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте исеме | Балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү | РФ Гаилә кодексының 60 маддәсе;<br>РФ Гражданлык кодексының 26, 28 маддәләре;<br>РФ Гражданлык кодексының 37 маддәсе;<br>48-ФЗ номерлы Федераль законның 21 маддәсе |
| 2.2. Хезмәт күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (балигъ булмаган затның яшәү урыны буенча) | 8-ТРЗ номерлы ТР Законы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль законның 21 маддәсе |
| 2.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Боерык формасында балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү яки хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат | РФ Гаилә кодексының 60 маддәсе;<br>ТР Гражданлык кодексының 37 маддәсе;<br>48-ФЗ номерлы Федераль законның 21 маддәсе |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты | Гражданнарның дәүләт хезмәте күрсәтүгә кагылышлы язма мөрәҗәгатьләрен карау аларны теркәгәннән соң 18 көн эчендә башкарыла | |
| 2.5. Закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәте өчен кирәк һәм мәҗбүри булган документларның тулы исемлеге | 1. әти-әнисенең икесенең дә (яки аларны алыштыручыларның) гаризасы;<br>2. законлы вәкиле ризалыгы белән эш итә торган 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге баланың гаризасы (2 Кушымта);<br>3. гариза бирүчеләрнең яки аларны алыштыручыларның паспортлары күчермәсе (1 бит + теркәлү);<br>4. баланың (балаларның), шул исәптән 14 яшьтән өлкәнрәкләренең туу турында таныклык күчермәсе;<br>5. балигъ булмаган зат милкендә булган (милек өлеше булган) торак бинага хокук билгеләү документлары күчермәләре;<br>6. техник паспорт күчермәсе яки техник инвентаризация бюросыннан белешмә;<br>Документлар күчермәсе төп нөсхә булган очракта 1 нөсхәдә тапшырыла. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм алар бирергә хокуклы булган документларның тулы исемлеге | балигъ булмаган баланың теркәлү урыныннан йорт (фатир) кенәгәсеннән өземтә; | |
| 2.7. Норматив хокукый актлар белән каралган очракларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган һәм хезмәт күрсәтә торган | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла торган дәүләт хакимияте һәм аның структур бүлекчәләре исемлеге | | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Гражданинның яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итмәве | |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>- тапшырылган документларның әлеге Административ регламентның 2.5 пукнтында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>- балигъ булмаган затның хокукларын кысу. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә. | |
| 2.11. Әлеге түләүне исәпләү турында мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргән вакытта һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алган вакытта чиратта көтүнең максималь вакыты | Көтеп утыруның (хезмәт күрсәтүнең) максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Аерым категория кешеләр өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты | Гариза кергән көнне | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | 1. Гариза түбәндәге адрес буенча тапшырыла:<br>Арча шәһәре, Советлар мәйданы урамы, 12 йорт, опека һәм попечительлек секторы.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазланган бинада башкарыла;<br>3. Бинада гаризалар кабул итү өчен сектор белгеченең эш урыны хезмәтне тулысынча күрсәтергә мөмкинлек бирүче электрон белешмә-хокукый системалар, оргтехника белән тәэмин ителгән шәхси компьютер белән җиһазландырыла.<br>4. Документлар тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазлана һәм документлар тутыру үрнәкләре белән тәэмин ителә.<br>5. Инвалидларга хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыкларсыз керү тәэмин ителә, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм чыгу юлларына, дәүләт хезмәте күрсәтү урынына барып җитү максатында объект буйлап мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итү тәэмин ителә.<br>6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны исәпкә алып, урнаштырыла. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Хезмәт күрсәтүнең аңлаешлылыгы күрсәткечләре:<br>1) гариза бирүче яшәгән районда опека һәм попечительлек органы булуы;<br>2) бинаның җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы;<br>3) җитәрлек белгечләр булу, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>4) мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә башкарма комитетның мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү бердәм порталында хезмәт күрсәтү тәртибе, ысуллары, вакыты турында тулы мәгълүмат булу;<br>Хезмәт күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре:<br>1) документларны кабул итү һәм карау вакытын саклау;<br>2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын саклау; | |
| 2.16. Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Хезмәт электрон формада күрсәтелми | |

## 3. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкару составы, эзлеклелеге һәм вакыты, аларны башкару тәртибенә таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау:

3.1.1. Балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчеләргә консультация бирү;

2) гаризаны һәм документларны кабул итү (әлеге регламентның 2.5 пунктын кара);

3) балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирүгә рөхсәт әзерләү;

4) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

5) нигезләр булган очракта гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема әлеге Административ регламентка 3 кушымтада бирелә.

3.2. Консультация күрсәтү

Мәгълүмат һәм консультация бирү буенча процедуралар кысаларында гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибен җайлаучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;

- гариза бирүчеләрне балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән таныштыра;

- балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеген бирә.

Консультация гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне күрсәтелә.

Процедура нәтиҗәсе: документлар составы һәм хезмәт күрсәтү буенча башка сораулар буенча консультация.

Консультация һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедуралар башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

3.3. Гариза, документлар кабул итү.

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән үзе опека һәм попечительлек секторына, күпфункцияле үзәккә (хезмәт күпфункцияле үзәк аркылы күрсәтелгән очракта) гариза һәм 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыра.

Кабул итү алып баручы опека һәм попечительлек секторы, күпфункцияле үзәк белгече:

- гариза бирүченең шәхесен, балигъ булмаган затның яшәү урынын билгели;

- документларның барлыгын тикшерә. Кирәкле документлар булмаган очракта җитмәгән документларны тапшырырга тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларны кабул итүне таләп итсә, документлар кабул ителә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта опека һәм попечительлек, күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелсә) белгече гариза бирүчегә гариза һәм документлар алу, теркәлү номеры турында хәбәр итә, аннан соң әлеге Регламентның 3.3.3. подпунктында күрсәтелгән процедуралар башкарыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән вакыттан соң 1 көн эчендә 15 минут вакыт аралыгында башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язмасы.

3.3.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүче тапшырган документлардагы мәгълүматны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергәннән соң 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәт бирү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратып алу әзерләү һәм җибәрү.

3.4.1 Опека һәм попечительлек белгече (гариза бирүче белән килештереп) ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү системасы аркылы әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны җибәрү турында электрон формада соратып алу юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән көннән 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында юлланган соратып алу.

3.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы опека һәм попечительлек секторы органнары соратуы буенча автоматлаштырылган режимда башкарыла:

- соратып алуны эшкәртү һәм соратылган мәгълүматны эзләү;

- ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү аркылы соратып алынган мәгълүматны формалаштыру, соратып алынган мәгълүмат булмаган очракта, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, соратып алынган мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар опека һәм попечительлек органнарына соратып алу кергән вакыттан 5 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: соратып алуга җавап яки әлеге Регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.5.1. Тапшырылган документлар нигезендә опека һәм попечительлек секторы белгече балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча боерык проекты әзерли һәм аны килештерү һәм раслату өчен опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә җибәрә яки тиешле аныклау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү турында боерык яки 3.7 пункты нигезендә әзерләнгән хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.6. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен тапшыру.

3.6.1. Опека һәм попечительлек секторы белгече, имзаланган боерыкны алгач, аны терки һәм гариза бирүчегә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.5.1 подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.7. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат тапшыру.

3.7.1 Опека һәм попечительлек секторы белгече боерык бирүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты (алга таба – баш атрту турында хат) әзерли.

Әзерләнгән баш тарту турында хат проектын Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар баш тарту өчен нигезләр ачыкланган көннән соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзалауга юлланган баш тарту турында хат проекты.

3.7.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек секторы белгеченә кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзаланган баш тарту турында хат.

3.7.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече баш тарту турында хатны аны имзалаган көннән соң 1 эш көне эчендә гариза бирүчегә юллый. Шул ук вакытта гариза бирүчегә карарны шикаять итү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.7.2. подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формасы

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларын үтәүне тикшерүне, карар кабул итүне һәм күпфункцияле үзәкнең (хезмәт күпфункцияле үзәк аркылы күрсәтелсә), опека һәм попечительлек бүлегенең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап бирүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларының хокукый экспертизасын үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау;
- кабул итлегән тәртиптә делопроизводство алып баруны тикшерү;
- кабул ителгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү үткәрү процедураларына контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерү үткәргән вакытта дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык сораулар каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта һәм карар кабул иткән вакытта гамәлләрне башкаруны тикшерүне башкару максатында күпфункцияле үзәк, опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затлар исемлеге күпфункцияле үзәкнең, опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы гариза бирүченең мөрәҗәгатен вакытында карамаган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезләнмәгән рәвештә баш тарткан өчен җавап бирә.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, аларның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелгән очракта), опека һәм попечительлек секторы хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Арча муниципаль районы башкарма комитетына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итәргә мөкин:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган документлар, мәгълүмат яки гамәл кылу таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү вакыты яки тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылганда, әгәр туктатылу нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта мөрәҗәгать итүчедән беренче тапкыр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документлар тапшырган вакытта булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү.

5.2. Шикаять почта аркылы язма рәвештә кәгазь битендә яки электрон формада җибәрелергә, шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәткән очракта шикаять күпфункцияле үзәк аркылы җибәрелә ала.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең документларны кабул итүдән баш тартуына яки киткән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять биргән очракта яки мондый төзәтүләрне башкаруның кабул ителгән вакыты бозылуга шикаять биргән очракта – аны теркәгән көннән соң 5 эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исемен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки муниципаль хезмәткәрнең исемен;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән риза булмавына дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә тасвирланган вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре теркәлгән булырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документлар исемлеге бирелә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәте күрсәтелүче зат тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта Башкарма комитет тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта ачыкланган бозуларны кичекмәстән бетерү максатында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле гамәлләр турында әйтелә.

5.9. Әгәр шикаять канәгатьләндерелмәсә, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул итлегән карарга нигезләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында аңлатма бирелә.

5.10. Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән
сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
1 Кушымта

_______________________________________________

_______________________________________________

______________адресы буенча яшәүче
(тулы адрес)

____________________________________________ннән
(тулысынча фамилиясе, исеме)

_____________________________

Телефон:______________________________________

Паспорт:______________________________________

(серия,номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

ГАРИЗА

Мин,_____________________________________________________________,

(фамилия, исем, әтисенең исеме)

балигъ булмаган балалар:___________________________________________________

_______________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туу көне)

_________________________________________________________________ исеменнән эш итүче,

_______________________________________________________________________

адресы буенча урнашкан, гомуми мәйданы _________________________________булган

_______________________________________________________________________

өстенлекле алу хокукыннан баш тартам.

Сәбәбе: _________________________________________________________.

(искәрмә: ихтыяҗ булмау сәбәпле, акча булмау сәбәпле һ.б.)

Минем балигъ булмаган балаларымның ______________________________

(фамилия, исем, әтисенең исеме)

Хокуклары кысылмый, чөнки аларның,_____________________________________________________

(фамилия, исем, әтисенең исеме)

адресы буенча теркәлгән, ___________________________________________________

адресы буенча урнашкан йортта (фатирда) ____________________өлешләре бар.

Минем шәхси мәгълүматларым белән эшләүгә ризалык бирәм.

____________________ ________________

(дата) (имза)

Балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән
сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
2 Кушымта

Әнисе (әтисе, опекага алучы) ризалыгы белән эш итүче,
______________________________________________
______________________________________________
_______________адресы буенча яшәүче
(тулы адрес)
____________________________________________ннән
(тулысынча фамилиясе, исеме)
_____________________________
Телефон:_____________________________________
Паспорт:_____________________________________
(серия,номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

ГАРИЗА

Мин,_____________________________________________________________,
(фамилия, исем, әтисенең исеме)
____________________________________________________________________________

адресы буенча урнашкан, гомуми мәйданы ________________________________булган
_____________________________ өстенлек сатып алу хокукыннан баш тартуга рөхсәт бирүегезне сорыйм,

чөнки _______________________________________________________________адресы буенча
әти-әниләр белән яшим, ____________________________________________________
адресы буенча урнашкан йортта (фатирда) ______________________өлешем бар

Минем шәхси мәгълүматларым белән эшләүгә рөхсәт бирәм.

______________________ ________________

(дата) (имза)

Балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән
сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
Кушымта (мәгълүмати)

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне агымдагы контрольдә тотучы җаваплы вазыйфаи затларның**
**РЕКВИЗИТЛАРЫ**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**


| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-84366 ) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |
| Сектор белгече | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-84366) 3-00-44 | Ispolkom.Arsk@tatar.ru |

Балигъ булмаган бала (балалар) исеменнән
сатып алуга өстенлекле хокуктан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
4 Кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтүбуенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы**



Татарстан Республикасы Арча муниципаль
районы башкарма комитетының
«__»_________, 2019 ел, №_____
Карарына
12 Кушымта

**Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка алучы булу мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү һәм уллыкка алучылыкка кандидат буларак теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү**
**Административ регламенты**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге регламент Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка алучы булу мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү һәм уллыкка алучылыкка кандидат буларак теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – хезмәт күрсәтү) стандарты һәм тәртипләрен билгели.

1.2. Хезмәт алучылар: уллыкка (кызлыкка) бала алырга теләүче, даими рәвештә Россия Федерациясе территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары.

1.3. Дәүләт хезмәте ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен башкаручы – балигъ булмаган затның яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (алга таба – опека һәм попечительлек органы).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

1.3.2. Опека һәм попечительлек органы урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

Эш режимы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш.

Төшке аш вакыты – 12.00 – 13.00.

Эчкә үтү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне аныклаучы документ буенча.

1.3.3. Опека һәм попечительлек органы телефоны: (84366)3–13–81.

1.3.4. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайты (алга таба – «Интернет» челтәре): http://www.arsk.tatarstan.ru.

1.3.5. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы бинасында урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аркылы;

2) «Интернет» челтәре аша:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында http://www.arsk.tatarstan.ru;

3) опека һәм попечительлек секторына шәхси мөрәҗәгать итеп;

4) күпфункцияле үзәктә (хезмәт күрсәтүне күпфункцияле үзәк аркылы алып булган очракта).

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә башкарыла:

- Россия Федерациясе Конституциясе (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 26.01.2009, №4, 445 маддә);

- Россия Федерациясе Гаилә кодексы (алга таба – РФ Гаилә кодексы) (РФ законнар җыентыгы, 01.01.1996, №1, 16 маддә);

- «Әти-әнисез калган балалар турында дәүләт банкы турында» 2001 елның 16 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон (РФ Законнар җыентыгы, 23.04.2001, №17, 1643 маддә);

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 маддә);

- «Балаларны уллыкка (кызлыкка) бирү кагыйдәләрен һәм Россия Федерациясе территориясендә уллыкка алган гаиләләрдә аларның тормыш һәм тәрбия шартлары контролен башкару һәм Россия Федерациясе консул учреждениеләре тарафыннан Россия Федерациясе гражданнары булган балаларны һәм чит ил гражданнары яки гражданствосыз затлар уллыкка алган балаларны исәпкә алу кагыйдәләрен раслау турында» 2000 елның 29 мартындагы 275 нче номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (алга таба – 275 номерлы РФ Хөкүмәте карары) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 10.04.2000, №15, 1590 маддә);

- Татарстан Республикасы Гаилә кодексы (алга таба – ТР Гаилә кодексы) (Республика Татарстан, №8, 16.01.2009);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №43–44, 02.03.2004, Татарстан Дәүләт Советы ведомосте, 2004, №2 (1 өлеш), 70 маддә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыелмасы, 26.05.2004, №21, 2021 маддә);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №60-61, 25.03.2008, «Татарстан Дәүләт Советы ведомосте», 2008, №3, 212 маддә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 15 августындагы боерыгы белән расланган Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында Нигезләмәсе (алга таба – опека секторы турнда Нигезләмә).

1.5.Әлеге Регламентта түбәндәге термин һәм билгеләмәләр кулланыла:

- административ регламент –Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралар һәм административ эшчәнлек вакытын һәм эзлеклелеген, структур бүлекчәләр һәм вазыйфаи затлар арасындагы хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хакимияте башкарма органнарының физик яки юридик затлар (алга таба – дәүләт хезмәте алучылар), башка дәүләт хезмәте һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгеләүче норматив хокукый документ;

- дәүләт хезмәте – дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән чикләрдә мөрәҗәгать итүче соравы буенча башкарыла торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарган вакытта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек;

- дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе $1^1$ бүлегендә каралган оешмалар яки аларның эшчеләре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта бозылган хокукларны яки законлы мәнфәгатьләрне кире кайтару яки саклау турында таләбе.

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яки муниципаль учреждениенең  оештыру-хокукый формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирүче һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча, вәкаләтле оешма;

- «бер тәрәзә» принцибы – мөрәҗәгать итүче 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ маддәсендә күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү, ә дәүләт хезмәт күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар белән күпфункцияле үзәк тарафыннан мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актлар һәм хезмәттәшлек итү турында килешү нигезендә хезмәттәшлек алып бару принцибы.

**2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты**

| Стандарт таләбе исеме | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү исеме | Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка алучы булу һәм уллыкка алучылыкка кандидат буларак теркәү мөмкинлеге турында турында нәтиҗә бирү | РФ Гаилә кодексының 19 бүлеге;<br>ТР Гаилә кодексының 19 бүлеге;<br>275 нче номерлы РФ Хөкүмәте карары |
| 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты опека һәм попечительлек секторы | РФ Гаилә кодексның 19 бүлеге;<br>ТР Гаилә кодексыңж 19 бүлеге;<br>7-ТРЗ номерлы ТР Законы |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Уллыкка алуга кандидат булу һәм уллыкка алуга кандидат сыйфатында исәпкә кую турында нәтиҗә бирү | РФ Гаилә кодексыңж 19 бүлеге;<br>ТР Гаилә кодексыңж 19 бүлеге;<br>275 нче номерлы РФ Хөкүмәте карары |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты | Гариза бирүченең гаризасын теркәгәннән соң 17 эш көне эчендә | 275 нче номерлы РФ Хөкүмәте карары |
| 2.5. Закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәте өчен кирәк һәм мәҗбүри булган документларның тулы исемлеге | - уллыкка (кызлыкка) бала алырга теләүче затларны исәпкә кую турында язмача гариза;<br>- паспорт яки шәхесне раслаучы башка документ, түбәндәге документларны теркәп:<br>1) кыскача автобиография;<br>2) уллыкка бала алырга теләүче затның эш урыныннан белешмә, вазыйфасын, соңгы 12 айга уртача хезмәт хакы күләмен күрсәтеп, һәм (яки) әлеге затның керемен раслаучы башка документ яки уллыкка бала алырга теләүче затның хатынының (иренең) эш урыныннан белешмә, вазыйфасын һәм соңгы 12 айга уртача хезмәт хакы күләмен күрсәтеп, һәм (яки) хатынының (иренең) керемен раслаучы башка документ;<br>3) уллыкка (кызлыкка) бала, опекага (попечительлеккә), асрамага яки патронат гаиләгә ятим балалар, әти-әнисез калган балалар алырга җыенучы гражданнарның медицина тикшерүе турында, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы белән билгеләнгән формада нәтиҗә;<br>4) гаилә кору (гаиләле кеше булса) турында таныклык күчермәсе;<br>5) РФ Гаилә кодексының 127 маддәсе, 6 пункты белән билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясендә гаиләгә әти-әнисез калган баланы тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү турында таныклык күчермәсе (баланың якын туганнарыннан, шулай ук элегрәк уллыкка алучылар булган затлардан, әгәр уллыкка алу кире кагылмаган булса, йөкләнгән вазыйфалардан читләштерелмәгән очракта элегрәк яки хәзер опекага алучы (попечитель) булып торучы затлардан тыш). | 275 нче номерлы РФ Хөкүмәте карары |

| | | |
|---|---|---|
| | Әлеге пукнтның 2 подпунктында саналган документлар аларны биргән көннән соң бер ел дәвамында гамәлдә, медицина тикшерүе турында нәтиҗә – 6 ай дәвамында. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм алар бирергә хокуклы булган документларның тулы исемлеге | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында белгеч тарафыннан соратып алына торган документлар:<br>1) РФ Гаилә кодексының 127 маддәсе, 1 пункты белән каралган хөкем ителмәү һәм җинаять эше факты булмау турында эчке эшләр органыннан белешмә;<br>2) уллыкка бала алырга теләүче гражданинның яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында мәгълүмат;<br>3) пенсия алу турында һәм аның күләме турында мәгълүмат (төп керем чыганагы булып мәҗбүри пенсия иминиятләве яки башка пенсия түлүәүләре торган затлар өчен);<br>4) Россия Федерациясе Гаилә кодексының 127 маддәсе 6 пунктында каралган тәртиптә Россия Федерациясе территориясендә әти-әнисез калган балаларны тәрбиягә гаиләгә алырга теләүче затларны әзерләү курслары үтү турында таныклык күчермәсе.<br>Әлеге документлар опека һәм попечительлек секторы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә, бирелгән мәгълүматның конфиденциальлеген тәэмин итү максатында, гариза бирүчене алдан кисәтеп, башкарыла.<br>Әлеге мәгълүматны биргән вакытта уллыкка алу сере сакланырга тиеш. Аны таратуда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә. | 275 нче номерлы РФ Хөкүмәте карары |
| 2.7. Норматив хокукый актлар белән каралган очракларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган һәм хезмәт күрсәтә торган башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла торган дәүләт хакимияте һәм аның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Тиеш булмаган органга мөрәҗәгать итү | 275 нче номерлы РФ Хөкүмәте карары |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Әгәр гариза бирүче (ләр) түбәндәге категорияләргә караса:<br>1) суд тарафыннан эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы дип танылган затлар;<br>2) ире яки хатыны суд тарафыннан эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы дип танылган булса;<br>3) суд тарафыннан әти-әни хокукыннан мәхрүм ителгән яки әти-әни хокуклары чикләнгән затлар;<br>4) йөкләнгән вазыйфаны тиешенчә башкармаган өчен опекага алучы (попечитель) вазыйфаларыннан читләштерелгән затлар;<br>5) элеккеге уллыкка алучылар, әгәр уллыкка алу суд тарафыннан кире | 275 нче номерлы РФ Хөкүмәте карары |

| | | |
|---|---|---|
| | кагылган булса;<br>6) сәламәтлек буенча уллыкка бала ала алмаучылар. Уллыкка бала алу, аны опекага, попечительлеккә алу, тәрбиягә яки патронат гаиләгә алу мөмкин булмаган авырулар исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә;<br>7) уллыкка алу вакытына балага Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумын тәэмин итүче керемнәре булмаган затлар;<br>8) даими яшәү урыны булмаган затлар;<br>9) хөкем ителгән, шәхеснең җенес кагылгысызлыгына һәм җенес иркенә каршы, шулай ук шәхеснең тормышына һәм сәламәтлегенә каршы, ирегенә каршы, намусына һәм абруена каршы (стационар шартларда психиатрия ярдәме күрсәтүче медицина оешмасына законсыз урнаштырудан тыш), балигъ булмаган затларның гаиләсенә каршы, халык сәламәтлегенә һәм җәмәгать әхлагына, кешелекнең тынычлыгына һәм куркынычсызлыгына каршы җинаять эзәрлекләвенә дучар ителгән (реабилитацияләү нәтиҗәләре буенча җинаять эзәрлекләве туктытылган затлардан тыш) затлар, 10 пунктта күрсәтелгән очраклардан тыш;<br>10) 9 пунктта күрсәтелгән затлардан зур булмаган яки уртача авырлыктагы җинаятьләргә керүче шәхеснең тормышына һәм сәламәтлегенә каршы, ирегенә каршы, намусына һәм абруена каршы (стационар шартларда психиатрия ярдәме күрсәтүче медицина оешмасына законсыз урнаштырудан тыш), балигъ булмаган затларның гаиләсенә каршы, халык сәламәтлегенә һәм җәмәгать әхлагына, кешелекнең тынычлыгына һәм куркынычсызлыгына каршы җинаять эзәрлекләвенә дучар ителгән затлар, әгәр әлеге затлар суд тарафыннан уллыкка алынучы баланың тормышына, сәламәтлегенә, әхлагына куркыныч тудыра дип табылса;<br>11) 9 пунктта күрсәтелгән җинаятьләргә кермәгән авыр һәм аеруча авыр җинаять кылган өчен хөкем ителгән затлар;<br>12) РФ Гаилә кодексының 116 маддәсе 6–10 бүлекләре белән билгеләнгән тәртиптә әзерлек үтмәгән затлар (баланың якын туганнарыннан, шулай ук элегрәк уллыкка алучылар булган затлардан, әгәр уллыкка алу кирек агылмаган булса, йөкләнгән вазыйфалардан читләштерелмәгән очракта элегрәк яки хәзер опекага алучы (попечитель) булып торучы затлардан тыш);<br>13) мондый гаилә рөхсәт ителгән дәүләт законнары нигезендә рәсмиләштерелгән һәм гаилә булып танылган бер җенестәге затлар белән яшәүче затлар, шулай ук әлеге дәүләт гражданнары булып саналучы, гаилә булып рәсмиләштерелмәгән затлар.<br>2. Гариза бирүче тарафыннан алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүгә хокук билгеләнә торган тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүмат бирү;<br>3. Тапшырылган документларның 2.5. пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә. | |
| 2.11. Әлеге түләүне исәпләү турында мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргән вакытта һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алган вакытта чиратта көтүнең максималь вакыты | Көтеп утыруның (хезмәт күрсәтүнең) максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Аерым категория кешеләр өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты | Гариза кергән көнне | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | Гариза бирүчеләрне кабул итү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз, мәгълүмати стендлар белән җиһазланган бинада башкарыла;<br>Инвалидларга хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыкларсыз керү тәэмин ителә (биналарга уңайлы керү–чыгу һәм алар чигендә хәрәкәт итү).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны исәпкә алып, урнаштырыла. | Вазыйфаи регламентлар, вазыйфаи күрсәтмәләр |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Хезмәт күрсәтүнең аңлаешлылыгы күрсәткечләре:<br>- бинаның җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы;<br>- җитәрлек белгечләр булу, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>- мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә башкарма комитетның мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү бердәм порталында хезмәт күрсәтү тәртибе, ысуллары, вакыты турында тулы мәгълүмат булу;<br>- инвалидларга башкалар белән беррәттән дәүләт хезмәте алырга комачаулаучы каршылыкларны бетерү<br>Хезмәт күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре:<br>-гариза бирүчедән документлар кабул итеп алган һәм аңа документлар биргән вакытта чиратлар булмау;<br>- дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозмау;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирмәү;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә игътибарсызлык күрсәтүенә шикаять бирмәү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратып алу биргән очракта һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен алган вакытта муниципаль хезмәт күрсәтә торган вазыйфаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр аралашуы күздә тотыла.<br>Хезмәттәшлек вакыты регламент белән билгеләнә. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Хезмәт күпфункцияле үзәктә күрсәтелми. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Хезмәт электрон формада күрсәтелми | |

## 3. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкару составы, эзлеклелеге һәм вакыты, аларны башкару тәртибенә таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау:

3.1.1. Уллыкка алучылыкка кандидат буларак теркәү буенча нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчеләргә консультация бирү;

2) гаризаны (1 Кушымта), документларны кабул итү (әлеге регламентның 2.5 пунктын кара);

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратып алу формалаштыру һәм юллау;

4) уллыкка алучы буларак кандидат булу һәм исәпкә алу мөмкинлеге турында нәтиҗә әзерләү (3 Кушымта);

5) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

6) нигезләр булган очракта гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат җибәрү;

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема әлеге Административ регламентка 5 Кушымтада бирелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү

Дәүләт хезмәте алу турында консультация алу өчен гариза бирүче шәхсән опека һәм попечительлек секторына мөрәҗәгать итә.

Опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәк булган документлар исемлеге һәм формасы эчтәлеге буенча.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте алу өчен кирәк булган документлар исемлеге һәм формасы эчтәлеге буенча консультацияләр, аңлатмалар.

3.3. Гариза, документлар кабул итү

3.3.1. Гариза бирүче, 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән үзе гариза тапшыра (гариза бирүче белән килешеп).

3.3.2. Кабул итү алып баручы опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүченеж шәхесен һәм яшәү урынын билгели.

Гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ булмаса, яки гариза бирүче тиешле органга мөрәҗәгать итмәсә, гариза һәм документларны кабул итеп алудан баш тартыла.

Гариза бирүченең шәхесе расланса һәм ул тиешле органга мөрәҗәгать итсә, опека һәм попечительлек секторы белгече гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны кабул итеп ала, аннан соң әлеге Регламентның 3.3.3 подпункты белән карарлган процедуралар башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар.

3.3.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүче тапшырган документларда булган мәгълүматны тикшерә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен 2.9 пункты белән каралган нигезләр булган очракта, опека һәм попечительлек белгече баш тарту турында хат әзерли һәм аны имзалаган көннән соң 2 көн эчендә гариза бирүчегә җиткерә. Шул ук вакытта гариза бирүчегә барлык документлар кире кайтарыла һәм карарны шикаять итү тәртибе аңлатыла һәм әлеге Регламентның 3.6. пункты белән каралган процедуралар башкарыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән көннән соң 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм нәтиҗә әзерләү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратып алу әзерләү һәм җибәрү.

3.4.1 Опека һәм попечительлек белгече (гариза бирүче белән килештереп) ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү системасы аркылы әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны җибәрү турында электрон формада соратып алу юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән көннән 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында юлланган соратып алу.

3.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы опека һәм попечительлек секторы органнары соратуы буенча автоматлаштырылган режимда башкарыла:

- соратып алуны эшкәртү һәм соратылган мәгълүматны эзләү;

- ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү аркылы соратып алынган мәгълүматны формалаштыру, соратып алынган мәгълүмат булмаган очракта, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, соратып алынган мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар опека һәм попечительлек органнарына соратып алу кергән вакыттан 5 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: соратып алуга җавап яки әлеге Регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.5. Уллыкка алуга кандидат булу мөмкинлеге турында нәтиҗә әзерләү.

3.5.1. Уллыкка алуга кандидат булу мөмкинлеге турында нәтиҗә әзерләү өчен опека һәм попечительлек секторы белгечләре тарафыннан гариза бирүченең торак-көнкүреш шартлары тикшерелә, аның сәбәпләре, бала тәрбияләүгә сәләте, гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләр ачыклана. Тикшерү нәтиҗәләре буенча гражданинның тормыш шартларын тикшерү акты рәсмиләштерелә, ул тикшерү үткәргән затларның имзалары белән раслана.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар опека секторы белгече тарафыннан соратып алынган мәгълүмат тиешле вәкаләтле органнар тарафыннан расланганнан соң 3 эш көне дәвамында башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: балигъ булмаган баланы уллыкка (кызлыкка) алырга теләк белдергән гражданинның тормыш шартларын тикшерү акты (әлеге Регламентка 2 Кушымта).

3.5.2. Опека һәм попечительлек секторы белгече тапшырылган документлар һәм тикшерү акты нигезендә уллыкка алуга кандидат булу мөмкинлеге турында нәтиҗә яки уллыкка алуга кандидат булу мөмкинлегенә рөхсәт бирүдән баш тарту турында хат әзерли һәм аны опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә раслатуга юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар опека секторы белгече тарафыннан соратып алынган әлеге Регламентның 3.4. пункты белән каралган мәгълүмат тиешле вәкаләтле органнар тарафыннан расланганнан соң 10 эш көне дәвамында башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән уллыкка алучы (лар) булу мөмкинлеге турында нәтиҗә яки 3.6. пункты нигезендә әзерләнгән баш тарту турында хат (әлеге Регламентка 3 кушымта).

3.5.3. Уңай нәтиҗә чыгарган очракта, уллыкка (кызлыкка) бала алырга теләүче затлар гаризасы нигезендә анкеталар (әлеге Регламентка 4 Кушымта) тутырыла, алар махсус журналда теркәлә һәм уллыкка бала алуга кандидатлар тарафыннан шәхсән уллыкка алу Үзәгенә, «Уллыкка алу» республика мәгълүматлар банкына кертё һәм иәпкә алу өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан шәһәре опека һәм попечительлек бүлегенә тапшырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң 3 эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: уллыкка алуга кандидат сыйфатында гариза бирүчене исәпкә кую.

3.6. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат тапшыру.

3.6.1 Опека һәм попечительлек секторы белгече рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты (алга таба – баш атрут турында хат) әзерли.

Әзерләнгән баш тарту турында хат проектын опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар баш тарту өчен нигезләр ачыкланган көннән соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзалауга юлланган баш тарту турында хат проекты.

3.6.2. Опека һәм попечительлек секторы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек секторы белгеченә кайтара.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзаланган баш тарту турында хат.

3.9.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече баш тарту турында хатны аны имзалаган көннән соң 1 эш көне эчендә гариза бирүчегә юллый. Шул ук вакытта гариза бирүчегә карарны шикаять итү тәртибе аңлатыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формасы

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларын үтәүне тикшерүне, карар кабул итүне һәм күпфункцияле үзәкнең (хезмәт күпфункцияле үзәк аркылы күрсәтелсә), опека һәм попечительлек бүлегенең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап бирүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларының хокукый экспертизасын үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау;
- кабул ителгән тәртиптә делопроизводство алып баруны тикшерү;
- кабул ителгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү үткәрү процедураларына контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерү үткәргән вакытта дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык сораулар каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта һәм карар кабул иткән вакытта гамәлләрне башкаруны тикшерүне башкару максатында күпфункцияле үзәк, опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затлар исемлеге күпфункцияле үзәкнең, опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы гариза бирүченең мөрәҗәгатен вакытында карамаган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезләнмәгән рәвештә баш тарткан өчен җавап бирә.

**5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, аларның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү**

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелгән очракта), опека һәм попечительлек секторы хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Арча муниципаль районы башкарма комитетына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итәргә мөкин:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган документлар, мәгълүмат яки гамәл кылу таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү вакыты яки тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылганда, әгәр туктатылу нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта мөрәҗәгать итүчедән беренче тапкыр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документлар тапшырган вакытта булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү.

5.2. Шикаять почта аркылы язма рәвештә кәгазь битендә яки электрон формада җибәрелергә, шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәткән очракта шикаять күпфункцияле үзәк аркылы җибәрелә ала.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең документларны кабул итүдән баш тартуына яки киткән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять биргән очракта яки мондый төзәтүләрне башкаруның кабул ителгән вакыты бозылуга шикаять биргән очракта – аны теркәгән көннән соң 5 эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исемен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки муниципаль хезмәткәрнең исемен;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән риза булмавына дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә тасвирланган вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре теркәлгән булырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документлар исемлеге бирелә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәте күрсәтелүче зат тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый

актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта Башкарма комитет тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта ачыкланган бозуларны кичекмәстән бетерү максатында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле гамәлләр турында әйтелә.

5.9. Әгәр шикаять канәгатьләндерелмәсә, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул итлегән карарга нигезләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында аңлатма бирелә.

5.10. Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

.

Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка алучы булу мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү һәм уллыкка алучылыкка кандидат буларак теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
1 Кушымта

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлек Башкарма комитеты опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә

________________________________ адресы буенча яшәүче

_______________________________________________ннән
(тулысынча фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

Паспорт ______________________________________________
(серия, номер, кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)
_______________________________________________________
_______________________________________________ннән
(тулысынча фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

Паспорт ______________________________________________
(серия, номер, кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)

Телефон: _________________________________

ГАРИЗА

Фамилия, исем, әтисенең исеме (тулысынча), туу датасы, адресы буенча теркәлгән:
Фамилия, исем, әтисенең исеме (тулысынча), туу датасы, адресы буенча теркәлгән:
уллыкка бала алу мөмкинлеге турында нәитҗә бирүегезне һәм кандидатлар сыйфатында исәпкә куюыгызны сорыйбыз.
Ир белән хатын арасында никах рәсмиләштерелгән (дата), чынлып та никах мөнәсәбәтләрендә торабыз (дата).
Безнең белән бергә теркәлгән һәм яши (гариза бирүче белән бергә теркәлгән һәм яшәүче барлык затлар, аларның туганлык дәрәҗәсе, алар арасындагы мөнәсәбәтләр күрсәтелә).
Хатыны (фамилиясе, исем, әтисенең исеме), белеме, эшлим (эш характерын тасвирларга – даими/вакытлыча, хезмәт хакы күләмен күрсәтеп; әгәр гариза бирүче эшләмәсә – сәбәбен күрсәтергә), хөкем ителү/ хөкем ителмәү, пенсия күләме (әгәр булса) турында мәгълүмат күрсәтергә.
Ире (фамилиясе, исем, әтисенең исем), белеме, эшлим (эш характерын тасвирларга – даими/вакытлыча, хезмәт хакы күләмен күрсәтеп; әгәр гариза бирүче эшләмәсә – сәбәбен күрсәтергә), хөкем ителү/ хөкем ителмәү, пенсия күләме (әгәр булса) турында мәгълүмат күрсәтергә.
Матди мөмкинлекләр, торак шартлары, сәламәтлек һәм эш характеры безгә уллыкка бала алырга мөмкинлек бирә.
Яшибез (торак бина тасвирлана, секторлымы юкмы, мәйданын күрсәтеп, торак дәүләт, муниципаль фондныкы яки шәхси милек)
Өстәмә мәгълүмат (бакча, автотранспорт, йорт хайваннары һ.б. булу).
Баланы (балаларны) гаиләгә алу сәбәпләре.
Без гаиләгә алырга теләр идек(баланың яшен, җенесен, сәламәтлеген, тышкы кыяфәтен, милләтен күрсәтергә).
Опека һәм попечительлек органы тарафыннан без РФ законнары нигезендә дөреслеккә туры килмәгән мәгълүмат тапшырган өчен җаваплылык турында кисәтелдек, опека һәм попечительлек секторы тарафыннан безнең шәхси мәгълүматны эшкәртүгә рөхсәт бирәбез.

Дата_________________

______________________
(гариза бирүчеләрнең имзалары)

Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка алучы булу мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү һәм уллыкка алучылыкка кандидат буларак теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
2 Кушымта

Балигъ булмаган гражданинны опекага алучы яки попечитель булырга яки әти-әнисез калган балаларны Россия Федерациясе гаилә законнары белән билгеләнгән башка формаларда гаиләгә тәрбиягә алырга теләүче гражданинның тормыш шартларын тикшерү акты

Тикшерү датасы "__" _________________ 20__ ел.

Тикшерү үткәргән кешенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), вазыйфасы ___________
_______________________________________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме

_____________________________________________________________нең тормыш шартлары тикшерелде;

(булган очракта), туу көне)

Шәхесне раслаучы документ: _______________________________________________________
__________________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________________

(кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)

Тору урыны (теркәү урыны буенча) __________________________________________________________
________________________________________________________________________________________

Яшәү урыны (яшәү урыны буенча)______________________________________________________________

Белеме __________________________________________________________________________

Профессиональ эшчәнлек ____________________________________________________________
________________________________________________________________________________________

(адрес, биләгән вазыйфаны, эш телефонын күрсәтеп, эш урыны)

_______________________________________________________________________________________ яшәүче торак мәйдан

фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта)

_____ кв. м тәшкил итә, __________________________ бүлмәдән тора, һәр бүлмәнең мәйданы: ___ кв.м, ______________ кв. м, ________ кв. м.
___этажда _______ этажлы йортта.

Йорт сыйфаты (кирпеч, панель, агач һ.б.; яхшы хәлдә, тузган, аварияле; бүлмәләр коры, якты, үтә торган, тәрәзәләр саны һ.б.) ________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________________

Йорт һәм торак мәйданының төзекләндерелеше (су үткәргеч, канализация, җылыту, газ, ванна, лифт, телефон һ.б.):
________________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________________

Торак мәйданның санитар-гигиеник торышы (яхшы, канәгатьләнерлек, канәгатьләнерлек түгел)
________________________________________________________________________________________

Торак мәйданда яши (тиешле тәртиптә теркәлгән һәм чынлап яши):

| Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта) | Туу елы | Эш урыны, вазыйфасы яки уку урыны | Туганлык мөнәсәбәтләре | Кайчаннан әлеге торак мәйданда яши |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

Гражданинның гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәт ________________________________________
________________________________________________________________________________________

(гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәт характеры, балалар белән аралашу үзенчәлекләре, балалар
_____________________________________________________________________________

арасындагы үзара мөнәсәбәт һ.б.)

Гражданинның шәхси сыйфатлары (характер үзенчәлекләре, гомуми мәдәният, балалар белән аралашу тәҗрибәсе һ.б.)____________________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________________________

Балигъ булмаган баланы гаиләгә алу өчен гражданинның сәбәпләре ___________________________________
______________________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________________

Тикшерүнең өстәмә мәгълүматы __________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________.

Балигъ булмаган гражданинны опекага алучы яки попечитель булырга яки әти-әнисез калган балаларны Россия Федерациясе гаилә законнары белән билгеләнгән башка формаларда гаиләгә тәрбиягә алырга теләүче гражданинның тормыш шартлары
________________________________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________________

(Канәгатьләнерлек/канәгатьләнерлек түгел конкрет шартларны күрсәтеп)

Тикшерү үткәргән затның имзасы _____________________________________

_________________________________ _______________ _______________________

(опека һәм попечительлек органы җитәкчесе) (имза) (фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

М.П.

Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка алучы булу мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү һәм уллыкка алучылыкка кандидат буларак теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
3 Кушымта

УЛЛЫККА АЛУЧЫ (ЛАР), ТӘРБИЯГӘ АЛУЧЫӘТИ-ӘНИ (ЛӘР)
БУЛУ МӨМКИНЛЕГЕ ТУРЫНДА
НӘТИҖӘ
(тиешлесенең астына сызарга)

**№_______** **«____»____________200___ ел**

Опека органы: ________________________________________________________________________________
Иренең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (тулысынча): ____________________________________________
Туу датасы: ___________________________________________________________________
Иренең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (тулысынча): ___________________________________________
Туу датасы: ___________________________________________________________________
Яшәү (теркәлү) урыны: индекс _______________________________________________
Гаилә характеристикасы _______________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________________
____________________________

Никах составы, дәвамлыгы (беренче никах булмаса, алдагы никахтан балалар барлгын күрсәтергә); балалар белән аралашу тәҗрибәсе; гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләр; якын туганнары булуы һәм аларның уллыкка (кызлыкка) бала алуга мөнәсәбәте; уллыкка алучылыкка кандидатларның характер үзенчәлекләре; баланы ире яки хатыны үзе генә уллыкка (кызлыкка) алса, ире яки хатынының уллыкка (кызлыкка) алуга ризалыгы булу)

Белеме һәм профессиональ эшчәнлек ____________________________________________________________
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________

Сәламәтлек характеристикасы
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________

Сәламәтлек торышы, уллыкка (кызлыкка) бала алырга комачаулаучы авырулар булмавы

Матди хәл ____________________________________________________
__________________________________________________________________________

Милек, хезмәт хакы күләме, башка төр керемнәр

Уллыкка (кызлыкка) алу сәбәпләре___________________________________________________
_____________________________________________________________________________________________
___________________________________________________________

Уллыкка алучыларның бала кандидатурасына теләкләре
_____________________________________________________________________________________________
___________________________________________________________
__________________________________________________________________________

Җенесе, яше, характер үзенчәлекләре, уллыкка (кызлыкка) бала алуга кандидатларның үсештә тоткарлыклары булган бала алуга ризалыгы

Уллыкка алырга кандидат (лар) булу мөмкинлеге/мөмкин булмавы турында нәтиҗә
___________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________

Гариза бирүченең тулы фамилиясе, исеме, әтисенең исеме

__________________________________________________________________________

(Анкета тутыруга җаваплы затның вазыйфасы) (фамилия, исем, әтисенең исеме, имза, мөһер)

*Искәрмә*. Нәтиҗәнең төп нөсхәсе уллыкка алучылыкка кандидатларга бирелә, күчермәсе уллыкка алуга кандидатларның делосында кала. Нәтиҗә җирле үзидарә органы бланкында әзерләнә, аның җитәкчесе тарафыннан имзалана һәм мөһер сугыла. Нәтиҗә 2000 елның 29 мартындагы 275 нче номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Россия Федерациясе территориясендә балаларны уллыкка (кызлыкка) бирү һәм уллыкка алган гаиләләрдә аларның тормыш шартларын контрольдә тоту кагыйдәләренең (РФ законнар җыентыгы, 2000, №15, 1590 маддә) 6 пункты белән каралган документлар нигезендә әзерләнә һәм уллыкка алучылыкка кандидат сыйфатында исәпкә кую һәм бала сайлау өчен нигез булып тора. Исәпкә кую датасы уллыкка бала алучылыкка кандидатлар журналында күрсәтелә.

Россия Федерациясе территориясендә даими
рәвештә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына
уллыкка алучы булу мөмкинлеге турында нәтиҗә
бирү һәм уллыкка алучылыкка кандидат буларак
теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
4 Кушымта

**ГАИЛӘГӘ БАЛА АЛЫРГА ТЕЛӘҮЧЕ ГРАЖДАНИН АНКЕТАСЫ**

**1 бүлек (гражданин тарафыннан тутырыла)**

**ГРАЖДАНИН ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ (тутыру датасына)**

Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме.: ______________________________

Җенесе: ______________ Туу датасы:______________________________

Көне, ае, елы

Туу урыны: ______________________________

республика, өлкә, торак пункт паспорт буенча

Гражданлык: ______________________.

Гаилә хәле: ______________________

Яшәү урыны һәм/яки тору урыны (почта индексын күрсәтеп):

______________________________

______________________________

Телефон номеры/факс: ______________________________

шәһәрара кодны күрсәтеп

Шәхесне раслаучы документ: ______________________________

Документ төре, мәсәлән, паспорт

Серия: ______________ №______________________ Бирү датасы: ______________________

Кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән: ______________________________

Уллыкка алучы/опекага алучы (попечитель)/тәрбиягә алучы (тормыш шартлары һәм уллыкка алу мөмкинлеге турында нәтиҗә – чит ил гражданнары өчен) әзерләнде

______________________________

Орган исеме

Дата: ______________________. Номер: ______________________

Гражданин уллыкка алырга/опекага (попечительлеккә) алырга/ тәрбиягә алырга теләгән
бала (балалар) турында мәгълүмат
(кирәклесенең астына сызарга)

Җенесе: ________________, яше ________яшьтән __________ яшькә кадәр.

Сәламәтлеге: ______________________________

Тышкы кыяфәте: күзләр төсе: *зәңгәр* чәчәләр төсе: *коңгырт*

*яшел* *җирән*

*коңгырт-кара* *ачык коңгырт*

*соры* *ачык*

*кара* *караңгы коңгырт*

*караңгы*

*кара*

Башка теләкләр: ______________________________.

Граажданин бала алырга теләгән төбәкләр:

______________________________

______________________________

Анкета тутыру датасы
Гражданин имзасы

**2 Бүлек (әти-әнисез калган балалар турында Дәүләт банкы операторы тарафыннан тутырыла)**

Республика уллыкка алу, опека һәм попечительлек үзәге ______________________.

Балалар турында мәгълүматлар Дәүләт банкы операторы функцияләрен башкаручы орган исеме
Дәүләт банкында анкета номеры:
___________________________________________________________________________
Төбәк исәбенә кую датасы:
___________________________________________________________________________
Анкетаны теркәгән хезмәткәр фамилиясе:
___________________________________________________________________________

Гражданинга ул сайлаган баланы барып кару өчен бирелгән учреждениеләр турында һәм аның кабул иткән карары турында мәгълүмат

Баланың фамилиясе, исеме, әтисенең исеме:
___________________________________________________________________________
Учреждение исеме: ___________________________________________________________
Юллама бирү датасы:
___________________________________________________________________________
Баланы гаиләгә алу яки алмау турында карар, гаиләгә алмауның сәбәбен күрсәтеп:_____________________________________________________________


Тикшерде ______________________

Анкетаны алу датасы__________

Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә

яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка
алучы булу мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү һәм
уллыкка алучылыкка кандидат буларак теркәү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
5 Кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы**



Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә
яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка
алучы булу мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү һәм уллыкка
алучылыкка кандидат буларак теркәү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
Кушымта (мәгълүмати)

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне агымдагы контрольдә тотучы җаваплы вазыйфаи затларның РЕКВИЗИТЛАРЫ**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**

| **Вазыйфа** | **Телефон** | **Электрон адрес** |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |
| Сектор белгече | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты**

| **Вазыйфа** | **Телефон** | **Электрон адрес** |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-84366) 3-00-44 | Ispolkom.Arsk@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының
«__»_________, 2019 ел, №_____
Карарына
12 Кушымта

**Балигъ булмаганнарның күчемле милкен алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү**
**Административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге регламент балигъ булмаганнарның күчемле милкен алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандарты һәм тәртипләрен билгели.

1.2. Хезмәтне алучылар: законлы вәкилләре ризалыгы белән эш итүче ундүрт яше тулган балигъ булмаган Россия Федерациясе гражданнары яки балигъ булмаганнарның кучемле милкен алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт алырга теләүче ундүрт яше тулмаган балигъ булмаган гражданнарның законлы вәкилләре (алга таба – гариза бирүчеләр).

1.3. Дәүләт хезмәте ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен башкаручы – опекага алынган затның яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (алга таба – опека һәм попечительлек органы).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

1.3.2. Опека һәм попечительлек органы урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

Эш режимы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш.

Төшке аш вакыты – 12.00 – 13.00.

Эчкә үтү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне аныклаучы документ буенча.

1.3.3. Опека һәм попечительлек органы телефоны: (84366)3–13–81.

1.3.4. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайты (алга таба – «Интернет» челтәре): http://www.arsk.tatarstan.ru.

1.3.5. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы бинасында урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аркылы;

2) «Интернет» челтәре аша:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында http://www.arsk.tatarstan.ru;

3) опека һәм попечительлек секторына шәхси мөрәҗәгать итеп;

4) күпфункцияле үзәктә (хезмәт күрсәтүне күпфункцияле үзәк аркылы алып булган очракта).

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә башкарыла:

- Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы (1 бүлек) 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гражданлык кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 05.12.1994, №32, 3301 маддә);

- Россия Федерациясе Гаилә кодексы 1995 елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гаилә кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 01.01.1996, №1 16 маддә;

- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 01 гыйнварындагы 48-ФЗ номерлы Федераль законы (алга таба – 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 28.04.2008, №17, 1755 маддә);

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 маддә);

- Татарстан Республикасы Гаилә кодексы 2009 елның 13 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы (алга таба – ТР Гаилә кодексы) (Республика Татарстан, 16.01.2009, №8);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары җыелмасы, №21, 26.05.2004);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №60-61, 25.03.2008);

- «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары (алга таба – 880 нче номерлы ТР Министрлар кабинеты карары) (Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карарлары һәм республика башкарма комитет органнары норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, 2144 маддә; 20.12.2011, №48, 2612 маддә; 25.05.2012, №40, 1252 маддә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 15 августындагы боерыгы белән расланган Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында Нигезләмәсе (алга таба – опека секторы турнда Нигезләмә).

1.5.Әлеге Регламентта түбәндәге термин һәм билгеләмәләр кулланыла:

- административ регламент –Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралар һәм административ эшчәнлек вакытын һәм эзлеклелеген, структур бүлекчәләр һәм вазыйфаи затлар арасындагы хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хакимияте башкарма органнарының физик яки юридик затлар (алга таба – дәүләт хезмәте алучылар), башка дәүләт хезмәте һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгеләүче норматив хокукый документ;

- дәүләт хезмәте – дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән чикләрдә мөрәҗәгать итүче соравы буенча башкарыла торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарган вакытта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек;

- дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе 1[1] бүлегендә каралган оешмалар яки аларның эшчеләре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта бозылган хокукларны яки законлы мәнфәгатьләрне кире кайтару яки саклау турында таләбе.

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яки муниципаль учреждениенең оештыру-хокукый формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирүче һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча, вәкаләтле оешма;

- «бер тәрәзә» принцибы – мөрәҗәгать итүче 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15[1] маддәсендә күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү, ә дәүләт хезмәт күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар белән күпфункцияле үзәк тарафыннан мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актлар һәм хезмәттәшлек итү турында килешү нигезендә хезмәттәшлек алып бару принцибы.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбе исеме | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте исеме | Балигъ булмаганнарның күчемле милкен алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү | РФ Гражданлык кодексының 28 маддәсе;<br>РФ Гражданлык кодексының 37 маддәсе<br>РФ Гаилә кодексының 60 маддәсе;<br>122-ФЗ номерлы Федераль закон<br>8-ТРЗ номерлы ТР Законы |
| 2.2. Хезмәт күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (гариза бирүченең яшәү урыны буенча) | 8-ТРЗ номерлы ТР Законы;<br>7-ТРЗ номерлы ТР Законы<br>Устав, ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә 2014 елның 15 августындагы |
| 2.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Балигъ булмаганнарның күчемле милкен алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү, рөхсәт бирү документы формасында<br>Хат формасында дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту | РФ Гражданлык кодексының 37 маддәсе;<br>РФ Гаилә кодексының 60 маддәсе;<br>48-ФЗ номерлы Федераль законның 21 маддәсе;<br>8-ТРЗ номерлы ТР Законы |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты | Гражданнарның дәүләт хезмәте күрсәтүгә кагылышлы язма мөрәҗәгатьләрен карау аларны теркәгәннән соң 15 көн эчендә башкарыла | |
| 2.5. Закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәте өчен кирәк һәм мәҗбүри булган документларның тулы исемлеге | 1. Әти-әнисенең берсенең (яки аларны алыштыручыларның) һәм 14 яше тулган балигъ булмаган баланың гаризасы (1 Кушымта).<br>2. Әти-әнисенең (аны алыштыручы затның) паспорт күчермәсе.<br>3. Баланың (балаларның) туу турында таныклыгы.<br>4. 14 яше тулган балигъ булмаган баланың паспорт күчермәсе.<br>5. Алына торган күчемле милеккә хокук билгеләүче документлар күчермәсе.<br>6. Хокукларны дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе;<br>7. Күчемле милеккә техник паспорт күчермәсе.<br>8. Агымдагы елга мөрәҗәгать итү вакытына күчемле милекне бәяләү бәясе.<br>9. Югалта торган милек урынына алына торган милеккә документлар (хокук билгеләүчедокументлар, хокукларны дәүләт теркәве турында таныклык (булган очракта), техник паспорт, милекнең бәяләү бәясен раслаучы документ) яки баланың алына торган күчемле милке бәясенә тигез булган суммага балигъ булмаган бала исеменә ачылган исәп-хисап счетыннан өземтә.<br>10. Балигъ булмаган бала исеменә банкта счет.<br>Документлар күчермәсе төп нөсхә булган очракта 1 нөсхәдә тапшырыла, | |

| | | |
|---|---|---|
| | нотариаль расланган документлар күчермәләре кабул ителергә мөмкин. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм алар бирергә хокуклы булган документларның тулы исемлеге | Балигъ булмаган баланың теркәлү урыныннан йорт кенәгәсеннән өземтә; | |
| 2.7. Норматив хокукый актлар белән каралган очракларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган һәм хезмәт күрсәтә торган башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла торган дәүләт хакимияте һәм аның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Гражданинның яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итмәве | |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>- тапшырылган документларның әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>- балигъ булмаган затның хокукларын кысу. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Түләүсез нигездә | |
| 2.11. Әлеге түләүне исәпләү турында мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргән вакытта һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алган вакытта чиратта көтүнең максималь вакыты | Көтеп утыруның (хезмәт күрсәтүнең) максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Аерым категория кешеләр өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты | Гариза кергән көнне | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | 1. Гариза түбәндәге адрес буенча тапшырыла:<br>Арча шәһәре, Советлар мәйданы урамы, 12 йорт, опека һәм попечительлек секторы.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазланган бинада башкарыла;<br>3. Бинада гаризалар кабул итү өчен сектор белгеченең эш урыны хезмәтне тулысынча күрсәтергә мөмкинлек бирүче электрон белешмә-хокукый системалар, оргтехника белән тәэмин ителгән шәхси компьютер белән | |

| | | |
|---|---|---|
| | җиһазландырыла.<br>4. Документлар тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазлана һәм документлар тутыру үрнәкләре белән тәэмин ителә.<br>5. Инвалидларга хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыкларсыз керү тәэмин ителә, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм чыгу юлларына, дәүләт хезмәте күрсәтү урынына барып җитү максатында объект буйлап мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итү тәэмин ителә.<br>6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны исәпкә алып, урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Хезмәт күрсәтүнең аңлаешлылыгы күрсәткечләре:<br>бинаның җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы;<br>җитәрлек белгечләр булу, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә башкарма комитетның мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү бердәм порталында хезмәт күрсәтү тәртибе, ысуллары, вакыты турында тулы мәгълүмат булу;<br>инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт алырга комачаулаучы каршылыкларны узарга ярдәм итү.<br><br>Хезмәт күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре:<br>гариза бирүче документлар тапшырганда һәм алганда чиратлар булмау;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын саклау;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирмәү;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә игътибарсызлык күрсәтүенә шикаять бирмәү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратып алу биргән очракта һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен алган вакытта муниципаль хезмәт күрсәтә торган вазыйфаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр аралашуы күздә тотыла.<br>Хезмәттәшлек вакыты регламент белән билгеләнә. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Хезмәт электрон формада күрсәтелми | |

## 3. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкару составы, эзлеклелеге һәм вакыты, аларны башкару тәртибенә таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау:

3.1.1. Балигъ булмаганнарның күчемле милкен алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчеләргә консультация бирү;

2) гаризаны һәм документларны кабул итү (әлеге регламентның 2.5 пунктын кара);

3) тапшырылган документларны карау;

4) балигъ булмаганнарның күчемле милкен алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү яки баш тарту турында хат әзерләү;

5) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

6) нигезләр булган очракта гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема әлеге Административ регламентка 3 кушымтада бирелә.

3.2. Консультация күрсәтү

Мәгълүмат һәм консультация бирү буенча процедуралар кысаларында гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибен җайлаучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;

- гариза бирүчеләрне балигъ булмаганнарның күчемле милкен алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән таныштыра;

- балигъ булмаганнарның күчемле милкен алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеген бирә.

Консультация гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне күрсәтелә.

Процедура нәтиҗәсе: документлар составы һәм хезмәт күрсәтү буенча башка сораулар буенча консультация.

Консультация һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедуралар башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

3.3. Гариза, документлар кабул итү.

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән үзе гариза һәм 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыра.

Гариза һәм документларны кабул итү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- гариза бирүченең шәхесен, балигъ булмаган затның яшәү урынын билгели;

- документларның барлыгын тикшерә. Кирәкле документлар булмаган очракта җитмәгән документларны тапшырырга тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларны кабул итүне таләп итсә, документлар кабул ителә.

- документлар пакеты формалаштыра.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар.

Гамәлләрне башкаруның максималь вакыты – 15 минут.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта опека һәм попечительлек, күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелсә) белгече гариза бирүчегә гариза һәм документлар алу, теркәлү номеры турында хәбәр итә, аннан соң әлеге Регламентның 3.4. подпунктында күрсәтелгән процедуралар башкарыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән вакыттан соң 1 көн эчендә 15 минут вакыт аралыгында башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язмасы.

Гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирүче белгеч, шәхси мәгълүматларны исәпкә алып, консультациянең грамоталыгы, тулылыгы һәм ачыклыгы өчен шәхси җавап бирә.

3.4. Опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүче тапшырган документлардагы мәгълүматны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергәннән соң 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәт бирү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.5.1. Тапшырылган документлар нигезендә опека һәм попечительлек секторы балигъ булмаганнарның күчемле милкен алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү буенча боерык проекты әзерли һәм аны килештерү һәм раслату өчен опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә җибәрә яки тиешле аныклау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: балигъ булмаганнарның күчемле милкен алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү турында боерык яки 3.7 пункты нигезендә әзерләнгән хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.6. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен тапшыру.

3.6.1. Опека һәм попечительлек секторы белгече, имзаланган боерыкны алгач, аны терки һәм гариза бирүчегә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.4 подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.7. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат тапшыру.

3.7.1 Опека һәм попечительлек секторы белгече боерык бирүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты әзерли.

Әзерләнгән баш тарту турында хат проектын опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар баш тарту өчен нигезләр ачыкланган көннән соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзалауга юлланган баш тарту турында хат проекты.

3.7.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек секторы белгеченә кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзаланган баш тарту турында хат.

3.7.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече баш тарту турында хатны аны имзалаган көннән соң 1 эш көне эчендә гариза бирүчегә юллый. Шул ук вакытта гариза бирүчегә карарны шикаять итү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.7.2. подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формасы

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларын үтәүне тикшерүне, карар кабул итүне һәм күпфункцияле үзәкнең (хезмәт күпфункцияле үзәк аркылы күрсәтелсә), опека һәм попечительлек бүлегенең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап бирүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларының хокукый экспертизасын үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау;

- кабул итлегән тәртиптә делопроизводство алып баруны тикшерү;

- кабул ителгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү үткәрү процедураларына контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерү үткәргән вакытта дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык сораулар каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта һәм карар кабул иткән вакытта гамәлләрне башкаруны тикшерүне башкару максатында күпфункцияле үзәк, опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затлар исемлеге күпфункцияле үзәкнең, опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы гариза бирүченең мөрәҗәгатен вакытында карамаган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезләнмәгән рәвештә баш тарткан өчен җавап бирә.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, аларның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелгән очракта), опека һәм попечительлек секторы хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Арча муниципаль районы башкарма комитетына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итәргә мөкин:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган документлар, мәгълүмат яки гамәл кылу таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү вакыты яки тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылганда, әгәр туктатылу нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта мөрәҗәгать итүчедән беренче тапкыр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документлар тапшырган вакытта булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү.

5.2. Шикаять почта аркылы язма рәвештә кәгазь битендә яки электрон формада җибәрелергә, шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәткән очракта шикаять күпфункцияле үзәк аркылы җибәрелә ала.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең документларны кабул итүдән баш тартуына яки киткән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять биргән очракта яки мондый төзәтүләрне башкаруның кабул ителгән вакыты бозылуга шикаять биргән очракта – аны теркәгән көннән соң 5 эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исемен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки муниципаль хезмәткәрнең исемен;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, этисенең исеме (булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән риза булмавына дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә тасвирланган вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре теркәлгән булырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документлар исемлеге бирелә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәте күрсәтелүче зат тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта Башкарма комитет тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта ачыкланган бозуларны кичекмәстән бетерү максатында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле гамәлләр турында әйтелә.

5.9. Әгәр шикаять канәгатьләндерелмәсә, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул итлегән карарга нигезләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында аңлатма бирелә.

5.10. Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Балигъ булмаганнарның күчемле милкен алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
1 Кушымта

________________________________________________
______________________________адресы буенча яшәүче

_____________________________________________ннән
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
______________________________
Паспорт:_______________________________________

Телефон:_______________________________________

ГАРИЗА

_____________________________________________________________________________
торган күчемле милекне сатуга (алыштыруга) рөхсәт бирүегезне сорыйм.

Милекнең техник характеристикасы:
_______________________________________________________________________________
_____________________________________, милекне бәяләү бәясе:
_________________________________________________________,
милекче булып балигъ булмаган балалар тора:
_________________________________________________ (фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
_________________________________________________________
________________________________________________ нигезендә
(закон буенча мираска хокук турында таныклык һ.б.)
Югалта торган милек урынына баланың (балаларның) счетына
___________________________________________________сум акча күчерелә яки
_____________________________________________
_________________________________________________________ сатып алына.
Балигъ булмаган баланың (балаларның) хокуклары кысылмый.
Балигъ булмаган баланың шәхси мәгълүматлары белән эшләүгә рөхсәт бирәм.

Өстәмә мәгълүмат: _____________________________________________.

________________ ________________
(дата) (имза)

Балигъ булмаганнарның күчемле милкен алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
Кушымта (мәгълүмати)

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне агымдагы контрольдә тотучы җаваплы вазыйфаи затларның**
**РЕКВИЗИТЛАРЫ**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**


| **Вазыйфа** | **Телефон** | **Электрон адрес** |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |
| Сектор белгече | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты**

| **Вазыйфа** | **Телефон** | **Электрон адрес** |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-84366) 3-00-44 | Ispolkom.Arsk@tatar.ru |

Балигъ булмаганнарның күчемле милкен алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
3 Кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы**



Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының
«__»_________, 2019 ел, №_____
Карарына
1 Кушымта

**Ундүрт яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү**
**Административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге регламент ундүрт яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандарты һәм тәртипләрен билгели.

1.2. Хезмәтне алучылар: ундүрт яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт алырга теләүче Россия Федерациясе гражданнары (алга таба – гариза бирүчеләр).

1.3. Дәүләт хезмәте ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен башкаручы – балигъ булмаган затның яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (алга таба – опека һәм попечительлек органы).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

1.3.2. Опека һәм попечительлек органы урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

Эш режимы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш.

Төшке аш вакыты – 12.00 – 13.00.

Эчкә үтү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне аныклаучы документ буенча.

1.3.3. Опека һәм попечительлек органы телефоны: (84366)3–13–81.

1.3.4. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайты (алга таба – «Интернет» челтәре): http://www.arsk.tatarstan.ru.

1.3.5. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы бинасында урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аркылы;

2) «Интернет» челтәре аша:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында http://www.arsk.tatarstan.ru;

3) опека һәм попечительлек секторына шәхси мөрәҗәгать итеп;

4) күпфункцияле үзәктә (хезмәт күрсәтүне күпфункцияле үзәк аркылы алып булган очракта).

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә башкарыла:

- Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гражданлык кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 05.12.1994, №32, 3301 маддә, Российская газета, 238-239, 08.12.1994);

- Россия Федерациясе Гаилә кодексы 1995 елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гаилә кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 01.01.1996, №17 (27.01.1996);

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (Российская газета, №169, 30.07.2010, РФ Законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 маддә);

- Татарстан Республикасы Гаилә кодексы 2009 елның 13 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы (алга таба – ТР Гаилә кодексы) (Республика Татарстан, 16.01.2009, №8);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №43-44, 02.03.2004, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары җыелмасы, №21, 26.05.2004);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Ватаным Татарстан, 22.03.2008, №54, Республика Татарстан, №60-61, 25.03.2008, Татарстан Дәүләт Советы ведомосте, №3, 2008 елның марты);

- «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары;

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 15 августындагы боерыгы белән расланган Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында Нигезләмәсе (алга таба – опека секторы турнда Нигезләмә).

1.5.Әлеге Регламентта түбәндәге термин һәм билгеләмәләр кулланыла:

- административ регламент –Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралар һәм административ эшчәнлек вакытын һәм эзлеклелеген, структур бүлекчәләр һәм вазыйфаи затлар арасындагы хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хакимияте башкарма органнарының физик яки юридик затлар (алга таба – дәүләт хезмәте алучылар), башка дәүләт хезмәте һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгеләүче норматив хокукый документ;

- дәүләт хезмәте – дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән чикләрдә мөрәҗәгать итүче соравы буенча башкарыла торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарган вакытта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек;

- дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе 1[1] бүлегендә каралган оешмалар яки аларның эшчеләре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта бозылган хокукларны яки законлы мәнфәгатьләрне кире кайтару яки саклау турында таләбе.

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яки муниципаль учреждениенең оештыру-хокукый формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирүче һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча, вәкаләтле оешма;

- «бер тәрәзә» принцибы – мөрәҗәгать итүче 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15[1] маддәсендә күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү, ә дәүләт хезмәт күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар белән күпфункцияле үзәк тарафыннан мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актлар һәм хезмәттәшлек итү турында килешү нигезендә хезмәттәшлек алып бару принцибы.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбе исеме | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте исеме | Ундүрт яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү | РФ Гаилә кодексының 59 маддәсе;<br>ТР Гаилә кодексының 50 маддәсе;<br>8-ТРЗ номерлы ТР Законы |
| 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (гариза бирүченең яшәү урыны буенча) | РФ Гаилә кодексының 59 маддәсе;<br>ТР Гаилә кодексының 50 маддәсе;<br>8-ТРЗ номерлы ТР Законы |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе | Боерык формасында баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт яки хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат | РФ Гаилә кодексының 59 маддәсе;<br>ТР Гаилә кодексының 50 маддәсе;<br>8-ТРЗ номерлы ТР Законы |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты | Гражданнарның дәүләт хезмәте күрсәтүгә кагылышлы язма мөрәҗәгатьләрен карау аларны теркәгәннән соң 18 көн эчендә башкарыла | |
| 2.5. Закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәте өчен кирәк һәм мәҗбүри булган документларның тулы исемлеге | 1. эти-әнисенең берсенең балигъ булмаган баланың фамилиясен (исемен) үзгәртү турында гаризасы (1 Кушымта);<br>2. эти-әнисенең икенчесенең балигъ булмаган баланың фамилиясен (исемен) алыштыруга гаризасы (ризалыгы) (2 Кушымта);<br>3. баланың туу турында таныклыгы күчермәсе;<br>4. эти-әнисенең паспортлары күчермәсе;<br>5. баланың эти-әнисенең баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүне сорауның сәбәпләрен раслаучы документлар күчермәләре (гаилә кору яки аерылышу турында таныклык, эти-әнисенең берсене фамилиясен алыштыру турында таныклык һ.б.) (булган очракта);<br>6. 10 яше тулган балигъ булмаган баланых гариза-ризалыгы.<br>Әти-әнисенең берсенең гаризасы нигезендә генә рөхсәт алу өчен:<br>- эти-әнинең икенчесе булмауны раслаучы яки аның талдан уйлап эти-әни вазыйфаларын башкармавын раслаучы документ (25 нче форма буенча туу турында белешмә, эти-әнинең икенчесенең үлү турында таныклыгы, 6 айдан артык алиментлар түләүдән качып йөрүен раслаучы суд приставы белешмәсе, эти-әнисенең икенчесен эти-әни вазыйфаларыннан мәхрүм итү турында яки аны эшкә яраксыз дип тану турында суд карары, эти-әнисенең икенчесенең игътибарга алырлык сәбәпләрдән башка баланы тәрбияләүдән качып йөрүен раслаучы документлар) күчермәсе.<br><br>Документлар күчермәсе төп нөсхә булган очракта 1 нөсхәдә тапшырыла; нотариаль расланган документлар кабул итү мөмкин. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм алар бирергә хокуклы булган документларның тулы исемлеге | - балигъ булмаган баланың теркәлү урыныннан йорт (фатир) кенәгәсеннән өземтә;<br>- әти-әнинең икенчесен эзләү эше ачу турында эчке эшләр бүлегеннән белешмә | |
| 2.7. Норматив хокукый актлар белән каралган очракларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган һәм хезмәт күрсәтә торган башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла торган дәүләт хакимияте һәм аның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Гражданинның яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итмәве | |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>- тапшырылган документларның әлеге Административ регламентның 2.5 пукнтында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве; | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә. | |
| 2.11. Әлеге түләүне исәпләү турында мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргән вакытта һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алган вакытта чиратта көтүнең максималь вакыты | Көтеп утыруның (хезмәт күрсәтүнең) максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Аерым категория кешеләр өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты | Гариза кергән көнне | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | 1. Гариза түбәндәге адрес буенча тапшырыла:<br>Арча шәһәре, Советлар мәйданы урамы, 12 йорт, опека һәм попечительлек секторы.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазланган бинада башкарыла;<br>3. Бинада гаризалар кабул итү өчен сектор белгеченең эш урыны хезмәтне тулысынча күрсәтергә мөмкинлек бирүче электрон белешмә-хокукый системалар, оргтехника белән тәэмин ителгән шәхси компьютер белән җиһазландырыла.<br>4. Документлар тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазлана һәм документлар тутыру үрнәкләре белән тәэмин ителә. | |

| | | |
|---|---|---|
| | 5. Инвалидларга хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыкларсыз керү тәэмин ителә, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм чыгу юлларына, дәүләт хезмәте күрсәтү урынына барып җитү максатында объект буйлап мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итү тәэмин ителә.<br>6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны исәпкә алып, урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Хезмәт күрсәтүнең аңлаешлылыгы күрсәткечләре:<br>- бинаның җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы;<br>- җитәрлек белгечләр булу, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>- мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә башкарма комитетның мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү бердәм порталында хезмәт күрсәтү тәртибе, ысуллары, вакыты турында тулы мәгълүмат булу;<br>- инвалидларга башкалар белән беррәттән дәүләт хезмәте алырга комачаулаучы каршылыкларны бетерү<br>Хезмәт күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре:<br>- гариза бирүчедән документлар кабул итеп алган һәм аңа документлар биргән вакытта чиратлар булмау;<br>- дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозмау;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирмәү;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә игътибарсызлык күрсәтүенә шикаять бирмәү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратып алу биргән очракта һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен алган вакытта муниципаль хезмәт күрсәтә торган вазыйфаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр аралашуы күздә тотыла.<br>Хезмәттәшлек вакыты регламент белән билгеләнә. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Хезмәт электрон формада күрсәтелми | |

## 3. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкару составы, эзлеклелеге һәм вакыты, аларны башкару тәртибенә таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау:

3.1.1. Үндүрт яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчеләргә консультация бирү;

2) гаризаны һәм документларны кабул итү (әлеге регламентның 2.5 пунктын кара);

3) үндүрт яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт әзерләү;

4) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

5) нигезләр булган очракта гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема әлеге Административ регламентка 4 кушымтада бирелә.

3.2. Консультация күрсәтү

Мәгълүмат һәм консультация бирү буенча процедуралар кысаларында гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибен җайлаучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;

- гариза бирүчеләрне, шулай ук аларның законлы вәкилләрен үндүрт яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән таныштыра;

- үндүрт яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеген бирә.

Консультация гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Процедура нәтиҗәсе: документлар составы һәм хезмәт күрсәтү буенча башка сораулар буенча консультация.

Консультация һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедуралар башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

3.3. Гариза бирүче, 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән үзе гариза тапшыра.

Гаризалар һәм документлар кабул итү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- гражданинның шәхесен, балигъ булмаган затның яшәү урынын билгели;

- гариза бирүче тапшырган кирәкле документларның барлыгын тикшерә. Кирәкле документлар булмаган очракта җитмәгән документларны тапшырырга тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларны кабул итүне таләп итсә, документлар кабул ителә.

- документлар пакеты формалаштыра.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән документлар.

Гамәлләрне башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта опека һәм попечительлек, күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелсә) белгече гариза бирүчегә гариза һәм документлар алу, теркәлү номеры турында хәбәр итә, аннан соң әлеге Регламентның 3.4 подпунктында күрсәтелгән процедуралар башкарыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән вакыттан соң 1 көн эчендә 15 минут вакыт аралыгында башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язмасы.

3.4 Опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүче тапшырган документлардагы мәгълүматны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергәннән соң 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәт бирү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратып алу әзерләү һәм җибәрү.

3.5.1 Опека һәм попечительлек белгече (гариза бирүче белән килештереп) ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү системасы аркылы әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны җибәрү турында электрон формада соратып алу юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән көннән 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында юлланган соратып алу.

3.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы опека һәм попечительлек секторы органнары соратуы буенча автоматлаштырылган режимда башкарыла:

- соратып алуны эшкәртү һәм соратылган мәгълүматны эзләү;

- ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү аркылы соратып алынган мәгълүматны формалаштыру, соратып алынган мәгълүмат булмаган очракта, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, соратып алынган мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар опека һәм попечительлек органнарына соратып алу кергән вакыттан 5 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: соратып алуга җавап яки әлеге Регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.6.1. Тапшырылган документлар нигезендә опека һәм попечительлек секторы белгече унդүрт яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү турында боерык проекты әзерли һәм аны килештерү һәм раслату өчен опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә җибәрә яки тиешле аныклау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: унդүрт яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү турында боерык яки 3.8 пункты нигезендә әзерләнгән хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.7. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен тапшыру.

3.7.1. Опека һәм попечительлек секторы белгече, имзаланган боерыкны алгач, аны терки һәм гариза бирүчегә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.5.1 подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.8. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат тапшыру.

3.8.1 Опека һәм попечительлек секторы белгече боерык бирүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты әзерли.

Әзерләнгән баш тарту турында хат проектын Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар баш тарту өчен нигезләр ачыкланган көннән соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзалауга юлланган баш тарту турында хат проекты.

3.8.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек секторы белгеченә кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзаланган баш тарту турында хат.

3.8.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече баш тарту турында хатны аны имзалаган көннән соң 1 эш көне эчендә гариза бирүчегә юллый. Шул ук вакытта гариза бирүчегә карарны шикаять итү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.7.2. подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формасы

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларын үтәүне тикшерүне, карар кабул итүне һәм күпфункцияле үзәкнең (хезмәт күпфункцияле үзәк аркылы күрсәтелсә), опека һәм попечительлек бүлегенең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап бирүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларының хокукый экспертизасын үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау;

- кабул итлегән тәртиптә делопроизводство алып баруны тикшерү;

- кабул ителгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү үткәрү процедураларына контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерү үткәргән вакытта дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык сораулар каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта һәм карар кабул иткән вакытта гамәлләрне башкаруны тикшерүне башкару максатында күпфункцияле үзәк, опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затлар исемлеге күпфункцияле үзәкнең, опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы гариза бирүченең мөрәҗәгатен вакытында карамаган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезләнмәгән рәвештә баш тарткан өчен җавап бирә.

**5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, аларның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү**

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелгән очракта), опека һәм попечительлек секторы хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Арча муниципаль районы башкарма комитетына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итәргә мөкин:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган документлар, мәгълүмат яки гамәл кылу таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү вакыты яки тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылганда, әгәр туктатылу нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта мөрәҗәгать итүчедән беренче тапкыр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документлар тапшырган вакытта булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү.

5.2. Шикаять почта аркылы язма рәвештә кәгазь битендә яки электрон формада җибәрелергә, шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәткән очракта шикаять күпфункцияле үзәк аркылы җибәрелә ала.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең документларны кабул итүдән баш тартуына яки киткән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять биргән очракта яки мондый төзәтүләрне башкаруның кабул ителгән вакыты бозылуга шикаять биргән очракта – аны теркәгән көннән соң 5 эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исемен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки муниципаль хезмәткәрнең исемен;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән риза булмавына дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә тасвирланган вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре теркәлгән булырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документлар исемлеге бирелә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәте күрсәтелүче зат, законлы вәкиле тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча опека һәм попечительлек органы җитәкчесе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан

Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тара.

5.8. Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

Шикаять тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелгән очракта  Башкарма комитет тарафыннан дәүләт хезмәте җитәкчесе бозуларны бетерү максатында күрелергә тиешле чараларны билгели.

5.9. Әгәр шикаять канәгатьләндерелмәсә, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул итлегән карарга нигезләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында аңлатма бирелә.

Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.10. Гариза бирүчеләр башкарма комитетның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең һәм күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына)  Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять итәргә мөмкин.

Үндүрт яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә
рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
1 Кушымта

______________________________________________
______________________________________________
_____________адресы буенча яшәүче
(тулы адрес)
___________________________________________ннән
(тулысынча фамилиясе, исеме)
_____________________________
Телефон:_____________________________________
Паспорт:_____________________________________
(серия,номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

ГАРИЗА

Минем __________________________________________ елда туган улымның (кызымның) ______________________________________________________________________________________,
(балигъ булмаган баланың тулусынча фамилиясе, исеме, этисенең исеме)
фамилиясен (исемен) «___________________________________________» фамилиясенә алыштыруыгызны сорыйм.

Сәбәбе: ________________________________________________________________________
(баланың фамилиясен (исемен) алыштыру сәбәпләрен күрсәтергә)
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________

Балигъ булмаган баланың (балаларның) хокуклары кысылмый.
Минем шәхси мәгълүматларым белән эшләүгә рөхсәт бирәм.

«___» _____________ 20___ ел ______________
(имза)

Уиндүрт яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә
рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
2 Кушымта

___________________________________________________

___________________________________________________

_______________адресы буенча яшәүче
(тулы адрес)

________________________________________________ннән
(тулысынча фамилиясе, исеме)

________________________________

Телефон:__________________________________________

Паспорт:__________________________________________
(серия,номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

ГАРИЗА

Мин минем _______________________________________________ елда туган улымның (кызымның) ____________________________________________________________________________________________________,
(балигъ булмаган баланың тулусынча фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
фамилиясен (исемен) «________________________________________________» фамилиясенә алыштыруга ризалыгымны бирәм.

Сәбәбе: __________________________________________________________________________________
(баланың фамилиясен (исемен) алыштыру сәбәпләрен күрсәтергә)
____________________________________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________________________________

Балигъ булмаган баланың (балаларның) хокуклары кысылмый.
Минем шәхси мәгълүматларым белән эшләүгә рөхсәт бирәм.

«___» _______________ 20___ ел ________________
(имза)

Ундүрт яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
Кушымта (мәгълүмати)

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне агымдагы контрольдә тотучы җаваплы вазыйфаи затларның**
**РЕКВИЗИТЛАРЫ**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**


| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |
| Сектор белгече | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-84366) 3-00-44 | Ispolkom.Arsk@tatar.ru |

Үндүрт яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә
рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
4 Кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы**



Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының
«__»_________, 2019 ел, №_____
Карарына
15 Кушымта

**Ятим балалар һәм эти-әнисез калган балалар, Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар (түләүле яки түләүсез шартларда) өстеннән опека (попечительлек) билгеләү яки опекага алучы (попечитель) булу мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү**
**Административ регламенты**

1.1. Әлеге регламент Арча муниципаль районы территориясендә яшәүче ятим балалар һәм эти-әнисез калган балалар, Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар (түләүле яки түләүсез шартларда) өстеннән опека (попечительлек) билгеләү яки опекага алучы (попечитель) булу мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – хезмәт күрсәтү) стандарты һәм тәртипләрен билгели.

1.2. Хезмәт алучылар: ятим балаларны яки эти-шнисез калган балаларны гаиләгә тәрбиягә алырга теләүче, даими рәвештә Россия Федерациясе территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары.

1.3. Дәүләт хезмәте ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен башкаручы – балигъ булмаган затның яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (алга таба – опека һәм попечительлек органы).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

1.3.2. Опека һәм попечительлек органы урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

Эш режимы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш.

Төшке аш вакыты – 12.00 – 13.00.

Эчкә үтү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне аныклаучы документ буенча.

1.3.3. Опека һәм попечительлек органы телефоны: (84366)3–13–81.

1.3.4. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайты (алга таба – «Интернет» челтәре): http://www.arsk.tatarstan.ru.

1.3.5. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы бинасында урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аркылы;

2) «Интернет» челтәре аша:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында http://www.arsk.tatarstan.ru;

3) опека һәм попечительлек секторына шәхси мөрәҗәгать итеп;

4) күпфункцияле үзәктә (хезмәт күрсәтүне күпфункцияле үзәк аркылы алып булган очракта).

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә башкарыла:

- Россия Федерациясе Гражданлык кодексы 1 бүлек 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гражданлык кодексы) (РФ Законнар җыентыгы, 05.12.1994, №32, 3301 маддә);

- Россия Федерациясе Гаилә кодексы 1995 елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гаилә кодексы) (РФ законнар җыентыгы, 01.01.1996, №1, 16 маддә);

- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 28.04.20018, №17, 1755 маддә);

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 маддә);

- «Балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек башкаруның аерым сораулары турында» 2009 елның 18 маендагы 423 нче РФ Хөкүмәте карары (алга таба – 423 нче номерлы РФ Хөкүмзте карары);

- Татарстан Республикасы Гаилә кодексы 2009 елның 18 маендагы 4-ТРЗ номерлы(алга таба – ТР Гаилә кодексы) (Республика Татарстан, №8, 16.01.2009);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыелмасы, 26.05.2004, №21);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №60-61, 25.03.2008, «Татарстан Дәүләт Советы ведомосте», 2008, №3, 212 маддә);

- «Татарстан Республикасы балигъ булмаган гражданнарына карата опека һәм попечительлек эшчәнлген башкару буенча бирелгән аерым вәкаләтләрне тормышка ашыру Тәртибен раслау турында» 2008 елның 01 декабрендәге 843 нче номерлы Министрлар Кабинеты Карары (алга таба – 843 нче номерлы ТР Министрлар кабинеты карары);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 15 августындагы боерыгы белән расланган Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында Нигезләмәсе (алга таба – опека секторы турнда Нигезләмә).

1.5.Әлеге Регламентта түбәндәге термин һәм билгеләмәләр кулланыла:

- опека – яшь гражданнарның (ундүрт яше тулмаган балигъ булмаган гражданнарның) төзелеш формасы, опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (опекуннар) аларның законлы вәкилләре булып санала һәм алар исеменнән һәм алар мәнфәгате буенча юридик әһәмияткә ия булган гамәлләр башкара ала;

- попечительлек ундүрт яшьтән унсигез яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарның төзелеш формасы, опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (попечительләр) әлеге затларга үзләренең хокукларын һәм вазифаларын башкаруда ярдәм күрсәтергә, шулай ук аларны өченче затларның усаллык кылуыннан сакларга тиеш;

- опека (попечительлек) түләүсез шартларда гариза бирүче белән туганлык мөнәсәбәтләрендә торган балигъ балмаган балага карата билгеләнә, бу бала сайлау процедурасын төшереп калдыра;

- опека (попечительлек) түләүле шартларда гариза бирүче белән туганлык шартларында тормаган балигъ булмаган бала өстеннән билгеләнә, бу үз эченә бала сайлау процессын һәм балигъ булмаган опекага алынучы өстеннән түләүле шартларда опека яки попечительлек билгеләү турында килешү төзүне, шул исәптән тәрбиягә бала алучы гаилә турындагы килешүне (алга таба – тәрбиягә бала алучы гаилә) яки Россия Федерациясе субъекты белән каралган очракларда – патронат гаилә турындагы килешүне ала;

- административ регламент –Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралар һәм административ эшчәнлек вакытын һәм эзлеклелеген, структур бүлекчәләр һәм вазыйфаи затлар арасындагы хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хакимияте башкарма органнарының физик яки юридик затлар (алга таба – дәүләт хезмәте алучылар), башка дәүләт хезмәте һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгеләүче норматив хокукый документ;

- дәүләт хезмәте – дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән чикләрдә мөрәҗәгать итүче соравы буенча башкарыла торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарган вакытта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек;

- дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе $1^1$ бүлегендә каралган оешмалар яки аларның эшчеләре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта бозылган хокукларны яки законлы мәнфәгатьләрне кире кайтару яки саклау турында таләбе.

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яки муниципаль учреждениенең оештыру-хокукый формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирүче һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча, вәкаләтле оешма;

- «бер тәрәзә» принцибы – мөрәҗәгать итүче 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ маддәсендә күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү, ә дәүләт хезмәт күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар белән күпфункцияле үзәк тарафыннан мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актлар һәм хезмәттәшлек итү турында килешү нигезендә хезмәттәшлек алып бару принцибы.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбе исеме | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү исеме | Ятим балалар һәм эти-әнисез калган балалар, Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар (түләүле яки түләүсез шартларда) өстеннән опека (попечительлек) билгеләү яки опекага алучы (попечитель) булу мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү | РФ Гражданлык кодексының 31 маддәсе;<br>РФ Гаилә кодексының 145 маддәсе;<br>48-ФЗ номерлы Федераль законның 11 маддәсе;<br>423 нче номерлы РФ Хөкүмәте карары;<br>ТР Гаилә кодексының 133 маддәсе |
| 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты опека һәм попечительлек секторы | 48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>843 нче номерлы ТР Министрлар кабинеты карары |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Опекага алучы билгеләү турында карар (боерык);<br>Аны опекага алучы булырга теләк белдергән гражданин сыйфатында исәпкә кую өчен гражданинның опекага алучы булу мөмкинлеге турында карар (нәтиҗә);<br>Түләүле шартларда балигъ булмаган опекага алынучыга карата опека яки попечительлек (түләүсез шартларда опека (попечительлек)) билгеләү турында килешү | РФ Гражданлык кодексы;<br>РФ Гаилә кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>423 нче номерлы РФ Хөкүмәте карары;<br>1716 нче номерлы РФ Хөкүмәте карары |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты | Опека (попечительлек) билгеләү яки опекага алучы (попечитель) булу мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү гаризаны теркәгән көннән соң 17 эш көне эчендә башкарыла.<br>Опеа (попечительлек) башкару турында каилешү төзү опека һәм попечительлек органы тарафыннан опека (попечительлек) билгеләү турында Карар (боерык) кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә башкарыла | 423 нче номерлы РФ Хөкүмәте карары;<br>1716 нчы номерлы РФ Хөкүмәте карары |
| 2.5. Закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәте өчен кирәк һәм мәҗбүри булган документларның тулы исемлеге | 1. аны опекага алучы итеп билгеләү турында гариза яки опекага алучы (попечитель) булу мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү турында гариза (1 Кушымта);<br>- паспорт яки шәхесне раслаучы башка документ, түбәндәге документларны теркәп:<br>- опекага алучы булырга теләүче гражданинның кыскача автобиографиясе;<br>- опекага алырга теләүче затның эш урыныннан белешмә, вазыйфасын, соңгы 12 айга уртача хезмәт хакы күләмен күрсәтеп, һәм (яки) әлеге затның керемен раслаучы башка документ яки опекага алырга теләүче затның хатынының (иренең) эш урыныннан белешмә, вазыйфасын һәм соңгы 12 айга уртача хезмәт хакы күләмен күрсәтеп, һәм (яки) хатынының (иренең) керемн раслаучы башка документ;<br>- уллыкка (кызлыкка) бала, опекага (попечительлеккә), асрамага яки патронат гаиләгә ятим балалар, эти-әнисез калган балалар алырга җыенучы | РФ Гаилә кодексы;<br>423 нче номерлы РФ Хөкүмәте карары;<br>1716 нчы номерлы РФ Хөкүмәте карары |

| | | |
|---|---|---|
| | гражданнарның медицина тикшерүе турында, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы белән билгеләнгән формада нәтиҗә;<br>- гаилә кору (опекага алырга теләүче гражданин никахта торса) турында таныклык күчермәсе;<br>- РФ Гаилә кодексының 127 маддәсе, 6 пункты белән билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясендә гаиләгә әти-әнисез калган баланы тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү турында таныклык күчермәсе (баланың якын туганнарыннан, шулай ук элегрәк уллыкка алучылар булган затлардан, әгәр уллыкка алу кирек агылмаган булса, йөкләнгән вазыйфалардан читләштерелмәгән очракта элегрәк яки хәзер опекага алучы (попечитель) булып торучы затлардан тыш). Әлеге таныклык формасы Россия Федерациясе Фән һәм мәгариф министрлыгы тарафыннан раслана.<br><br>Әлеге пукнтның 2 подпунктында саналган документлар аларны биргән көннән соң бер ел дәвамында гамәлдә, медицина тикшерүе турында нәтиҗә – 6 ай дәвамында. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм алар бирергә хокуклы булган документларның тулы исемлеге | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында белгеч тарафыннан соратып алына торган документлар:<br>Опекага алучы булырга теләүче гражданинның яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында мәгълүмат;<br>Гражданинда Россия Федерациясе Гаилә кодексының 146 маддәсе 1 пункты өченче һәм дүртенче кызыл юлда күрсәтелгән очраклары булмавын раслаучы мәгълүмат;<br>пенсия алу турында һәм аның күләме турында мәгълүмат (төп керем чыганагы булып мәҗбүри пенсия иминиятләве яки башка пенсия тлүәүләре торган затлар өчен);<br>гаилә кору (опекага алырга теләүче гражданин никахта торса) турында таныклык күчермәсе;<br>Россия Федерациясе Гаилә кодексының 127 маддәсе 6 пунктында каралган тәртиптә Россия Федерациясе территориясендә әти-әнисез калган балаларны тәрбиягә гаиләгә алырга теләүче затларны әзерләү курслары үтү турында таныклык күчермәсе.<br>Әлеге документлар опека һәм попечительлек секторы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә, бирелгән мәгълүматның конфиденциальлеген тәэмин итү максатында, гариза бирүчене алдан кисәтеп, башкарыла. | 423 нче номерлы РФ Хөкүмәте карары |
| 2.7. Норматив хокукый актлар белән каралган очракларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган һәм хезмәт күрсәтә торган башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла торган дәүләт хакимияте һәм аның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Гариза бирүченең яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итмәве | |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Әгәр гариза бирүче (ләр) түбәндәге категорияләргә караса:<br>- әти-әни хокукыннан мәхрүм ителгән затлар;<br>- хөкем ителгән, шәхеснең тормышына һәм сәламәтлегенә каршы, ирегенә каршы, намусына һәм абруена каршы (стационар шартларда психиатрия ярдәме күрсәтүче медицина оешмасына законсыз урнаштырудан тыш), шәхеснең җенес кагылгысызлыгына һәм җенес иркенә каршы, балигъ булмаган затларга һәм гаиләгә каршы, халык сәламәтлегенә һәм җәмәгать әхлагына, кешелекнең тынычлыгына һәм куркынычсызлыгына каршы җинаять эзәрлеклəвенә дучар ителгән (реабилитацияләү нәтиҗәләре буенча җинаять эзәрлекләве туктытылган затлардан тыш) затлар;<br>- авыр һәм аеруча авыр җинаять кылган өчен үз көчендәге хөкем карары булган затлар;<br>- хроник эчкечелек яки наркомания белән авыру затлар, опекага алучы (попеечитель) вазыйфаларын башкарудан яитләштерелгән затлар, әти-әни хокукыннан читләштерелгән затлар, элеккеге уллыкка алучылар, әгәр уллыкка алу алар гаебе белән кире кагылган булса, сәламәтлек буенча (РФ Гаилә кодексының 127 маддәсе 1 пункты) бала тәрбияләү буенча вазыйфаларны башкара алмаучы затлар<br>- РФ Гаилә кодексының 127 маддәсе 10 бүлеге белән билгеләнгән тәртиптә әзерлек үтмәгән затлар (баланың якын туганнарыннан, шулай ук элегрәк уллыкка алучылар булган затлардан, әгәр уллыкка алу кирек агылмаган булса, йөкләнгән вазыйфалардан читләштерелмәгән очракта элегрәк яки хәзер опекага алучы (попечитель) булып торучы затлардан тыш);<br>- мондый гаилә рөхсәт ителгән дәүләт законнары нигезендә рәсмиләштерелгән һәм гаилә булып танылган бер җенестәге затлар белән яшәүче затлар, шулай ук әлеге дәүләт гражданнары булып саналучы, гаилә булып рәсмиләштерелмәгән затлар.<br>2. Гариза бирүче тарафыннан алар нигезендә бөүләт хезмәте үкрсәтүгә хокук билгеләнә торган тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүмат бирү;<br>3. Тапшырылган документларның 2.5. пукнтында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве.<br>4. Кандидатның якын туганнары гаиләгә бала алуга каршы булу.<br>Опека (попечительлек) рәсмиләштерүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә. | |
| 2.11. Әлеге түләүне исәпләү турында мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргән вакытта һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алган вакытта чиратта көтүнең максималь вакыты | Көтеп утыруның (хезмәт күрсәтүнең) максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Аерым категория кешеләр өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты | Гариза кергән көнне | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | 1. Гариза түбәндәге адрес буенча тапшырыла:<br>Арча шәһәре, Советлар мәйданы урамы, 12 йорт, опека һәм попечительлек секторы.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазланган бинада башкарыла;<br>3. Бинада гаризалар кабул итү өчен сектор белгеченең эш урыны хезмәтне тулысынча күрсәтергә мөмкинлек бирүче электрон белешмә-хокукый системалар, оргтехника белән тәэмин ителгән шәхси компьютер белән җиһазландырыла.<br>4. Документлар тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазлана һәм документлар тутыру үрнәкләре белән тәэмин ителә.<br>5. Инвалидларга хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыкларсыз керү тәэмин ителә, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм чыгу юлларына, дәүләт хезмәте күрсәтү урынына барып җитү максатында объект буйлап мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итү тәэмин ителә.<br>6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны исәпкә алып, урнаштырыла. | Вазыйфаи регламентлар, вазыйфаи күрсәтмәләр |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Хезмәт күрсәтүнең аңлаешлылыгы күрсәткечләре:<br>- бинаның җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы;<br>- җитәрлек белгечләр булу, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>- мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә башкарма комитетның мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү бердәм порталында хезмәт күрсәтү тәртибе, ысуллары, вакыты турында тулы мәгълүмат булу;<br>- инвалидларга башкалар белән беррәттән дәүләт хезмәте алырга комачаулаучы каршылыкларны бетерү<br>Хезмәт күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре:<br>-гариза бирүчедән документлар кабул итеп алган һәм аңа документлар биргән вакытта чиратлар булмау;<br>- дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозмау;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирмәү;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза | |

| | | |
|---|---|---|
| | бирүчеләргә игътибарсызлык күрсәтүенә шикаять бирмәү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратып алу биргән очракта һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен алган вакытта муниципаль хезмәт күрсәтә торган вазыйфаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр аралашуы күздә тотыла.<br>Хезмәттәшлек вакыты регламент белән билгеләнә.<br>Хезмәт күпфункцияле үзәктә күрсәтелми. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Хезмәт электрон формада күрсәтелми | |

## 3. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкару составы, эзлеклелеге һәм вакыты, аларны башкару тәртибенә таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау:

3.1.1. Ятим балалар һәм әти-әнисез калган балалар, Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар (түләүле яки түләүсез шартларда) өстеннән опека (попечительлек) билгеләү яки опекага алучы (попечитель) булу мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчеләргә консультация бирү;

2) гаризаны, документларны кабул итү (әлеге регламентның 2.5 пунктын кара);

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратып алу формалаштыру һәм юллау;

4) торак-көнкүреш шартларын тикшерү (2 Кушымта);

5) опекага алучы (попечитель) булу мөмкинлеге турында нәтиҗә әзерләү;

6) гариза бирүчене опекага алучы (попечитель) итеп билгеләү турында боерык әзерләү;

7) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен бирү;

8) балигъ булмаган опекага алынучы өстеннән түләүле шартларда опека яки попечительлек башкару турында килешү төзү;

9) нигезләр булган очракта гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат җибәрү.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема әлеге Административ регламентка 5 Кушымтада бирелә.

3.2. Консультация бирү

Мәгълүмат һәм консультация бирү буенча процедуралар кысаларында гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибен җайлаучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;

- гариза бирүчеләрне, шулай ук аларның законлы вәкилләрен ятим балалар һәм әти-әнисез калган балалар, Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар (түләүле яки түләүсез шартларда) өстеннән опека (попечительлек) билгеләү яки опекага алучы (попечитель) булу мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән таныштыра;

- конкрет затны опекага алучы яки попечитель итеп билгеләү өчен кирәкле документлар исемлеген бирә.

Консультация гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Процедура нәтиҗәсе: документлар составы һәм хезмәт күрсәтү буенча башка сораулар буенча консультация.

Консультация һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедуралар башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

Гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирүче белгеч, шәхси мәгълүматларны исәпкә алып, консультациянең грамоталыгы, тулылыгы һәм ачыклыгы өчен шәхси җавап бирә.

3.3. Гариза, документлар кабул итү

3.3.1. Гариза бирүче, 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән үзе гариза тапшыра (гариза бирүче белән килешеп).

3.3.2. Кабул итү алып баручы опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүченеж шәхесен һәм яшәү урынын билгели.

Гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ булмаса, яки гариза бирүче тиешле органга мөрәҗәгать итмәсә, гариза һәм документларны кабул итеп алудан баш тартыла.

Гариза бирүченең шәхесе расланса һәм ул тиешле органга мөрәҗәгать итсә, опека һәм попечительлек секторы белгече гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны кабул итеп ала, аннан соң әлеге Регламентның 3.3.3 подпункты белән карарлган процедуралар башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар.

Башкаруның максималь вакыты – 30 минут

3.3.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүче тапшырган документларда булган мәгълүматны тикшерә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләр булган очракта, опека һәм попечительлек белгече баш тарту турында хат әзерли һәм аны имзалаган көннән соң 2 көн эчендә гариза бирүчегә җиткерә. Шул ук вакытта гариза бирүчегә барлык документлар кире кайтарыла һәм карарны шикаять итү тәртибе аңлатыла һәм әлеге Регламентның 3.9. пункты белән каралган процедуралар башкарыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән көннән соң 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм опека (попечительлек) билгеләү турында боерык әзерләү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратып алу әзерләү һәм җибәрү.

3.4.1 Опека һәм попечительлек белгече (гариза бирүче белән килештереп) ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү системасы аркылы әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны җибәрү турында электрон формада соратып алу юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән көннән 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында юлланган соратып алу.

3.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы опека һәм попечительлек секторы органнары соратуы буенча автоматлаштырылган режимда башкарыла:

- соратып алуны эшкәртү һәм соратылган мәгълүматны эзләү;

- ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү аркылы соратып алынган мәгълүматны формалаштыру, соратып алынган мәгълүмат булмаган очракта, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, соратып алынган мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар опека һәм попечительлек органнарына соратып алу кергән вакыттан 5 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: соратып алуга җавап яки әлеге Регламентның 3.4 пунктында күрсәтелгән мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.5. Торак-көнкүреш шартларын тикшерү.

3.5.1. Опекага алучы булырга теләк белдергән гражданинны баланың опекуны итеп билгеләү яки аны опекун булырга теләк белдерүче гражданин сыйфатында исәпкә кую максатында опека һәм попечительлек секторы блегечләре тарафыннан гариза бирүченең торак-көнкүреш шартлары тикшерелә, аның сәбәпләре, бала тәрбияләүгә сәләте, гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләр ачыклана. Тикшерү нәтиҗәләре буенча гражданинның тормыш шартларын тикшерү акты рәсмиләштерелә, ул тикшерү үткәргән затларның имзалары белән раслана.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар опека секторы белгече тарафыннан соратып алынган мәгълүмат тиешле вәкаләтле органнар тарафыннан расланганнан соң 3 эш көне дәвамында башкарыла.

Тикшерү акты опекага алучы буылрга теләүче гражданинның тормыш шартларын тикшергән көннән соң 3 көн эчендә рәсмиләштерелә, тикшерү үткәргән вәкаләтле опека һәм попечительлек секторы белгече тарафыннан имзалана һәм опека һәм попечительлек секторы җитәкчесе тарафыннан раслана.

Тикшерү акты 2 нөсхәдә төзелә, аның берсе актны раслаганнан соң 3 көн эчендә опекага алырга теләк белдергән гражданинга бирелә, икенчесе опека һәм попечительлек секторында саклана.

Процедуралар нәтиҗәсе: гариза бирүченең тормыш шартларын тикшерү акты, бер нөсхәсен гариза бирүчегә тапшыру.

3.6. Опека (попечительлек) билгеләү турында карар (боерык), опекага алучы (попечитель) булу яки булмау мөмкинлеге турында карар (нәтиҗә) әзерләү.

3.6.1. Опека һәм попечительлек секторы блегече опека секторы белгече тарафыннан соратып алынган мәгълүматларны тиешле вәкаләтле органнар раслаганнан соң опекага алучыны билгеләү турында карар (боерык) проекты (аны опекага алучы булырга теләк белдергән гражданин сыйфатында исәпкә куярга нигез булып торучы гражданинның опекага алучы булу мөмкинлеге турында карар (нәтиҗә)) яки, баш тарту нигезләрен күрсәтеп, опекага алучы билгеләүдән баш тарту турында карар әзерли һәм аны опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә раслауга юллый. Опекага алучы булу мөмкин булмавы турында нәтибә әзерләү турында карар кабул иткән очракта опека органы белгече 3.8 пункты белән җитәкчелек итә.

Гражданинның опекага алучы (попечитель) булу мөмкинлеге турында нәтиҗә аны биргән көннән соң 2 ел эчендә гамәлдә һәм опекага алучы (попечитель) булырга теләк белдергән гражданинга закон белән билгеләнгән тәртиптә яшәүурыны буенча опека һәм попечительлек органына, үзе теләгән башка опека һәм попечительлек органына яки әти-әнисез калган балалар турында дәүләт мүгълүматлар банкына мөрәҗәгать итү өчен нигез булып тора.

Процедуралар нәтиҗәсе: опекага алучы (попечитель) билгеләү турында карар (боерык), опекага алучы (попечитель) булу яки булмау мөмкинлеге турында карар (нәтиҗә).

3.6.2. Опека һәм попечительлек белгече 3.6.1 пунктында каралган процедуралар тәмамланганнан соң карарның бер нөсхәсен гариза бирүчегә тапшыра. Тискәре нәтиҗә чыгарган очракта опекага алучы (попечитель) була алмау турында нәтиҗәне шәхсән кулына тапшыра.

Процедуралар нәтиҗәсе: опека билгеләү, опекагаалучы булу яки була алмау мөмкинлеге турында нәтиҗә.

3.7. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен гариза бирүчегә тапшыру.

3.7.1. Опека һәм попечительлек белгече, имзаланган карар (боерык) алгач, аны терки. Опекага алучы билгеләү турында карар (боерык) опека һәм попечительлек секторы тарафыннан аны имзалаганнан соң 3 көн эчендә гариза бирүчегә тапшырыла. Тискәре нәтиҗә чыгарган очракта баш тарту турында хат шәхсән кулга тапышырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.7.1. подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң өч көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: 3.8 пункт нигезендә гариза бирүчегә дәүләт хзмәте күрсәтүнәтиҗәсен яки баш тарту турында хат тапшыру.

3.8. Гариза бирүчегә опека (попечительлек) билгеләүдән баш тарту турында хат яки опекага алучы (попечитель) булу алмау турында нәтиҗә җибәрү.

3.8.1. Опекага алучы (попечитель) булу мөмкинлеге булмау турында бәяләмә бирү хакында карар кабул ителгән очракта, опекага алучы (попечитель) булырга мөмкин булмавы турында бәяләмә проектын әзерли. опекага алучы (попечитель) булу мөмкинлеге булмау турында әзерләнгән бәяләмә опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә имза салуга җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар баш тарту өчен нигезләрне ачыкланган вакыттан өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: опекага алучы (попечитель) булу мөмкинлеге булмау турында имзаланган бәяләмә.

3.8.2. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече опекага алучы (попечитель) булу мөмкинлеге булмау турында нәтиҗәне мөрәҗәгать итүчегә җиткерә. Шул ук вакытта гариза бирүчегә барлык документлар кире кайтарыла һәм карар өстеннән шикаять бирү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.8.1. яки 3.8.2. подпунктларында каралган процедураны тәмамлаганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү.

3.9. Балигъ булмаган балаларга карата түләүле шартларда опека һәм попечительлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү.

3.9.1. Опека (попечительлек) түләүле шартларда билгеләнгән очракта, опека һәм попечительлек бүлеге белгече балигъ булмаган балага карата түләүле шартларда опека һәм попечительлекне гамәлгә ашыру турында шартнамә төзи, шул исәптән тәрбиягә алган гаилә турында опекага алучы төзи һәм опекага алучы (попечитель) имзасын куйдыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.7.1. пункты белән каралган процедураны тәмамлаганнан соң 5 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: рәсмиләштерелгән һәм опекун (попечитель) имзалаган килешү.

3.9.2. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече шартнамәгә опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә кул куйдыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.9.1 пунктында каралган процедураны тәмамлаганнан соң 5 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: төзелгән килешү.

3.9.3. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече шартнамәнең 1 нөсхәсен мөрәҗәгать итүчегә 3.9.2 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән соң 2 көн эчендә бирә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә шартнамә тапшыру.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формасы

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларын үтәүне тикшерүне, карар кабул итүне һәм күпфункцияле үзәкнең (хезмәт күпфункцияле үзәк аркылы күрсәтелсә), опека һәм попечительлек бүлегенең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап бирүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларының хокукый экспертизасын үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау;
- кабул итлегән тәртиптә делопроизводство алып баруны тикшерү;
- кабул ителгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү үткәрү процедураларына контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерү үткәргән вакытта дәүләт хезмәте күрсәтү (комплексլы тикшерүләр) белән бәйле яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык сораулар каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта һәм карар кабул иткән вакытта гамәлләрне башкаруны тикшерүне башкару максатында күпфункцияле үзәк, опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затлар исемлеге күпфункцияле үзәкнең, опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы гариза бирүченең мөрәҗәгатен вакытында карамаган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезләнмәгән рәвештә баш тарткан өчен җавап бирә.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, аларның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелгән очракта), опека һәм попечительлек секторы хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Арча муниципаль районы башкарма комитетына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итәргә мөкин:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган документлар, мәгълүмат яки гамәл кылу таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү вакыты яки тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылганда, әгәр туктатылу нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта мөрәҗәгать итүчедән беренче тапкыр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документлар тапшырган вакытта булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү.

5.2. Шикаять почта аркылы язма рәвештә кәгазь битендә яки электрон формада җибәрелергә, шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәткән очракта шикаять күпфункцияле үзәк аркылы җибәрелә ала.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең документларны кабул итүдән баш тартуына яки киткән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять биргән очракта яки мондый төзәтүләрне башкаруның кабул ителгән вакыты бозылуга шикаять биргән очракта – аны теркәгән көннән соң 5 эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исемен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки муниципаль хезмәткәрнең исемен;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән риза булмавына дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә тасвирланган вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре теркәлгән булырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документлар исемлеге бирелә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәте күрсәтелүче зат тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта Башкарма комитет тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта ачыкланган бозуларны кичекмәстән бетерү максатында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле гамәлләр турында әйтелә.

5.9. Әгәр шикаять канәгатьләндерелмәсә, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул итлгегән карарга нигезләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында аңлатма бирелә.

5.10. Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Ятим балалар һәм әти-әнисез калган балалар, Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар (түләүле яки түләүсез шартларда) өстеннән опека (попечительлек) билгеләү яки опекага алучы (попечитель) булу мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
1 Кушымта

________________________________________________

________________________________________________

_______________адресы буенча яшәүче
(тулы адрес)

_____________________________________________ннән
(тулысынча фамилиясе, исеме)

________________________________

Телефон:________________________________________
Паспорт:________________________________________
(серия,номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

ГАРИЗА

Мин,__________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганочракта)

Гражданлык_______________ Шәхесне раслаучы документ:________________________

______________________________________________________________________
(кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)

Яшәү урыны____________________________________________________________,
(теркәлү белән расланган яшәү урыны адресы)

Тору урыны____________________________________________________________,
(фактик тору урыны адресы)

☐ миңа опекага алучы (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирүегезне үтенәм

☐ миңа тәрбиягә алган ата-ана булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирүегезне үтенәм

☐ миңа опекага (попечительлеккә) ______________________

________________________________________________________бирүегезне үтенәм
(баланың (балаларның) фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу көне, ае, елы)

☐ миңа опекага (попечительствога) түләүле шартларда

________________________________________________________ бирүегезне үтенәм
(баланың (балаларның) фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу көне, ае, елы)

Россия Федерациясе гаилә законы билгеләгән башка формаларда миңа баланы (балаларны) опекага (попечительлеккә) алырга яисә гаиләгә тәрбиягә кабул итәргә торак шартлары, сәламәтлек торышы һәм эш үзенчәлеге мөмкинлек бирә.
Үзем турында өстәмә түбәндәгеләрне хәбәр итә алам:______________________________
(гражданинда

______________________________________________________________________
балаларны тәрбияләүдә кирәкле белем һәм күнекмәләр булуы, шул исәптән

______________________________________________________________________
белеме турында, һөнәри эшчәнлек, опекунлыкка яки попечительлеккә

______________________________________________________________________
кандидатлар әзерләү программаларын узуы һ.б. күрсәтелә)

Мин, ________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, әтисының исеме)

әлеге гаризада һәм мин биргән документларда булган шәхси мәгълүматларны эшкәртү һәм кулланугa ризалык бирәм.

________________________

(имза, дата)

Ятим балалар һәм әти-әнисез калган балалар, Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар (түләүле яки түләүсез шартларда) өстеннән опека (попечительлек) билгеләү яки опекага алучы (попечитель) булу мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
2 Кушымта

Балигъ булмаган гражданинны опекага алучы яки попечитель булырга яки әти-әнисез калган балаларны Россия Федерациясе гаилә законнары белән билгеләнгән башка формаларда гаиләгә тәрбиягә алырга теләүче гражданинның тормыш шартларын тикшерү акты

Тикшерү датасы "__" _________________ 20__ ел.

Тикшерү үткәргән кешенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), вазыйфасы ___________
______________________________________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме
____________________________________________________________нең тормыш шартлары тикшерелде;
(булган очракта), туу көне)

Шәхесне раслаучы документ: _____________________________________________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
(кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)

Тору урыны (теркәү урыны буенча) _________________________________________________________
______________________________________________________________________________________

Яшәү урыны (яшәү урыны буенча)______________________________________________________________

Белеме __________________________________________________________________________
Профессиональ эшчәнлек _________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
(адрес, биләгән вазыйфаны, эш телефонын күрсәтеп, эш урыны)
_____________________________________________________________________ яшәүче торак мәйдан
фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта)

_____ кв. м тәшкил итә, __________________________ бүлмәдән тора, һәр бүлмәнең мәйданы: ___ кв.м, ______________ кв. м, ________ кв. м.
___этажда _______ этажлы йортта.

Йорт сыйфаты (кирпеч, панель, агач һ.б.; яхшы хәлдә, тузган, аварияле; бүлмәләр коры, якты, үтә торган, тәрәзәләр саны һ.б.) _________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________

Йорт һәм торак мәйданының төзекләндерелеше (су үткәргеч, канализация, җылыту, газ, ванна, лифт, телефон һ.б.): _________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________

Торак мәйданның санитар-гигиеник торышы (яхшы, канәгатьләнерлек, канәгатьләнерлек түгел) ______________________________________________________________________________________

Бала өчен сектор бүлмәсе, почмагы, йокы, уен, шөгыльләр өчен урын) булу _________________________
______________________________________________________________________________________

Торак мәйданда яши (тиешле тәртиптә теркәлгән һәм чынлап яши):

| Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта) | Туу елы | Эш урыны, вазыйфасы яки уку урыны | Туганлык мөнәсәбәтләре | Кайчаннан әлеге торак мәйданда яши |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

Гражданинның гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәт ___________________________________

___________________________________________________________________________

(гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәт характеры, балалар белән аралашу үзенчәлекләре, балалар

_______________________________________________________________

арасындагы үзара мөнәсәбәт һ.б.)

Гражданинның шәхси сыйфатлары (характер үзенчәлекләре, гомуми мәдәният, балалр белән аралашу тәҗрибәсе һ.б.)_______________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________

Балигъ балмаган баланы гаиләгә алу өчен гражданинның сәбәпләре ________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________

Тикшерүнең өстәмә мәгълүматы ______________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________.

Балигъ булмаган гражданинны опекага алучы яки попечитель булырга яки әти-әнисез калган балаларны Россия Федерациясе гаилә законнары белән билгеләнгән башка формаларда гаиләгә тәрбиягә алырга теләүче гражданинның тормыш шартлары
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________

(Канәгатьләнерлек/канәгатьләнерлек түгел конкрет шартларны күрсәтеп)


Тикшерү үткәргән затның имзасы _________________________________

| | | |
|---|---|---|
| ______________________________ | ____________ | ____________________ |
| (опека һәм попечительлек органы җитәкчесе) | (имза) | (фамилиясе, исеме, әтисенең исеме) |

М.П.

Ятим балалар һәм әти-әнисез калган балалар, Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар (түләүле яки түләүсез шартларда) өстеннән опека (попечительлек) билгеләү яки опекага алучы (попечитель) булу мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
3 Кушымта

**Блок-схема последовательности действий**
**по предоставлению государственной услуги**



Ятим балалар һәм әти-әнисез калган балалар, Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар (түләүле яки түләүсез шартларда) өстеннән опека (попечительлек) билгеләү яки опекага алучы (попечитель) булу мөмкинлеге турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
Кушымта (мәгълүмати)

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне агымдагы контрольдә тотучы җаваплы вазыйфаи затларның**
**РЕКВИЗИТЛАРЫ**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**

| **Вазыйфа** | **Телефон** | **Электрон адрес** |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |
| Сектор белгече | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты**

| **Вазыйфа** | **Телефон** | **Электрон адрес** |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-84366) 3-00-44 | Ispolkom.Arsk@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының
«__»_________, 2019 ел, №_____
Карарына
16 Кушымта

**Балигъ булмаган затны тулысынча эмансипацияләү (балигъ булмаган затны тулысынча эшкә яраклы дип тану) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү**
**Административ регламенты**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге регламент балигъ булмаган затны тулысынча эмансипацияләү (балигъ булмаган затны тулысынча эшкә яраклы дип тану) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандарты һәм тәртипләрен билгели.

1.2. Хезмәтне алучылар: эмансипацияләнергә теләүче балигъ булмаган Россия Федерациясе гражданнары (алга таба – гариза бирүчеләр).

1.3. Дәүләт хезмәте ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен башкаручы – балигъ булмаган затның яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (алга таба – опека һәм попечительлек органы).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

1.3.2. Опека һәм попечительлек органы урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

Эш режимы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш.

Төшке аш вакыты – 12.00 – 13.00.

Эчкә үтү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне аныклаучы документ буенча.

1.3.3. Опека һәм попечительлек органы телефоны: (84366)3–13–81.

1.3.4. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайты (алга таба – «Интернет» челтәре): http://www.arsk.tatarstan.ru.

1.3.5. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы бинасында урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аркылы;

2) «Интернет» челтәре аша:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында http://www.arsk.tatarstan.ru;

3) опека һәм попечительлек секторына шәхси мөрәҗәгать итеп;

4) күпфункцияле үзәктә (хезмәт күрсәтүне күпфункцияле үзәк аркылы алып булган очракта).

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә башкарыла:

- Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гражданлык кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 05.12.1994, №32, 3301 маддә);

- Россия Федерациясенең гражданлык процессуаль кодексы 2002 елның 14 ноябрендәге 138-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гражданлык процессуаль кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 18.11.2002, №46, 4532 маддә);

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 маддә);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №43-44, 02.03.2004);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Ватаным Татарстан, 22.03.2008, №54, Республика Татарстан, №60-61);

- «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары (Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010. №46, 2144 маддә; 20.12.2011);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 15 августындагы боерыгы белән расланган Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында Нигезләмәсе (алга таба – опека секторы турнда Нигезләмә).

1.5.Әлеге Регламентта түбәндәге термин һәм билгеләмәләр кулланыла:

- эмансипация – эти-әнисе, уллыкка алучылар яки попечитель ризалыгы, әгәр андый ризалык булмаса, суд карары нигезендә балигъ булмаган затны тулысынча эшкә яраклы дип игълан итү;

- административ регламент –Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралар һәм административ эшчәнлек вакытын һәм эзлеклелеген, структур бүлекчәләр һәм вазыйфаи затлар арасындагы хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хакимияте башкарма органнарының физик яки юридик затлар (алга таба – дәүләт хезмәте алучылар), башка дәүләт хезмәте һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгеләүче норматив хокукый документ;

- дәүләт хезмәте – дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән чикләрдә мөрәҗәгать итүче соравы буенча башкарыла торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарган вакытта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек;

- дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе $1^1$ бүлегендә каралган оешмалар яки аларның эшчеләре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта бозылган хокукларны яки законлы мәнфәгатьләрне кире кайтару яки саклау турында таләбе.

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яки муниципаль учреждениенең оештыру-хокукый формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирүче һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча, вәкаләтле оешма;

- «бер тәрәзә» принцибы – мөрәҗәгать итүче 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ маддәсендә күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү, ә дәүләт хезмәт күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар белән күпфункцияле үзәк тарафыннан мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актлар һәм хезмәттәшлек итү турында килешү нигезендә хезмәттәшлек алып бару принцибы.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбе исеме | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте исеме | Балигъ булмаган затны тулысынча эмансипацияләү (балигъ булмаган затны тулысынча эшкә яраклы дип тану) турында карар кабул итү | РФ Гражданлык кодексының 27 маддәсе |
| 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (балигъ булмаган затның теркәлү урыны буенча) | 8-ТРЗ номерлы ТР Законының 5 маддәсе |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе | Боерык формасында балигъ булмаган баланы эмансипацияләү турында карар яки хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат | РФ Гражданлык кодексының 27 маддәсе |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты | Гражданнарның дәүләт хезмәте күрсәтүгә кагылышлы гаризаларын карау аларны теркәгәннән соң 15 көн эчендә башкарыла | |
| 2.5. Закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәте өчен кирәк һәм мәҗбүри булган документларның тулы исемлеге | 1. балигъ булмаган затның гаризасы (1 Кушымта);<br>2. балигъ булмаган затларның әти-әнисенең яки башка законлы вәкилләренең гариза-ризалыгы (2 Кушымта);<br>3. әти-әнисенең паспортлары күчермәсе;<br>4. балигъ булмаган затның туу турында таныклыгы күчермәсе;<br>5. балигъбулмаган затның урта белем турында таныклык күчермәсе;<br>6. балигъ булмаган затның хезмәт кенәгәсе (хезмәт килешүе) яки шәхси эшмәкәр буларак теркәлү турында таныклык күчермәсе.<br><br>Гаризалар һәм документлар күчермәләре төп нөсхә булган очракта 1 нөсхәдә тапшырыла. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм алар бирергә хокуклы булган документларның тулы исемлеге | Әлеге категориягә караган документлар бирү таләп ителми | |
| 2.7. Норматив хокукый актлар белән каралган очракларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган һәм хезмәт күрсәтә торган башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла торган дәүләт хакимияте һәм аның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен | Гражданинның яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итмәве | |

| | | |
|---|---|---|
| нигезләрнең тулы исемлеге | | |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>- тапшырылган документларның әлеге Административ регламентның 2.5 пукнтында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве; | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә. | |
| 2.11. Әлеге түләүне исәпләү турында мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргән вакытта һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алган вакытта чиратта көтүнең максималь вакыты | Көтеп утыруның (хезмәт күрсәтүнең) максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Аерым категория кешеләр өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты | Гариза кергән көнне | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | 1. Гариза түбәндәге адрес буенча тапшырыла:<br>Арча шәһәре, Советлар мәйданы урамы, 12 йорт, опека һәм попечительлек секторы.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазланган бинада башкарыла;<br>3. Бинада гаризалар кабул итү өчен сектор белгеченең эш урыны хезмәтне тулысынча күрсәтергә мөмкинлек бирүче электрон белешмә-хокукый системалар, оргтехника белән тәэмин ителгән шәхси компьютер белән җиһазландырыла.<br>4. Документлар тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазлана һәм документлар тутыру үрнәкләре белән тәэмин ителә.<br>5. Инвалидларга хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыкларсыз керү тәэмин ителә, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм чыгу юлларына, дәүләт хезмәте күрсәтү урынына барып җитү максатында объект буйлап мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итү тәэмин ителә.<br>6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны исәпкә алып, урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Хезмәт күрсәтүнең аңлаешлылыгы күрсәткечләре:<br>- бинаның җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы;<br>- җитәрлек белгечләр булу, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>- мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә башкарма комитетның мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү бердәм | |

| | | |
|---|---|---|
| | порталында хезмәт күрсәтү тәртибе, ысуллары, вакыты турында тулы мәгълүмат булу;<br>- инвалидларга башкалар белән беррәттән дәүләт хезмәте алырга комачаулаучы каршылыкларны бетерү<br>Хезмәт күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре:<br>-гариза бирүчедән документлар кабул итеп алган һәм аңа документлар биргән вакытта чиратлар булмау;<br>- дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозмау;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирмәү;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә игътибарсызлык күрсәтүенә шикаять бирмәү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратып алу биргән очракта һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен алган вакытта муниципаль хезмәт күрсәтә торган вазыйфаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр аралашуы күздә тотыла.<br>Хезмәттәшлек вакыты регламент белән билгеләнә. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Хезмәт электрон формада күрсәтелми | |

**3. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкару составы, эзлеклелеге һәм вакыты, аларны башкару тәртибенә таләпләр**

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау:

3.1.1. Балигъ булмаган затны тулысынча эмансипацияләү турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчеләргә консультация бирү;

2) гаризаны һәм документларны кабул итү (әлеге регламентның 2.5 пунктын кара);

3) балигъ булмаган затны эмансипацияләү турында рөхсәт әзерләү;

4) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

5) нигезләр булган очракта гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема әлеге Административ регламентка 4 кушымтада бирелә.

3.2. Консультация күрсәтү

Мәгълүмат һәм консультация бирү буенча процедуралар кысаларында гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирү өчен җаваапли опека һәм попечительлек секторы белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибен җайлаучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;

- гариза бирүчеләрне, шулай ук аларның законлы вәкилләрен балигъ булмаган затны эмансипацияләү турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән таныштыра;

- балигъ булмаган затны эмансипацияләү турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар исемлеген бирә.

Консультация гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Процедура нәтиҗәсе: документлар составы һәм хезмәт күрсәтү буенча башка сораулар буенча консультация.

Консультация һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедуралар башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

3.3. Гариза бирүче, 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән үзе гариза тапшыра.

Гаризалар һәм документлар кабул итү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- гражданинның шәхесен, балигъ булмаган затның яшәү урынын билгели;

- гариза бирүче тапшырган кирәкле документларның барлыгын тикшерә. Кирәкле документлар булмаган очракта җитмәгән документларны тапшырырга тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларны кабул итүне таләп итсә, документлар кабул ителә.

- документлар пакеты формалаштыра.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән документлар.

Гамәлләрне башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта опека һәм попечительлек, күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелсә) белгече гариза бирүчегә гариза һәм документлар алу, теркәлү номеры турында хәбәр итә, аннан соң әлеге Регламентның 3.4 подпунктында күрсәтелгән процедуралар башкарыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән вакыттан соң 1 көн эчендә 15 минут вакыт аралыгында башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язмасы.

3.4 Опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүче тапшырган документлардагы мәгълүматны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергәннән соң 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәт бирү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.5.1 Тапшырылган документлар нигезендә опека һәм попечительлек секторы белгече эмансипацияләү турында боерык проекты әзерли һәм аны килештерү һәм раслату өчен опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә җибәрә яки тиешле аныклау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: ундүрт яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү турында боерык яки 3.7 пункты нигезендә әзерләнгән хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.6. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен тапшыру.

3.6.1. Опека һәм попечительлек секторы белгече, имзаланган боерыкны алгач, аны терки һәм гариза бирүчегә тапшыра. Тискәре нәтиҗә булган очракта баш тарту турында хатны 3.7.пункты нигезендә шәхсән кулына тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.5.1 подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 3 эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.7. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат тапшыру.

3.7.1 Опека һәм попечительлек секторы белгече боерык бирүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты әзерли.

Әзерләнгән баш тарту турында хат проектын Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар баш тарту өчен нигезләр ачыкланган көннән соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзалауга юлланган баш тарту турында хат проекты.

3.7.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек секторы белгеченә кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзаланган баш тарту турында хат.

3.7.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече баш тарту турында хатны аны имзалаган көннән соң 1 эш көне эчендә гариза бирүчегә юллый. Шул ук вакытта гариза бирүчегә карарны шикаять итү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.7.2. подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

**4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формасы**

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларын үтәүне тикшерүне, карар кабул итүне һәм күпфункцияле үзәкнең (хезмәт күпфункцияле үзәк аркылы күрсәтелсә), опека һәм попечительлек бүлегенең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап бирүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларының хокукый экспертизасын үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау;
- кабул итлегән тәртиптә делопроизводство алып баруны тикшерү;
- кабул ителгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү үткәрү процедураларына контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерү үткәргән вакытта дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык сораулар каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта һәм карар кабул иткән вакытта гамәлләрне башкаруны тикшерүне башкару максатында күпфункцияле үзәк, опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затлар исемлеге күпфункцияле үзәкнең, опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы гариза бирүченең мөрәҗәгатен вакытында карамаган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезләнмәгән рәвештә баш тарткан өчен җавап бирә.

**5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, аларның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү**

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелгән очракта), опека һәм попечительлек секторы хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Арча муниципаль районы башкарма комитетына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итәргә мөкин:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган документлар, мәгълүмат яки гамәл кылу таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү вакыты яки тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылганда, әгәр туктатылу нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта мөрәҗәгать итүчедән беренче тапкыр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документлар тапшырган вакытта булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү.

5.2. Шикаять почта аркылы язма рәвештә кәгазь битендә яки электрон формада җибәрелергә, шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәткән очракта шикаять күпфункцияле үзәк аркылы җибәрелә ала.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең документларны кабул итүдән баш тартуына яки киткән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять биргән очракта яки мондый төзәтүләрне башкаруның кабул ителгән вакыты бозылуга шикаять биргән очракта – аны теркәгән көннән соң 5 эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исемен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки муниципаль хезмәткәрнең исемен;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән риза булмавына дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә тасвирланган вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре теркәлгән булырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документлар исемлеге бирелә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәте күрсәтелүче зат, законлы вәкиле тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта Башкарма комитет тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта ачыкланган бозуларны кичекмәстән бетерү максатында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле гамәлләр турында әйтелә.

5.9. Әгәр шикаять канәгатьләндерелмәсә, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул итлегән карарга нигезләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында аңлатма бирелә.

5.10. Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Балигъ булмаган затны тулысынча эмансипацияләү (балигъ булмаган затны тулысынча эшкә яраклы дип тану) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
1 Кушымта

___________________________________________
___________________________________________
____________адресы буенча яшәүче
(тулы адрес)
________________________________________ннән
(тулысынча фамилиясе, исеме)
___________________________
Телефон:___________________________________
Паспорт:___________________________________
(серия,номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

ГАРИЗА

Мин,______________________________________________________________,
Фамилия, исем, әтисенең исеме, туу датасы

түбәндәге нигезләр буенча мине эмансипацияләвегезне сорыйм________
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
______________________________________________________________________

Мин ______________________________________________________
опека һәм попечительлек секторы тарафыннан минем шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә ризалыгымны бирәм.

«____» ______________ 20___ ел ________________
(имза)

Балигъ булмаган затны тулысынча эмансипацияләү (балигъ булмаган затны тулысынча эшкә яраклы дип тану) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
2 Кушымта

______________________________________________
______________________________________________
_____________адресы буенча яшәүче
(тулы адрес)
_____________________________________________ннән
(тулысынча фамилиясе, исеме)
_____________________________
Телефон:______________________________________
Паспорт:______________________________________
(серия,номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

ГАРИЗА

Мин,__________________________________________________________________,
законлы вәкиленең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме
минем балигъ булмаган улымны (кызымны) _______________________________________________

______________________________________________________________________________
балигъ булмаган затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туу датасы
эмансипацияләнгән дип тану белән риза

Мин, ___________________________________________________________
опека һәм попечительлек секторы тарафыннан минем шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә ризалыгымны бирәм.

«____» _______________ 20___ ел _________________
(имза)

Балигъ булмаган затны тулысынча эмансипацияләү (балигъ булмаган затны тулысынча эшкә яраклы дип тану) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
3 Кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне агымдагы контрольдә тотучы җаваплы вазыйфаи затларның**
**РЕКВИЗИТЛАРЫ**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**


| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |
| Сектор белгече | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-84366) 3-00-44 | Ispolkom.Arsk@tatar.ru |

Балигъ булмаган затны тулысынча эмансипацияләү (балигъ булмаган затны тулысынча эшкә яраклы дип тану) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
4 Кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы**



Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының
«__»_________, 2019 ел, №_____
Карарына
1 Кушымта

**Балигъ булмаган затныкы булган күчемсез милекне алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү**
**Административ регламенты**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге регламент балигъ булмаган затныкы булган күчемсез милекне алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандарты һәм тәртипләрен билгели.

1.2. Хезмәтне алучылар: законлы вәкилләре ризалыгы белән эш итүче ундүрт яше тулган балигъ булмаган Россия Федерациясе гражданнары яки балигъ булмаганнарның күчемсез милкен алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт алырга теләүче ундүрт яше тулмаган балигъ булмаган гражданнарның законлы вәкилләре (алга таба – гариза бирүчеләр).

1.3. Дәүләт хезмәте ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен башкаручы – балигъ булмаган затның яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (алга таба – опека һәм попечительлек органы).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

1.3.2. Опека һәм попечительлек органы урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

Эш режимы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш.

Төшке аш вакыты – 12.00 – 13.00.

Эчкә үтү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне аныклаучы документ буенча.

1.3.3. Опека һәм попечительлек органы телефоны: (84366)3–13–81.

1.3.4. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайты (алга таба – «Интернет» челтәре): http://www.arsk.tatarstan.ru.

1.3.5. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы бинасында урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аркылы;

2) «Интернет» челтәре аша:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында http://www.arsk.tatarstan.ru;

3) опека һәм попечительлек секторына шәхси мөрәҗәгать итеп;

4) күпфункцияле үзәктә (хезмәт күрсәтүне күпфункцияле үзәк аркылы алып булган очракта).

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә башкарыла:

- Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы (1 бүлек) 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гражданлык кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 05.12.1994, №32, 3301 маддә);

- Россия Федерациясе Гаилә кодексы 1995 елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гаилә кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 01.01.1996, №1 16 маддә;

- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 01 гыйнварындагы 48-ФЗ номерлы Федераль законы (алга таба – 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 28.04.2008, №17, 1755 маддә);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №43–44, 02.03.2004);

- Татарстан Республикасы Гаилә кодексы 2009 елның 13 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы (алга таба – ТР Гаилә кодексы) (Республика Татарстан, 16.01.2009, №8);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №60-61, 25.03.2008);

- «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 нче номерлы Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинеты Карары (алга таба – 880 нче номерлы ТР Министрлар кабинеты карары) (Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карарлары һәм республика башкарма комитет органнары норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, 2144 маддә; 20.12.2011);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 15 августындагы боерыгы белән расланган Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында Нигезләмәсе (алга таба – опека секторы турнда Нигезләмә).

1.5.Әлеге Регламентта түбәндәге термин һәм билгеләмәләр кулланыла:

- административ регламент –Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралар һәм административ эшчәнлек вакытын һәм эзлеклелеген, структур бүлекчәләр һәм вазыйфаи затлар арасындагы хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хакимияте башкарма органнарының физик яки юридик затлар (алга таба – дәүләт хезмәте алучылар), башка дәүләт хезмәте һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгеләүче норматив хокукый документ;

- дәүләт хезмәте – дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән чикләрдә мөрәҗәгать итүче соравы буенча башкарыла торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарган вакытта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек;

- дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе $1^1$ бүлегендә каралган оешмалар яки аларның эшчеләре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта бозылган хокукларны яки законлы мәнфәгатьләрне кире кайтару яки саклау турында таләбе.

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яки муниципаль учреждениенең  оештыру-хокукый формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирүче һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча, вәкаләтле оешма;

- «бер тәрәзә» принцибы – мөрәҗәгать итүче 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ маддәсендә күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү, ә дәүләт хезмәт күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар белән күпфункцияле үзәк тарафыннан мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актлар һәм хезмәттәшлек итү турында килешү нигезендә хезмәттәшлек алып бару принцибы.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбе исеме | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте исеме | Балигъ булмаганнарның күчемсез милкен алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү | РФ Гражданлык кодексы;<br>РФ Гаилә кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль законның 21 маддәсе;<br>8-ТРЗ номерлы ТР Законы |
| 2.2. Хезмәт күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (балигъ булмаган затның яшәү урыны буенча) | 8-ТРЗ номерлы ТР Законы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль законның 21 маддәсе |
| 2.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Балигъ булмаганнарның күчемсез милкен алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү, рөхсәт бирү документы формасында<br>Хат формасында дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту | РФ Гаилә кодексының 60 маддәсе;<br>РФ Гражданлык кодексының 37 маддәсе;<br>48-ФЗ номерлы Федераль законның 21 маддәсе |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты | Гражданнарның дәүләт хезмәте күрсәтүгә кагылышлы язма мөрәҗәгатьләрен карау аларны теркәгәннән соң 15 көн эчендә башкарыла | 48-ФЗ номерлы Федераль законның 21 маддәсе;<br>РФ Гражданлык кодексының 37 маддәсе |
| 2.5. Закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәте өчен кирәк һәм мәҗбүри булган документларның тулы исемлеге | 1. Әти-әнисенең (яки аларны алыштыручыларның) килешү төзү турында гаризасы (1 Кушымта).<br>2. Законлы вәкиле ризалыгы белән эш итүче 14 яшьтән 18 яшькәчә булган балигъ булмаган затның гаризасы.<br>3. Гариза бирүчеләрнең паспорт күчермәсе (1 бит + теркәлү).<br>4. Баланың (балаларның) туу турында таныклыгы күчермәсе, шул исәптән, 14 яшьтән өлкәнрәк балаларның.<br>5. Сатыла торган һәм сатып алына торган күчемсез милек объектына хокук билгели торган документ күчермәсе.<br>6. Күчемсез милек объектларының икесенең дә техник паспортының күчермәсе (яки техник инвентаризация бюросы белешмәсе күчермәсе).<br>7. Сатып алына торган күчемсез милек объекты милекчеләренең гариза-ризалыгы.<br>Башка шәһәрдә яки районда фатирлар сатып алганда (алыштырганда) күчемсез милек объектын сатып алу – сату (алыштыру) буенча алдан килешү килешүен тапшырырга кирәк.<br>Социаль ипотека килешүе буенча фатир сатып алган очракта, социаль ипотека килешүе күчермәсен, катнашу беркетмәләрен һәм түләү графигын бирергә кирәк.<br>Торак йорт сатып алган вакытта техник паспорт күчермәсе һәм хуҗалык | |

| | | |
|---|---|---|
| | кенәгәсеннән өземтә бирелә.<br>Башка шәһәрдә яки районда милек хокукында шул исәптән балигъ булмаган балаларга караган фатирлар сатып алганда, тиешле шәһәрнең (районның) опека һәм попечительлек органының торакны алуга (сатуга, алмашуга) рөхсәтен бирергә кирәк.<br>Төп нөсхәләре булган очракта, документлар күчермәләре 1 нөсхәдә бирелә | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм алар бирергә хокуклы булган документларның тулы исемлеге | - сатып алына торган һәм сатыла торган күчемсез милек объектының, шулай ук балигъ булмаган затның теркәлү урыны буенча торак бинага йорт кенәгәсеннән өземтә | |
| 2.7. Норматив хокукый актлар белән каралган очракларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган һәм хезмәт күрсәтә торган башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла торган дәүләт хакимияте һәм аның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Гражданинның теркәлү урыны буенча мөрәҗәгать итмәве | |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>- тапшырылган документларның әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>- балигъ булмаган затның хокукларын кысу. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Түләүсез нигездә | |
| 2.11. Әлеге түләүне исәпләү турында мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргән вакытта һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алган вакытта чиратта көтүнең максималь вакыты | Көтеп утыруның (хезмәт күрсәтүнең) максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Аерым категория кешеләр өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты | Гариза кергән көнне | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | 1. Гариза түбәндәге адрес буенча тапшырыла:<br>Арча шәһәре, Советлар мәйданы урамы, 12 йорт, опека һәм попечительлек секторы.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү | |

| | | |
|---|---|---|
| | системасы белән җиһазланган бинада башкарыла;<br>3. Бинада гаризалар кабул итү өчен сектор белгеченең эш урыны хезмәтне тулысынча күрсәтергә мөмкинлек бирүче электрон белешмә-хокукый системалар, оргтехника белән тәэмин ителгән шәхси компьютер белән җиһазландырыла.<br>4. Документлар тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазлана һәм документлар тутыру үрнәкләре белән тәэмин ителә.<br>5. Инвалидларга хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыкларсыз керү тәэмин ителә, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм чыгу юлларына, дәүләт хезмәте күрсәтү урынына барып җитү максатында объект буйлап мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итү тәэмин ителә.<br>6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны исәпкә алып, урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Хезмәт күрсәтүнең аңлаешлылыгы күрсәткечләре:<br>бинаның җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы;<br>җитәрлек белгечләр булу, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә башкарма комитетның мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү бердәм порталында хезмәт күрсәтү тәртибе, ысуллары, вакыты турында тулы мәгълүмат булу;<br>инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт алырга комачаулаучы каршылыкларны узарга ярдәм итү.<br><br>Хезмәт күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре:<br>гариза бирүче документлар тапшырганда һәм алганда чиратлар булмау;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын саклау;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирмәү;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә игътибарсызлык күрсәтүенә шикаять бирмәү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратып алу биргән очракта һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен алган вакытта муниципаль хезмәт күрсәтә торган вазыйфаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр аралашуы күздә тотыла.<br>Хезмәттәшлек вакыты регламент белән билгеләнә. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Хезмәт электрон формада күрсәтелми | |

## 3. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкару составы, эзлеклелеге һәм вакыты, аларны башкару тәртибенә таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау:

3.1.1. Балигъ булмаган затныкы булган күчемсез милекне алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчеләргә консультация бирү;

2) гаризаны һәм документларны кабул итү (әлеге регламентның 2.5 пунктын кара);

3) балигъ булмаганнарның күчемсез милкен алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт әзерләү;

4) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

5) нигезләр булган очракта гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема әлеге Административ регламентка 3 кушымтада бирелә.

3.2. Консультация күрсәтү

Мәгълүмат һәм консультация бирү буенча процедуралар кысаларында гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибен җайлаучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;

- гариза бирүчеләрне балигъ булмаганнарның күчемсез милкен алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән таныштыра;

- балигъ булмаганнарның күчемсез милкен алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеген бирә.

Консультация гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне күрсәтелә.

Процедура нәтиҗәсе: документлар составы һәм хезмәт күрсәтү буенча башка сораулар буенча консультация.

Консультация һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедуралар башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

3.3. Гариза, документлар кабул итү.

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән үзе опека һәм попечительлек секторына, күпфункцияле үзәккә (хезмәт күпфункцияле үзәктә күрсәтелгән очракта) гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыра.

3.3.2. Кабул итү алып баручы опека һәм попечительлек секторы, күпфункцияле үзәк белгече:

- гариза бирүченең шәхесен, балигъ булмаган затның яшәү урынын билгели;

- документларның барлыгын тикшерә. Кирәкле документлар булмаган очракта җитмәгән документларны тапшырырга тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларны кабул итүне таләп итсә, документлар кабул ителә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта опека һәм попечительлек, күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелсә) белгече гариза бирүчегә гариза һәм документлар алу, теркәлү номеры турында хәбәр итә, аннан соң әлеге Регламентның 3.3.3 подпунктында күрсәтелгән процедуралар башкарыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән көннән соң 1 кңн эчендә 15 минут вакыт аралыгында башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язмасы.

3.3.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүче тапшырган документлардагы мәгълүматны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергәннән соң 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәт бирү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратып алу әзерләү һәм җибәрү.

3.4.1 Опека һәм попечительлек белгече (гариза бирүче белән килештереп) ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү системасы аркылы әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны җибәрү турында электрон формада соратып алу юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән көннән 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында юлланган соратып алу.

3.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы опека һәм попечительлек секторы органнары соратуы буенча автоматлаштырылган режимда башкарыла:

- соратып алуны эшкәртү һәм соратылган мәгълүматны эзләү;

- ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү аркылы соратып алынган мәгълүматны формалаштыру, соратып алынган мәгълүмат булмаган очракта, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, соратып алынган мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар опека һәм попечительлек органнарына соратып алу кергән вакыттан 5 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: соратып алуга җавап яки әлеге Регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.5.1. Тапшырылган документлар нигезендә опека һәм попечительлек секторы белгече балигъ булмаганнарның кучемсез милкен алу буенча килешүләр башкаруга рөхсәт бирү буенча боерык проекты әзерли һәм аны килештерү һәм раслату өчен опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә җибәрә яки тиешле аныклау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: балигъ булмаганнарның кучемсез милкен алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү турында боерык яки 3.7 пункты нигезендә әзерләнгән хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.6. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен тапшыру.

3.6.1. Опека һәм попечительлек секторы белгече, имзаланган боерыкны алгач, аны терки һәм гариза бирүчегә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.5.1 подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.7. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат тапшыру.

3.7.1 Опека һәм попечительлек секторы белгече боерык бирүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты әзерли (алга таба – баш тарту турында хат).

Әзерләнгән баш тарту турында хат проектын Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар баш тарту өчен нигезләр ачыкланган көннән соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзалауга юлланган баш тарту турында хат проекты.

3.7.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек секторы белгеченә кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзаланган баш тарту турында хат.

3.7.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече баш тарту турында хатны аны имзалаган көннән соң 1 көн эчендә гариза бирүчегә юллый. Шул ук вакытта гариза бирүчегә карарны шикаять итү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.7.2. подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формасы

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларын үтәүне тикшерүне, карар кабул итүне һәм күпфункцияле үзәкнең (хезмәт күпфункцияле үзәк аркылы күрсәтелсә), опека һәм попечительлек бүлегенең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап бирүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларының хокукый экспертизасын үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау;
- кабул итлегән тәртиптә делопроизводство алып баруны тикшерү;
- кабул ителгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү үткәрү процедураларына контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерү үткәргән вакытта дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык сораулар каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта һәм карар кабул иткән вакытта гамәлләрне башкаруны тикшерүне башкару максатында күпфункцияле үзәк, опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затлар исемлеге күпфункцияле үзәкнең, опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы гариза бирүченең мөрәҗәгатен вакытында карамаган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезләнмәгән рәвештә баш тарткан өчен җавап бирә.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, аларның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелгән очракта), опека һәм попечительлек секторы хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Арча муниципаль районы башкарма комитетына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итәргә мөкин:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган документлар, мәгълүмат яки гамәл кылу таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү вакыты яки тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылганда, әгәр туктатылу нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта мөрәҗәгать итүчедән беренче тапкыр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документлар тапшырган вакытта булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү.

5.2. Шикаять почта аркылы язма рәвештә кәгазь битендә яки электрон формада җибәрелергә, шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәткән очракта шикаять күпфункцияле үзәк аркылы җибәрелә ала.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең документларны кабул итүдән баш тартуына яки киткән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять биргән очракта яки мондый төзәтүләрне башкаруның кабул ителгән вакыты бозылуга шикаять биргән очракта – аны теркәгән көннән соң 5 эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исемен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки муниципаль хезмәткәрнең исемен;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән риза булмавына дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә тасвирланган вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре теркәлгән булырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документлар исемлеге бирелә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәте күрсәтелүче зат тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта Башкарма комитет тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта ачыкланган бозуларны кичекмәстән бетерү максатында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле гамәлләр турында әйтелә.

5.9. Әгәр шикаять канәгатьләндерелмәсә, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул итлегән карарга нигезләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында аңлатма бирелә.

5.10. Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Балигъ булмаган затныкы булган күчемсез милекне алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
1 Кушымта

______________________________________________
_____________________________адресы буенча яшәүче

___________________________________________ннән
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
_____________________________
Паспорт:______________________________________

Телефон:______________________________________

ГАРИЗА

Миңа ____________________________________________________________адресы буенча урнашкан, гомуми мәйданы ______ кв.м, торак мәйданы ________ кв.м, бүлмәләр саны ______ булган (приватизацияләнгән, милкекә сатып алынган, кооператив, дәүләтнеке булган)_____________________________________________________ фатирны, торак йортны алуга (сату-алу, сату, алыштыру) ____________________________________________ рөхсәт бирүегезне сорыйм.

Фатир милекчеләре (фамилияләре, исемнәре, әтиләренең исемнәре, өлешләрен күрсәтергә)_________________________________________________________________________________

Шул исәптән балигъ булмаган бала (балалар) (фамилияләре, исемнәре, әтиләренең исемнәре, өлешләрен күрсәтергә)_________________________________________________________________________.
________________________________________ (торак шартларын яхшырту, күчеп китү һ.б.) белән бәйле рәвештә ______________________________________________________________ адресы буенча урнашкан, __________________________(гомуми мәйданы)__________(торак мәйданы)___________(бүлмәләр саны)__________ булган ______________________(фатир, җир участогында урнашкан торак йорт) сатып алабыз, анда балигъ булмаган затка (затларга) __________ өлеш бүлеп бирелә.

Өстәмә мәгълүмат (кредит алу, сатып алына торган фатирны залогка бирү һәм башка чикләүләр, ана (гаилә) капиталына дәүләт сертификаты куллану)____________________________________________.

Балаларның милек һәм башка хокуклары кысылмый.

Рента килешүен ТР буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсендә теркәгәннән соң ике атна эчендә опека һәм попечительлек бүлегенә сату-алу килешүе һәм хокукны дәүләт теркәве таныклыгы күчермәләрен тапшырырга үземә йөкләмә алам.

Минем шәхси мәгълүматлар белән эшләргә рөхсәт бирәм.

___________________ ____________________
(дата) (имза)

Мин, ____________________________________________________________________________
(14 яшьтән өлкәнрәк балигъ булмаган затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
законлы вәкилләрнең гаризасы белән риза

___________________ ____________________
(дата) (имза)

Балигъ булмаган затныкы булган күчемсез
милекне алу буенча килешүләр башкаруга
алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтү
Административ регламентына
Кушымта (мәгълүмати)

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне агымдагы контрольдә тотучы җаваплы вазыйфаи затларның**
**РЕКВИЗИТЛАРЫ**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**


| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |
| Сектор белгече | (8-884366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-84366) 3-00-44 | Ispolkom.Arsk@tatar.ru |

Балигъ булмаган затныкы булган күчемсез
милекне алу буенча килешүләр башкаруга
алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтү
Административ регламентына
3 Кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы**



Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының
«__»_________, 2019 ел, №_____
Карарына
18 Кушымта

**Балигъ булмаган затлар катнашында, кредит акчалары кулланып, торак сатып алуга һәм аны залогка (ипотекага) бирүгә алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү**
**Административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге регламент балигъ булмаган затлар катнашында, кредит акчалары кулланып, торак сатып алуга һәм аны залогка (ипотекага) бирүгә алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандарты һәм тәртипләрен билгели.

1.2. Хезмәтне алучылар: балигъ булмаган затлар катнашында, кредит акчалары кулланып, торак сатып алуга һәм аны залогка (ипотекага) бирүгә алдан рөхсәт алырга теләүче ундүрт яше тулган балигъ булмаган Россия Федерациясе гражданнары яки ундүрт яше тулмаган балигъ булмаган гражданнарның законлы вәкилләре (алга таба – гариза бирүчеләр).

1.3. Дәүләт хезмәте ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен башкаручы – балигъ булмаган затның яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (алга таба – опека һәм попечительлек органы).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

1.3.2. Опека һәм попечительлек органы урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

Эш режимы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш.

Төшке аш вакыты – 12.00 – 13.00.

Эчкә үтү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне аныклаучы документ буенча.

1.3.3. Опека һәм попечительлек органы телефоны: (84366)3–13–81.

1.3.4. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайты (алга таба – «Интернет» челтәре): http://www.arsk.tatarstan.ru.

1.3.5. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы бинасында урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аркылы;

2) «Интернет» челтәре аша:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында http://www.arsk.tatarstan.ru;

3) опека һәм попечительлек секторына шәхси мөрәҗәгать итеп;

4) күпфункцияле үзәктә (хезмәт күрсәтүне күпфункцияле үзәк аркылы алып булган очракта).

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә башкарыла:

- Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы (1 бүлек) 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гражданлык кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 05.12.1994, №32, 3301 маддә);

- Россия Федерациясе Гаилә кодексы 1995 елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гаилә кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 01.01.1996, №1 16 маддә;

- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 01 гыйнварындагы 48-ФЗ номерлы Федераль законы (алга таба – 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 28.04.2008, №17, 1755 маддә);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №43–44, 02.03.2004);

- Татарстан Республикасы Гаилә кодексы 2009 елның 13 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы (алга таба – ТР Гаилә кодексы) (Республика Татарстан, 16.01.2009, №8);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №60-61, 25.03.2008);

- «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым

карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары (алга таба – 880 нче номерлы ТР Министрлар кабинеты карары) (Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карарлары һәм республика башкарма комитет органнары норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, 2144 маддә; 20.12.2011);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 15 августындагы боерыгы белән расланган Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында Нигезләмәсе (алга таба – опека секторы турнда Нигезләмә).

1.5.Әлеге Регламентта түбәндәге термин һәм билгеләмәләр кулланыла:

- административ регламент –Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралар һәм административ эшчәнлек вакытын һәм эзлеклелеген, структур бүлекчәләр һәм вазыйфаи затлар арасындагы хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хакимияте башкарма органнарының физик яки юридик затлар (алга таба – дәүләт хезмәте алучылар), башка дәүләт хезмәте һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгеләүче норматив хокукый документ;

- дәүләт хезмәте – дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән чикләрдә мөрәҗәгать итүче соравы буенча башкарыла торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарган вакытта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек;

- дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе $1^1$ бүлегендә каралган оешмалар яки аларның эшчеләре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта бозылган хокукларны яки законлы мәнфәгатьләрне кире кайтару яки саклау турында таләбе.

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яки муниципаль учреждениенең оештыру-хокукый формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирүче һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча, вәкаләтле оешма;

- «бер тәрәзә» принцибы – мөрәҗәгать итүче 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ маддәсендә күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү, ә дәүләт хезмәт күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар белән күпфункцияле үзәк тарафыннан мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актлар һәм хезмәттәшлек итү турында килешү нигезендә хезмәттәшлек алып бару принцибы.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбе исеме | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте исеме | балигъ булмаган затлар катнашында, кредит акчалары кулланып, торак сатып алуга һәм аны залогка (ипотекага) бирүгә алдан рөхсәт бирү | РФ Гражданлык кодексы;<br>РФ Гаилә кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль законы- |
| 2.2. Хезмәт күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (балигъ булмаган затның яшәү урыны буенча) | 8-ТРЗ номерлы ТР Законы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Балигъ булмаганнарның күчемсез милкен алу буенча килешүләр башкаруга алдан рөхсәт бирү, рөхсәт бирү документы формасында<br>Хат формасында дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту | РФ Гаилә кодексы;<br>РФ Гражданлык кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты | Гражданнарның дәүләт хезмәте күрсәтүгә кагылышлы язма мөрәҗәгатьләрен карау аларны теркәгәннән соң 15 көн эчендә башкарыла | 48-ФЗ номерлы Федераль;<br>РФ Гражданлык кодексы |
| 2.5. Закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәте өчен кирәк һәм мәҗбүри булган документларның тулы исемлеге | 1. Әти-әнисенең (яки аларны алыштыручыларның) гаризасы (1 Кушымта).<br>2. Законлы вәкиле ризалыгы белән эш итүче 14 яшьтән 18 яшькәчә булган балигъ булмаган затның гаризасы.<br>3. Банктан опека һәм попечительлек органы җитәкчесе исеменә ипотека кредиты бирү турында хат;<br>4. Гариза бирүчеләрнең паспорт күчермәсе (1 бит + яшәү урыны буенча теркәлү).<br>5. Баланың (балаларның) туу турында таныклыгы күчермәсе, шул исәптән, 14 яшьтән өлкәнрәк балаларның.<br>6. Сатучыларның сатуга гариза-ризалыгы.<br>7. Сатып алына торган фатирга хокук билгеләүче документлар күчермәсе (приватизацияләү килешүе, сату-алу килешүе һ.б.).<br>8. Сатып алына торган фатиның техник паспорты күчермәсе (яки техник инвентаризация бюросы белешмәсе күчермәсе).<br>9. Ана капиталы сертификаты (ана капиталы кулланган очракта).<br>Башка шәһәрдә яки районда фатирлар сатып алганда (алыштырганда) күчемсез милек объектын сатып алу – сату (алыштыру) буенча алдан килешү килешүен тапшырырга кирәк.<br>Төп нөсхәләре булган очракта, документлар күчермәләре 1 нөсхәдә бирелә | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм алар бирергә хокуклы булган документларның тулы исемлеге | - балигъ булмаган затның теркәлү урыны буенча йорт кенәгәсеннән өземтә (төп нөсхә);<br>- сатып алына торган фатирның йорт кенәгәсеннән өземтә (төп нөсхә). | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.7. Норматив хокукый актлар белән каралган очракларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган һәм хезмәт күрсәтә торган башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла торган дәүләт хакимияте һәм аның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Балигъ булмаган затның теркәлү урыны буенча мөрәҗәгать итмәве | |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>- тапшырылган документларның әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>- балигъ булмаган затның хокукларын кысу. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Түләүсез нигездә | |
| 2.11. Әлеге түләүне исәпләү турында мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргән вакытта һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алган вакытта чиратта көтүнең максималь вакыты | Көтеп утыруның (хезмәт күрсәтүнең) максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Аерым категория кешеләр өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты | Гариза кергән көнне | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | 1. Гариза түбәндәге адрес буенча тапшырыла:<br>Арча шәһәре, Советлар мәйданы урамы, 12 йорт, опека һәм попечительлек секторы.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазланган бинада башкарыла;<br>3. Бинада гаризалар кабул итү өчен сектор белгеченең эш урыны хезмәтне тулысынча күрсәтергә мөмкинлек бирүче электрон белешмә-хокукый системалар, оргтехника белән тәэмин ителгән шәхси компьютер белән җиһазландырыла.<br>4. Документлар тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазлана һәм документлар тутыру үрнәкләре белән тәэмин ителә.<br>5. Инвалидларга хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыкларсыз керү тәэмин ителә, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм чыгу юлларына, дәүләт хезмәте күрсәтү урынына барып җитү максатында объект буйлап мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итү тәэмин ителә. | |

| | | |
|---|---|---|
| | 6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны исәпкә алып, урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Хезмәт күрсәтүнең аңлаешлылыгы күрсәткечләре:<br>бинаның җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы;<br>җитәрлек белгечләр булу, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә башкарма комитетның мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү бердәм порталында хезмәт күрсәтү тәртибе, ысуллары, вакыты турында тулы мәгълүмат булу;<br>инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт алырга комачаулаучы каршылыкларны узарга ярдәм итү.<br><br>Хезмәт күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре:<br>гариза бирүче документлар тапшырганда һәм алганда чиратлар булмау;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын саклау;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирмәү;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә игътибарсызлык күрсәтүенә шикаять бирмәү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратып алу биргән очракта һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен алган вакытта муниципаль хезмәт күрсәтә торган вазыйфаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр аралашуы күздә тотыла.<br>Хезмәттәшлек вакыты регламент белән билгеләнә. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Хезмәт электрон формада күрсәтелми | |

## 3. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкару составы, эзлеклелеге һәм вакыты, аларны башкару тәртибенә таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау:

3.1.1. Балигъ булмаган затлар катнашында, кредит акчалары кулланып, торак сатып алуга һәм аны залогка (ипотекага) бирүгә алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчеләргә консультация бирү;

2) гаризаны һәм документларны кабул итү (әлеге регламентның 2.5 пунктын кара);

3) балигъ булмаган затлар катнашында, кредит акчалары кулланып, торак сатып алуга һәм аны залогка (ипотекага) бирүгә алдан рөхсәт бирү;

4) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

5) нигезләр булган очракта гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема әлеге Административ регламентка 3 кушымтада бирелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация күрсәтү.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе буенча консультация алу өчен гариза бирүче шәхсән опека һәм попечительлек секторына мөрәҗәгать итә.

Консультация гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне күрсәтелә.

Процедура нәтиҗәсе: документлар составы һәм хезмәт күрсәтү буенча башка сораулар буенча консультация.

3.3. Гариза, документлар кабул итү.

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән үзе опека һәм попечительлек секторына, күпфункцияле үзәккә (хезмәт күпфункцияле үзәктә күрсәтелгән очракта) гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыра.

3.3.2. Кабул итү алып баручы опека һәм попечительлек секторы, күпфункцияле үзәк белгече:

- гариза бирүченең шәхесен, балигъ булмаган затның яшәү урынын билгели;

- документларның барлыгын тикшерә. Кирәкле документлар булмаган очракта җитмәгән документларны тапшырырга тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларны кабул итүне таләп итсә, документлар кабул ителә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта опека һәм попечительлек, күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелсә) белгече гариза бирүчегә гариза һәм документлар алу, теркәлү номеры турында хәбәр итә, аннан соң әлеге Регламентның 3.3.3 подпунктында күрсәтелгән процедуралар башкарыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән көннән соң 1 кңн эчендә 15 минут вакыт аралыгында башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язмасы.

3.3.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүче тапшырган документлардагы мәгълүматны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергәннән соң 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәт бирү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратып алу әзерләү һәм җибәрү.

3.4.1 Опека һәм попечительлек белгече (гариза бирүче белән килештереп) ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү системасы аркылы әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны җибәрү турында электрон формада соратып алу юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән көннән 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында юлланган соратып алу.

3.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы опека һәм попечительлек секторы органнары соратуы буенча автоматлаштырылган режимда башкарыла:

- соратып алуны эшкәртү һәм соратылган мәгълүматны эзләү;

- ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү аркылы соратып алынган мәгълүматны формалаштыру, соратып алынган мәгълүмат булмаган очракта, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, соратып алынган мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар опека һәм попечительлек органнарына соратып алу кергән вакыттан 5 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: соратып алуга җавап яки әлеге Регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.5.1. Тапшырылган документлар нигезендә опека һәм попечительлек секторы белгече балигъ булмаган затлар катнашында торакны залогка яңадана рәсмиләштерүгә (рефинанслау) рөхсәт бирү буенча боерык проекты әзерли һәм аны килештерү һәм раслату өчен опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә җибәрә яки тиешле аныклау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: балигъ булмаган затлар катнашында, кредит акчалары кулланып, торак сатып алуга һәм аны залогка (ипотекага) бирүгә рөхсәт бирү турында боерык яки 3.7 пункты нигезендә әзерләнгән хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.6. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен тапшыру.

3.6.1. Опека һәм попечительлек секторы белгече, имзаланган боерыкны алгач, аны терки һәм гариза бирүчегә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.5.1 подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.7. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат тапшыру.

3.7.1 Опека һәм попечительлек секторы белгече боерык бирүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты әзерли (алга таба – баш тарту турында хат).

Әзерләнгән баш тарту турында хат проектын Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзалауга юлланган баш тарту турында хат проекты.

3.7.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек секторы белгеченә кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзаланган баш тарту турында хат.

3.7.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече баш тарту турында хатны аны имзалаган көннән соң 1 көн эчендә гариза бирүчегә юллый. Шул ук вакытта гариза бирүчегә карарны шикаять итү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.7.2. подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

### 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формасы

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларын үтәүне тикшерүне, карар кабул итүне һәм күпфункцияле үзәкнең (хезмәт күпфункцияле үзәк аркылы күрсәтелсә), опека һәм попечительлек бүлегенең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап бирүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларының хокукый экспертизасын үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау;

- кабул итлегән тәртиптә делопроизводство алып баруны тикшерү;

- кабул ителгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү үткәрү процедураларына контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерү үткәргән вакытта дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык сораулар каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта һәм карар кабул иткән вакытта гамәлләрне башкаруны тикшерүне башкару максатында күпфункцияле үзәк, опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затлар исемлеге күпфункцияле үзәкнең, опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы гариза бирүченең мөрәҗәгатен вакытында карамаган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезләнмәгән рәвештә баш тарткан өчен җавап бирә.

### 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, аларның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелгән очракта), опека һәм попечительлек секторы хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Арча муниципаль районы башкарма комитетына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итәргә мөкин:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган документлар, мәгълүмат яки гамәл кылу таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү вакыты яки тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылганда, әгәр туктатылу нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта мөрәҗәгать итүчедән беренче тапкыр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документлар тапшырган вакытта булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү.

5.2. Шикаять почта аркылы язма рәвештә кәгазь битендә яки электрон формада җибәрелергә, шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәткән очракта шикаять күпфункцияле үзәк аркылы җибәрелә ала.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең документларны кабул итүдән баш тартуына яки киткән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять биргән очракта яки мондый төзәтүләрне башкаруның кабул ителгән вакыты бозылуга шикаять биргән очракта – аны теркәгән көннән соң 5 эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исемен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки муниципаль хезмәткәрнең исемен;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән риза булмавына дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә тасвирланган вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре теркәлгән булырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документлар исемлеге бирелә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәте күрсәтелүче зат тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта Башкарма комитет тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта ачыкланган бозуларны кичекмәстән бетерү максатында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле гамәлләр турында әйтелә.

5.9. Әгәр шикаять канәгатьләндерелмәсә, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул итлегән карарга нигезләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында аңлатма бирелә.

5.10. Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Балигъ булмаган затлар катнашында, кредит акчалары кулланып, торак сатып алуга һәм аны залогка (ипотекага) бирүгә алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
1 Кушымта

________________________________ адресы буенча яшәүче

____________________________________________________ннән
(тулысынча фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

Паспорт ______________________________________________
______________________________________________________

Телефон: _________________________________

ГАРИЗА

Миңа __________________________________________________________________________ адресы буенча урнашкан, гомуми мәйданы _________________ кв.м, бүлмәләр саны ________________________ булган фатирны кредит акчалары кулланып _________________________________________________________________ төзелгән килешү буенча алынган, һәм балигъ булмаган затка

_______________________________________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

____________________ өлеш бирелә торган фатирны милеккә алырга сатып алына торган торакны залогка (ипотекага) бирергә рөхсәт бирүегезне сорыйм..

Өстәмә мәгълүмат: ____________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________.

Минем шәхси мәгълүматларым белән эшләүгә рөхсәт бирүегезне сорыйм.

____________________________ ________________________
(дата) (имза)

Балигъ булмаган затлар катнашында, кредит акчалары кулланып, торак сатып алуга һәм аны залогка (ипотекага) бирүгә алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
2 Кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне агымдагы контрольдә тотучы җаваплы вазыйфаи затларның**
**РЕКВИЗИТЛАРЫ**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**


| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Заведующий Сектором | (8-84366 ) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |
| Специалист Сектора | (8-84366 ) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-84366) 3-00-44 | Ispolkom.Arsk@tatar.ru |

Балигъ булмаган затлар катнашында, кредит акчалары кулланып, торак сатып алуга һәм аны залогка (ипотекага) бирүгә алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
3 Кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы**



Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының
«__»_________, 2019 ел, №_____
Карарына
19 Кушымта

**Законлы вәкиленә балигъ булмаган затның акча кертемен алуга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламенты**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге регламент законлы вәкиленә балигъ булмаган затның акча кертемен алуга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – хезмәт күрсәтү) стандарты һәм тәртипләрен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар: балигъ булмаган затның акча кертемен алуга рөхсәт алырга теләүче Россия Федерациясе гражданнары.

1.3. Дәүләт хезмәте ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен башкаручы – опекага алынган затның яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (алга таба – опека һәм попечительлек органы).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

1.3.2. Опека һәм попечительлек органы урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

Эш режимы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш.

Төшке аш вакыты – 12.00 – 13.00.

Эчкә үтү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне аныклаучы документ буенча.

1.3.3. Опека һәм попечительлек органы телефоны: (84366)3–13–81.

1.3.4. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайты (алга таба – «Интернет» челтәре): http://www.arsk.tatarstan.ru.

1.3.5. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы бинасында урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аркылы;

2) «Интернет» челтәре аша:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында http://www.arsk.tatarstan.ru;

3) опека һәм попечительлек секторына шәхси мөрәҗәгать итеп;

4) күпфункцияле үзәктә (хезмәт күрсәтүне күпфункцияле үзәк аркылы алып булган очракта).

1.4. Хезмәт күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә башкарыла:

- Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы (беренче бүлеге) 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гражданлык кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 05.12.1994, №32, 3301 маддә);

- Россия Федерациясе Гражданлык процессуальлек кодексы 2002 елның 14 ноябрендәге 138-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гражданлык процессуальлек кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 18.11.2002, №46, 4532 маддә);

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр  күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 маддә);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №43-44, 02.03.2004);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №60-61, 25.03.2008);

- «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 880 нче номерлы Карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары җыелмасы, 08.12.2010, №46, 2144 маддә, 20.12.2011);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 15 августындагы боерыгы белән расланган Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында Нигезләмәсе (алга таба – опека секторы турнда Нигезләмә).

1.5.Әлеге Регламентта түбәндәге термин һәм билгеләмәләр кулланыла:

- административ регламент –Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралар һәм административ эшчәнлек вакытын һәм эзлеклелеген, структур бүлекчәләр һәм вазыйфаи затлар арасындагы хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хакимияте башкарма органнарының физик яки юридик затлар (алга таба – дәүләт хезмәте алучылар), башка дәүләт хезмәте һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгеләүче норматив хокукый документ;

- дәүләт хезмәте – дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән чикләрдә мөрәҗәгать итүче соравы буенча башкарыла торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарган вакытта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек;

- дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе $1^1$ бүлегендә каралган оешмалар яки аларның эшчеләре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта бозылган хокукларны яки законлы мәнфәгатьләрне кире кайтару яки саклау турында таләбе.

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яки муниципаль учреждениенең  оештыру-хокукый формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирүче һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча, вәкаләтле оешма;

- «бер тәрәзә» принцибы – мөрәҗәгать итүче 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ маддәсендә күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү, ә дәүләт хезмәт күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар белән күпфункцияле үзәк тарафыннан мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актлар һәм хезмәттәшлек итү турында килешү нигезендә хезмәттәшлек алып бару принцибы.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбе исеме | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Хезмәт күрсәтү исеме | Законлы вәкиленә балигъ булмаган затның акча кертемен алуга рөхсәт бирү | РФ Гражданлык кодексының 28 маддәсе;<br>РФ Гражданлык кодексының 37 маддәсе;<br>РФ Гаилә кодексының 60 маддәсе |
| 2.2. Хезмәт күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (гариза бирүченең яшәү урыны буенча) | 8-ТРЗ номерлы ТР Законының 5 маддәсе |
| 2.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Законлы вәкиленә, тәрбиягә алган әти-әнисенә, опекага алучыга (попечительгә) балигъ булмаган затның акча кертемен алуга банкка (финанс учреждениесенә) хат язу формасында рөхсәт бирү рөхсәт бирү яки баш тарту турында хат язу | РФ Гражданлык кодексының 28 маддәсе;<br>РФ Гражданлык кодексының 37 маддәсе;<br>РФ Гаилә кодексының 60 маддәсе |
| 2.4. Хезмәт күрсәтү вакыты | Гражданнарның дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле гаризалары аларны теркәгәннән соң 15 көн эчендә башкарыла. | |
| 2.5. Закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә хезмәт күрсәтү, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларның тулы исемлеге | 1. Әти-әнисенең берсенең яки аларны алыштыручы затларның акча кертемен алуга рөхсәт бирү турында гаризасы.<br>2. Әти-әнисенең берсенең паспорт күчермәсе.<br>3. Балигъ булмаган затның туу турында таныклык күчермәсе.<br>4. Опека билгеләү (опекга алучылар (попечительләр), тәрбиягә алучы әти-әниләр өчен) билгеләү турында хокукый акт күчермәсе.<br>6. Балигъ булмаган затның акча кертеме булуын раслаучы документ (саклык кенәгәсе, мираска хокук турында таныклык һ.б.) күчермәсе.<br>6. Бала мәнфәгатьләрендә акча кертемен алуның максатчанлыгын раслаучы документлар (уку учреждениесеннән коммерцияле формада уку турында белешмә, дәвалау учреждениесеннән түләүле дәвалау кирәклеге турында белешмә һ.б.) | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге | Әлеге категориягә кертергә мөмкин булган документлар тапшыру таләп ителми | |
| 2.7. Норматив хокукый актлар белән каралган очракларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган һәм дәүләт хезмәте күрсәтә торган башкарма хакимият органы тарафыннан | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| башкарыла торган дәүләт хакимияте һәм аның структур бүлекчәләре исемлеге | | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Балигъ булмаган затның тору урыны буенча мөрәҗәгать итмәве | |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>- тапшырылган документларның әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>- балигъ булмаган затның милек хокукларын кысу | |
| 2.10. Хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә. | |
| 2.11. Әлеге түләүне исәпләү турында мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргән вакытта һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен алган вакытта чиратта көтүнең максималь вакыты | Көтеп утыруның (хезмәт күрсәтүнең) максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Аерым категория кешеләр өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты | Гариза кергән көнне | |
| 2.14. Хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр | 1. Гариза түбәндәге адрес буенча тапшырыла:<br>Арча шәһәре, Советлар мәйданы урамы, 12 йорт, опека һәм попечительлек секторы.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазланган бинада башкарыла;<br>3. Бинада гаризалар кабул итү өчен сектор белгеченең эш урыны хезмәтне тулысынча күрсәтергә мөмкинлек бирүче электрон белешмә-хокукый системалар, оргтехника белән тәэмин ителгән шәхси компьютер белән җиһазландырыла.<br>4. Документлар тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазлана һәм документлар тутыру үрнәкләре белән тәэмин ителә.<br>5. Инвалидларга хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыкларсыз керү тәэмин ителә, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм чыгу юлларына, дәүләт хезмәте күрсәтү урынына барып җитү максатында объект буйлап мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итү тәэмин ителә.<br>6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны исәпкә алып, урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлеге һәм | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең аңлаешлылыгы күрсәткечләре: | |

| | | |
|---|---|---|
| сыйфаты күрсәткечләре | - бинаның җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы;<br>- җитәрлек белгечләр һәм гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү өчен биналар булуы;<br>- мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә башкарма комитетның мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталында хезмәт күрсәтү тәртибе, ысуллары, вакыты турында тулы мәгълүмат булу;<br>- инвалидларга башкалар белән беррәттән хезмәт алуга комачаулаучы каршылыкларны узарга ярдәм күрсәтү.<br>Хезмәт күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре:<br>- хезмәт күрсәтү вакытын бозмау;<br>- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять булмау;<br>- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә игътибарсызлык күрсәтүенә шикаять булмау.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратып алу биргән очракта һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен алган вакытта муниципаль хезмәт күрсәтә торган вазыйфаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр аралашуы күздә тотыла.<br>Хезмәттәшлек вакыты регламент белән билгеләнә. | |
| 2.16. Хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Хезмәт электрон формада күрсәтелми | |

**3. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкару составы, эзлеклелеге һәм вакыты, аларны башкару тәртибенә таләпләр**

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау:

3.1.1. Законлы вәкиленә балигъ булмаган затның акча кертемен алуга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) консультация бирү;

2) гаризаны һәм документларны кабул итү (әлеге регламентның 2.5 пунктын кара);

3) тапшырылган документларны карау;

4) законлы вәкилгә балигъ булмаган затның акча кертемен алуга рөхсәт яки нигезләр булган очракта баш тарту турында хат әзерләү;

5) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру;

6) нигезләр булган очракта гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат тапшыру.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема әлеге Административ регламентка 3 Кушымтада бирелә.

3.2. Консультация бирү

Мәгълүмат һәм консультация бирү буенча процедуралар кысаларында гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибен җайлаучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;

- опекага алынган затның законлы вәкилен балигъ булмаган затның акча кертемен алуга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән таныштыра;

- балигъ булмаган затның акча кертемен алуга рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеген бирә.

Консультация гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Процедура нәтиҗәсе: документлар составы һәм хезмәт күрсәтү буенча башка сораулар буенча консультация.

Консультация һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедуралар башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

3.3. Гариза бирүче, 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән үзе гариза тапшыра.

Гаризалар һәм документлар кабул итү өчен җаваплы опека һәм попечительлек секторы белгече:

- гражданинның шәхесен, опекага алынган кешенең тору урынын билгели;

- опекага алучы (попечитель) тапшырган кирәкле документларның барлыгын тикшерә. Кирәкле документлар булмаган очракта җитмәгән документларны тапшырырга тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларны кабул итүне таләп итсә, документлар кабул ителә.

- документлар пакеты формалаштыра.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән документлар.

Гамәлләрне башкаруның гомуми вакыты – 15 минут.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта опека һәм попечительлек, күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелсә) белгече гариза бирүчегә гариза һәм документлар алу, теркәлү номеры турында хәбәр итә, аннан соң әлеге Регламентның 3.4. подпунктында күрсәтелгән процедуралар башкарыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән вакыттан соң 1 көн эчендә 15 минут вакыт аралыгында башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язмасы.

3.4 Опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүче тапшырган документлардагы мәгълүматны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергәннән соң 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәт бирү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.5.1. Тапшырылган документлар нигезендә опека һәм попечительлек секторы белгече балигъ булмаган затның акча кертемен алуга рөхсәт бирү күрсәтү турында боерык проекты әзерли һәм аны килештерү һәм раслату өчен опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә җибәрә яки тиешле аныклау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: опекага алучыга яки попечительгә балигъ булмаган затның акча кертемен алуга рөхсәт бирү турында боерык яки 3.7 пункты нигезендә әзерләнгән хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.6. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен тапшыру.

3.6.1. Опека һәм попечительлек секторы белгече, имзаланган боерыкны алгач, аны терки һәм гариза бирүчегә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.4 подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.7. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат тапшыру.

3.7.1 Опека һәм попечительлек секторы белгече боерык бирүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты әзерли.

Әзерләнгән баш тарту турында хат проектын опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар баш тарту өчен нигезләр ачыкланган көннән соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзалауга юлланган баш тарту турында хат проекты.

3.7.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек секторы белгеченә кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзаланган баш тарту турында хат.

3.7.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече баш тарту турында хатны аны имзалаган көннән соң 1 эш көне эчендә гариза бирүчегә юллый. Шул ук вакытта гариза бирүчегә карарны шикаять итү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.7.2. подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формасы

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларын үтәүне тикшерүне, карар кабул итүне һәм күпфункцияле үзәкнең (хезмәт күпфункцияле үзәк аркылы күрсәтелсә), опека һәм попечительлек бүлегенең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап бирүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларының хокукый экспертизасын үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау;

- кабул итлегән тәртиптә делопроизводство алып баруны тикшерү;

- кабул ителгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү үткәрү процедураларына контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерү үткәргән вакытта дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык сораулар каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта һәм карар кабул иткән вакытта гамәлләрне башкаруны тикшерүне башкару максатында күпфункцияле үзәк, опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затлар исемлеге күпфункцияле үзәкнең, опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы гариза бирүченең мөрәҗәгатен вакытында карамаган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезләнмәгән рәвештә баш тарткан өчен җавап бирә.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, аларның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелгән очракта), опека һәм попечительлек секторы хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Арча муниципаль районы башкарма комитетына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итәргә мөкин:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган документлар, мәгълүмат яки гамәл кылу таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү вакыты яки тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылганда, әгәр туктатылу нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта мөрәҗәгать итүчедән беренче тапкыр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документлар тапшырган вакытта булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү.

5.2. Шикаять почта аркылы язма рәвештә кәгазь битендә яки электрон формада җибәрелергә, шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәткән очракта шикаять күпфункцияле үзәк аркылы җибәрелә ала.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең документларны кабул итүдән баш тартуына яки киткән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять биргән очракта яки мондый төзәтүләрне башкаруның кабул ителгән вакыты бозылуга шикаять биргән очракта – аны теркәгән көннән соң 5 эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исемен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки муниципаль хезмәткәрнең исемен;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән риза булмавына дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә тасвирланган вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре теркәлгән булырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документлар исемлеге бирелә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәте күрсәтелүче зат тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта Башкарма комитет тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта ачыкланган бозуларны кичекмәстән бетерү максатында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле гамәлләр турында әйтелә.

5.9. Әгәр шикаять канәгатьләндерелмәсә, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул итлегән карарга нигезләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында аңлатма бирелә.

5.10. Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Законлы вәкиленә балигъ булмаган затның акча кертемен алуга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
1 Кушымта

______________________________________________
______________________________________________
_____________адресы буенча яшәүче
(тулы адрес)
___________________________________________ннән
(тулысынча фамилиясе, исеме)
_____________________________
Телефон:_______________________________________
Паспорт:_______________________________________
(серия,номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

ГАРИЗА

Минем _____________ елда туган улымның (кызымның), опекага алынган затның _____________________________________________________________________________________________,
(балигъ булмаган затның тулысынча фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
______________________________банкындагы счетыннан ________________________________________
_______________________________________________________________________________сәбәпле акча
(баланың акча кертемен алу сәбәбен аңлатырга)
кертемен алуга рөхсәт бирүегезне сорыйм.
____________________________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________________________

_______ка кадәр опека органына акчаны бала (опекага алынган зат) мәнфәгатьләрендә кулланыну раслаучы документлар тапшырырга һз өстемә йөкләмә алам.

«___» _____________ 20___ ел                    _______________
(имза)

Законлы вәкиленә балигъ булмаган затның акча кертемен алуга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
2 Кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне агымдагы контрольдә тотучы җаваплы вазыйфаи затларның**
**РЕКВИЗИТЛАРЫ**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**


| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |
| Сектор белгече | (8-84366) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-84366) 3-00-44 | Ispolkom.Arsk@tatar.ru |

Законлы вәкиленә балигъ булмаган затның акча кертемен алуга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
3 Кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы**



Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының
«__»_________, 2019 ел, №_____
Карарына

**Балигъ булмаган затлар катнашында торак залогын яңадан рәсмиләштерүгә (яңадан финанслау) алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү**
**Административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге регламент Арча муниципаль районы территориясендә яшәүче балигъ булмаган затлар катнашында торак залогын яңадан рәсмиләштерүгә (яңадан финанслау) алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандарты һәм тәртипләрен билгели.

1.2. Хезмәтне алучылар: балигъ булмаган затлар катнашында торак залогын яңадан рәсмиләштерүгә (яңадан финанслау) алдан рөхсәт алырга теләүче ундүрт яше тулган балигъ булмаган Россия Федерациясе гражданнары яки балигъ булмаганнарның ундүрт яше тулмаган балигъ булмаган гражданнарның законлы вәкилләре (алга таба – гариза бирүчеләр).

1.3. Дәүләт хезмәте ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен башкаручы – балигъ булмаган затның теркәлү урыны буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (алга таба – опека һәм попечительлек органы).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

1.3.2. Опека һәм попечительлек органы урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

Эш режимы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш.

Төшке аш вакыты – 12.00 – 13.00.

Эчкә үтү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне аныклаучы документ буенча.

1.3.3. Опека һәм попечительлек органы телефоны: (84366)3–13–81.

1.3.4. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайты (алга таба – «Интернет» челтәре): http://www.arsk.tatarstan.ru.

1.3.5. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы бинасында урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аркылы;

2) «Интернет» челтәре аша:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында http://www.arsk.tatarstan.ru;

3) опека һәм попечительлек секторына шәхси мөрәҗәгать итеп;

4) күпфункцияле үзәктә (хезмәт күрсәтүне күпфункцияле үзәк аркылы алып булган очракта).

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә башкарыла:

- Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гражданлык кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 05.12.1994, №32, 3301 маддә);

- Россия Федерациясе Гаилә кодексы 1995 елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гаилә кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 01.01.1996, №1 16 маддә;

- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 01 гыйнварындагы 48-ФЗ номерлы Федераль законы (алга таба – 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 28.04.2008, №17, 1755 маддә);

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 маддә);

- Татарстан Республикасы Гаилә кодексы 2009 елның 13 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы (алга таба – ТР Гаилә кодексы) (Республика Татарстан, 16.01.2009, №8);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №43–44, 02.03.2004);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №60-61, 25.03.2008);

- «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 нче номерлы Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинеты Карары (алга таба – 880 нче номерлы ТР Министрлар кабинеты карары) (Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карарлары һәм республика башкарма комитет органнары норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, 2144 маддә; 20.12.2011);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 15 августындагы боерыгы белән расланган Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында Нигезләмәсе (алга таба – опека секторы турнда Нигезләмә).

1.5.Әлеге Регламентта түбәндәге термин һәм билгеләмәләр кулланыла:

- административ регламент – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралар һәм административ эшчәнлек вакытын һәм эзлеклелеген, структур бүлекчәләр һәм вазыйфаи затлар арасындагы хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хакимияте башкарма органнарының физик яки юридик затлар (алга таба – дәүләт хезмәте алучылар), башка дәүләт хезмәте һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгеләүче норматив хокукый документ;

- дәүләт хезмәте – дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән чикләрдә мөрәҗәгать итүче соравы буенча башкарыла торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарган вакытта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек;

- дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе $1^1$ бүлегендә каралган оешмалар яки аларның эшчеләре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта бозылган хокукларны яки законлы мәнфәгатьләрне кире кайтару яки саклау турында таләбе.

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт яки муниципаль учреждениенең оештыру-хокукый формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирүче һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча, вәкаләтле оешма;

- «бер тәрәзә» принцибы – мөрәҗәгать итүче 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ маддәсендә күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау белән бер тапкыр мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү, ә дәүләт хезмәт күрсәтүче органнар яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар белән күпфункцияле үзәк тарафыннан мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка норматив хокукый актлар һәм хезмәттәшлек итү турында килешү нигезендә хезмәттәшлек алып бару принцибы.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбе исеме | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте исеме | Балигъ булмаган затлар катнашында торак залогын яңадан рәсмиләштерүгә (яңадан финанслау) алдан рөхсәт бирү | РФ Гаилә кодексының 60 маддәсе;<br>РФ Гражданлык кодексының 26, 28 маддәләре;<br>РФ Гражданлык кодексының 37 маддәсе;<br>48-ФЗ номерлы Федераль законның 21 маддәсе |
| 2.2. Хезмәт күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты (балигъ булмаган затның теркәлү урыны буенча) | 8-ТРЗ номерлы ТР Законы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль законның 21 маддәсе |
| 2.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Балигъ булмаган затлар катнашында торак залогын яңадан рәсмиләштерүгә (яңадан финанслау) боерык формасында алдан рөхсәт бирү яки хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында нәтиҗә | РФ Гаилә кодексының 60 маддәсе;<br>РФ Гражданлык кодексының 37 маддәсе;<br>48-ФЗ номерлы Федераль законның 21 маддәсе |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты | Гражданнарның дәүләт хезмәте күрсәтүгә кагылышлы язма мөрәҗәгатьләрен карау аларны теркәгәннән соң 15 көн эчендә башкарыла.<br>Ведомсвоара мәгълүмати хезмәттәшлек очрагында – мөрәҗәгатьне теркәгәннән соң 30 көннән дә соң түгел. | 48-ФЗ номерлы Федераль законның 21 маддәсе;<br>РФ Гражданлык кодексының 37 маддәсе<br>59-ФЗ номерлы Федераль законның 12 маддәсе |
| 2.5. Закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәте өчен кирәк һәм мәҗбүри булган документларның тулы исемлеге | 1. Торак бинаның барлык милекчеләренең, балигъ булмаган затларның әти-әниләренең (яки аларны алыштыручыларның) гаризалары (1 Кушымта);<br>2. Әти-әнисе ризалыгы белән эш итүче 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган затның гаризасы;<br>3. Хезмәт күрсәтүче органга булган кредитны яңадан финанслау максатында ипотека кредиты бирү турында банктан хат;<br>4. Гариза бирүчеләрнең паспорт күчермәләре (1 бит + яшәү урыны буенча теркәлү).<br>5. Баланың (балаларның), шул исәптән 14 яшьтән өлкәнрәкләрнең туу турында таныклык күчермәсе.<br>6. Фатир сату-алу (кредит килешүе) килешүе күчермәсе.<br>7. Фатирның техник паспот күчермәсе (яки техник инвентаризация бюросы белешмәсе күчермәсе) күчермәсе.<br>Төп нөсхәләре булган очракта, документлар күчермәләре 1 нөсхәдә бирелә | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган дәүләт | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында таләп ителергә мөмкин булган документлар: | |

| | | |
|---|---|---|
| органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм алар бирергә хокуклы булган документларның тулы исемлеге | - балигъ булмаган затларның сатып алына торган фатирга теркәлү урыныннан йорт (фатир) кенәгәсеннән өземтә | |
| 2.7. Норматив хокукый актлар белән каралган очракларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган һәм хезмәт күрсәтә торган башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла торган дәүләт хакимияте һәм аның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Балигъ булмаган затның теркәлү урыны буенча мөрәҗәгать итмәве | |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>- тапшырылган документларның әлеге Административ регламентның 2.5 пукнтында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>- балигъ булмаган затның милек хокукларын кысу. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Түләүсез нигездә | |
| 2.11. Әлеге түләүне исәпләү турында мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргән вакытта һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алган вакытта чиратта көтүнең максималь вакыты | Көтеп утыруның (хезмәт күрсәтүнең) максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Аерым категория кешеләр өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты | Гариза кергән көнне | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | 1. Гариза түбәндәге адрес буенча тапшырыла:<br>Арча шәһәре, Советлар мәйданы урамы, 12 йорт, опека һәм попечительлек секторы.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазланган бинада башкарыла;<br>3. Бинада гаризалар кабул итү өчен сектор белгеченең эш урыны хезмәтне тулысынча күрсәтергә мөмкинлек бирүче электрон белешмә-хокукый системалар, оргтехника белән тәэмин ителгән шәхси компьютер белән җиһазландырыла.<br>4. Документлар тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазлана һәм документлар тутыру үрнәкләре белән тәэмин ителә.<br>5. Инвалидларга хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыкларсыз керү тәэмин | |

| | | |
|---|---|---|
| | ителә, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм чыгу юлларына, дәүләт хезмәте күрсәтү урынына барып житү максатында объект буйлап мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итү тәэмин ителә.<br>6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны исәпкә алып, урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Хезмәт күрсәтүнең аңлаешлылыгы күрсәткечләре:<br>бинаның җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы;<br>җитәрлек белгечләр булу, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә башкарма комитетның мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү бердәм порталында хезмәт күрсәтү тәртибе, ысуллары, вакыты турында тулы мәгълүмат булу;<br>инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт алырга комачаулаучы каршылыкларны узарга ярдәм итү.<br><br>Хезмәт күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре:<br>гариза бирүче документлар тапшырганда һәм алганда чиратлар булмау;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын саклау;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирмәү;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә игътибарсызлык күрсәтүенә шикаять бирмәү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратып алу биргән очракта һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен алган вакытта муниципаль хезмәт күрсәтә торган вазыйфаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр аралашуы күздә тотыла.<br>Хезмәттәшлек вакыты регламент белән билгеләнә. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Хезмәт электрон формада күрсәтелми | |

## 3. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкару составы, эзлеклелеге һәм вакыты, аларны башкару тәртибенә таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау:

3.1.1. Балигъ булмаган затлар катнашында торак залогын яңадан рәсмиләштерүгә (яңадан финанслау) алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчеләргә консультация бирү;

2) гаризаны һәм документларны кабул итү (әлеге регламентның 2.5 пунктын кара);

3) Балигъ булмаган затлар катнашында торак залогын яңадан рәсмиләштерүгә (яңадан финанслау) алдан рөхсәт әзерләү;

4) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

5) нигезләр булган очракта гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема әлеге Административ регламентка 3 кушымтада бирелә.

3.2. Консультация күрсәтү

Дәүләт хезмәте алу турында консультация алу өчен гариза бирүче шәхсән опека һәм попечительлек секторына мөрәҗәгать итә.

Опека һәм попечительлек секторы белгече тарафыннан гариза бирүчегә консультация күрсәтелә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәк булган документлар составы, формасы һәм эчтәлеге буенча.

Консультация гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне күрсәтелә.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документлар составына, формасына, эчтәлегенә карата консультация, кисәтүләр.

3.3. Гариза, документлар кабул итү.

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән үзе опека һәм попечительлек секторына, күпфункцияле үзәккә (хезмәт күпфункцияле үзәктә күрсәтелгән очракта) гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыра.

3.3.2. Кабул итү алып баручы опека һәм попечительлек секторы, күпфункцияле үзәк белгече:

- гариза бирүченең шәхесен, балигъ булмаган затның яшәү урынын билгели;

- документларның барлыгын тикшерә. Кирәкле документлар булмаган очракта җитмәгән документларны тапшырырга тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларны кабул итүне таләп итсә, документлар кабул ителә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта опека һәм попечительлек, күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелсә) белгече гариза бирүчегә гариза һәм документлар алу, теркәлү номеры турында хәбәр итә, аннан соң әлеге Регламентның 3.3.3 подпунктында күрсәтелгән процедуралар башкарыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән көннән соң 1 кңн эчендә 15 минут вакыт аралыгында башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язмасы.

3.3.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече гариза бирүче тапшырган документлардагы мәгълүматны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергәннән соң 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәт бирү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратып алу әзерләү һәм җибәрү.

3.4.1 Опека һәм попечительлек белгече (гариза бирүче белән килештереп) ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү системасы аркылы әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны җибәрү турында электрон формада соратып алу юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән көннән 2 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында юлланган соратып алу.

3.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы опека һәм попечительлек секторы органнары соратуы буенча автоматлаштырылган режимда башкарыла:

- соратып алуны эшкәртү һәм соратылган мәгълүматны эзләү;

- ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү аркылы соратып алынган мәгълүматны формалаштыру, соратып алынган мәгълүмат булмаган очракта, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, соратып алынган мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар опека һәм попечительлек органнарына соратып алу кергән вакыттан 5 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: соратып алуга җавап яки әлеге Регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән мәгълүматны бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.5.1. Тапшырылган документлар нигезендә опека һәм попечительлек секторы белгече балигъ булмаган затлар катнашында торак залогын яңадан рәсмиләштерүгә (яңадан финанслау) алдан рөхсәт бирү буенча боерык проекты әзерли һәм аны килештерү һәм раслату өчен опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә җибәрә яки тиешле аныклау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: балигъ булмаган затлар катнашында торак залогын яңадан рәсмиләштерүгә (яңадан финанслау) алдан рөхсәт бирү турында дәүләт хезмәте күрсәтү, боерык яки 3.7 пункты нигезендә әзерләнгән хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.6. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен тапшыру.

3.6.1. Опека һәм попечительлек секторы белгече, имзаланган боерыкны алгач, аны терки һәм гариза бирүчегә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.5.1 подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.7. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат тапшыру.

3.7.1 Опека һәм попечительлек секторы белгече боерык бирүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты әзерли (алга таба – баш тарту турында хат).

Әзерләнгән баш тарту турында хат проектын Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедуралар тәмамланганнан соң 5 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзалауга юлланган баш тарту турында хат проекты.

3.7.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек секторы белгеченә кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: имзаланган баш тарту турында хат.

3.7.3. Опека һәм попечительлек секторы белгече баш тарту турында хатны аны имзалаган көннән соң 1 көн эчендә гариза бирүчегә юллый. Шул ук вакытта гариза бирүчегә карарны шикаять итү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар 3.7.2. подпункты белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формасы

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларын үтәүне тикшерүне, карар кабул итүне һәм күпфункцияле үзәкнең (хезмәт күпфункцияле үзәк аркылы күрсәтелсә), опека һәм попечительлек бүлегенең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап бирүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларының хокукый экспертизасын үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау;
- кабул итлегән тәртиптә делопроизводство алып баруны тикшерү;
- кабул ителгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү үткәрү процедураларына контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерү үткәргән вакытта дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык сораулар каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта һәм карар кабул иткән вакытта гамәлләрне башкаруны тикшерүне башкару максатында күпфункцияле үзәк, опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы опека һәм попечительлек органы җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затлар исемлеге күпфункцияле үзәкнең, опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы гариза бирүченең мөрәҗәгатен вакытында карамаган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезләнмәгән рәвештә баш тарткан өчен җавап бирә.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, аларның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелгән очракта), опека һәм попечительлек секторы хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Арча муниципаль районы башкарма комитетына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итәргә мөкин:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган документлар, мәгълүмат яки гамәл кылу таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү вакыты яки тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылганда, әгәр туктатылу нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта мөрәҗәгать итүчедән беренче тапкыр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документлар тапшырган вакытта булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү.

5.2. Шикаять почта аркылы язма рәвештә кәгазь битендә яки электрон формада җибәрелергә, шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәткән очракта шикаять күпфункцияле үзәк аркылы җибәрелә ала.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең документларны кабул итүдән баш тартуына яки киткән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять биргән очракта яки мондый төзәтүләрне башкаруның кабул ителгән вакыты бозылуга шикаять биргән очракта – аны теркәгән көннән соң 5 эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исемен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки муниципаль хезмәткәрнең исемен;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән риза булмавына дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә тасвирланган вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре теркәлгән булырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документлар исемлеге бирелә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәте күрсәтелүче зат тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта Башкарма комитет тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта ачыкланган бозуларны кичекмәстән бетерү максатында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүче башкарырга тиешле гамәлләр турында әйтелә.

5.9. Әгәр шикаять канәгатьләндерелмәсә, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул итлегән карарга нигезләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында аңлатма бирелә.

5.10. Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Балигъ булмаган затлар катнашында торак залогын яңадан рәсмиләштерүгә (яңадан финанслау) алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
1 Кушымта

ТР Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына
______________________________________________
______________________________________________
_____________адресы буенча яшәүче
___________________________________________ннән
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
Паспорт:_____________________________________
Телефон:_____________________________________

**ГАРИЗА**

_____________________________________ адресы буенча урнашкан гомуми мәйданы ________кв.м, торак мәйданы _____________ кв.м булган ________ бүлмәле, ___________________________ милкенә ипотека килешүе буенча сатып алына торган фатирны ____________________ Банкыннан ________________________ Банкына залогны яңадан тәсмиләштерергә рөхсәт бирүегезне сорыйм, балигъ булмаган затларның өлешләрен саклап:

____________________________________________, _____________елгы, - _____ өлеш.
Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туу датасы

____________________________________________, _____________елгы, - _____ өлеш.
Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туу датасы

Барлык кызыксынган якларның ризалыгы бар,балигъ булмаган затларның милек һәм торак хокуклары һәм мәнфәгатьләре кысылмый.

Мин (без) минем (безнең) шәхси мәгълүматны опека һәм попечительлек секторы тарафыннан эшкәртүгә ризалык бирәм (без).

________________________ ________________________
(дата) (имза)

Балигъ булмаган затлар катнашында торак залогын яңадан рәсмиләштерүгә (яңадан финанслау) алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
2 Кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне агымдагы контрольдә тотучы җаваплы вазыйфаи затларның**
**РЕКВИЗИТЛАРЫ**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**


| **Вазыйфа** | **Телефон** | **Электрон адрес** |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-84366 ) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |
| Сектор белгече | (8-84366 ) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты (шәһәр округы)**

| **Вазыйфа** | **Телефон** | **Электрон адрес** |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-84366) 3-00-44 | Ispolkom.Arsk@tatar.ru |

Балигъ булмаган затлар катнашында торак залогын яңадан рәсмиләштерүгә (яңадан финанслау) алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
3 Кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы**



Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының
«__»_________, 2019 ел, №_____
Карарына

**Суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган, социаль учреждениедә социаль хезмәт күрсәтүдә булган балигъ булган затны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче граждannar гаиләләренә вакытлыча яшәргә бирү турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү**
**Административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге регламент суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган, социаль учреждениедә социаль хезмәт күрсәтүдә булган балигъ булган затны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча яшәргә бирү турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – хезмәт, дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар: суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган балигъ булган затны гаиләгә алырга теләүче Россия Федерациясе гражданнары (алга таба – гариза бирүчеләр).

1.3. Дәүләт хезмәте ТР Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен башкаручы – гариза бирүченең яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы (алга таба – опека һәм попечительлек органы).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 422000, Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Советлар мәйданы, 12 йорт.

Эш режимы: дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш.

Төшке аш вакыты – 12.00 – 13.00.

Эчкә үтү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне аныклаучы документ буенча.

1.3.2. Опека һәм попечительлек органы телефоны: (84366)3–13–81.

1.3.3. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайты (алга таба – «Интернет» челтәре): http://www.arsk.tatarstan.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы бинасында урнашкан һәм дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аркылы;

2) «Интернет» челтәре аша:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында http://www.arsk.tatarstan.ru;

3) опека һәм попечительлек секторына шәхси мөрәҗәгать итеп;

4) күпфункцияле үзәктә (хезмәт күрсәтүне күпфункцияле үзәк аркылы алып булган очракта).

1.4. Хезмәт күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә башкарыла:

- Россия Федерациясе Конституциясе (бөтенхалык тавыш бирүе белән 12.12.1993 елда кабул ителгән) (алга таба – РФ Конституциясе) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 26.01.2009, №4, 445 маддә);

- Татарстан Республикасы Конституциясе 1992 елның 06 ноябрендәге (алга таба – ТР Конституциясе) (Республика Татарстан, №87-88, 30.04.2002);

- Россия Федерациясе Гаилә кодексы 1995 елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы (алга таба – РФ Гаилә кодексы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 01.01.1996, №1, 16 маддә);

- Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы;

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 маддә);

- «Психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткән вакытта гражданнар хокуклары гарантияләре турында» 1992 елның 02 июлендәге 3185-1 номерлы Россия Федерациясе законы (алга таба – 3185-1 номерлы РФ Законы) («Россия Федерациясенең халык депутатлары Советы һәм Югары Советы ведомосте», 20.08.1992, №33, 1913 маддә);

- «Өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтү турында» 1995 елның 02 августындагы 122-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 122-ФЗ номерлы Федеральный закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 07.08.1995, №32, 3198 маддә);

- «Күчемсез милеккә хокук һәм аның белән килешүләрне дәүләт теркәве турында» 1997 елның 21 июлендәге 122-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба дәүләт теркәве турында ФЗ) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 28.07.1997, №30, 3594 маддә);

- «Шәхси мәгълүмат турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 152-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2006, №31 (1 бүлек), 3451 маддә);

- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 28.04.2008, №17, 1755 маддә);

- «Россия Федрациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрнедәге 131-ФЗ нмоерлы Федераль закон (РФ Законнар дыентыгы, 06.10.2003, №40, 3822 маддә);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №43-44, 02.03.2004);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, №60-61, 25.03.2008);

- «Балигъ булган эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраксыз гражданнарга карата опека һәм попечительлек башкаруның аерым мәсьләләре турында» 2010 елның 17 ноябрендәге 927 нче номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары;

- «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 880 нче номерлы Карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары җыелмасы, 08.12.2010, №46, 2144 маддә);

- «Өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү дәүләт стационар учреждениеләрендә социаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмә раслау турында» 2007 елның 18 июнендәге 245 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары (алга таба – 245 нче номерлы ТР Министрлар кабинеты карары) (Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыелмасы, 11.07.2007, №25-26, 0916 маддә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2011 елның 14 октябрендәге 64 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Уставы (алга таба – Устав);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының 2015 елның 24 февралендәге 7 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2011 елның 31 гыйнварындагы 31.1 нче боерыгы белән расланган Арча муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – башкарма комитет турында Нигезләмә);

- Арча район Советының 2010 елның 22 декабрендәге 27 нче номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы башкарма комитеты опека һәм попечительлек секторы (бүлеге) турында Нигезләмә йалга таба – опека органы (секторы) турында Нигезләмә);

- Башкарма комитетның 2007 елның 30 мартындагы 204 нче номерлы карары белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр).

1.5.Әлеге Регламентта түбәндәге термин һәм билгеләмәләр кулланыла:

- административ регламент –Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының административ процедуралар һәм административ эшчәнлек вакытын һәм эзлеклелеген, структур бүлекчәләр һәм вазыйфаи затлар арасындагы хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хакимияте башкарма органнарының физик яки юридик затлар (алга таба – дәүләт хезмәте алучылар), башка дәүләт хезмәте һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгеләүче норматив хокукый документ;

- дәүләт хезмәте – дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән чикләрдә мөрәҗәгать итүче соравы буенча башкарыла торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарган вакытта Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек;

- дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе 11 бүлегендә каралган оешмалар яки аларның эшчеләре тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта бозылган хокукларны яки законлы мәнфәгатьләрне кире кайтару яки саклау турында таләбе.

- опека – суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган гражданнарның төзелеш формасы, опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (опекуннар) аларның законлы вәкилләре булып санала һәм алар исеменнән һәм алар мәнфәгате буенча юридик әһәмияткә ия булган гамәлләр башкара ала;

- попечительлек – суд тарафыннан эшкә яраксызлыгы чикләнгән гражданнарның төзелеш формасы, опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (попечительләр) балигъ булган опекага алынган затларга РФ Гражданлык кодексының 30 маддәсе белән каралган гамәлләр кылуга ризалык бирергә тиеш.

- опекага алынган зат – аңа карата опека яки попечительлек билгеләнгән гражданин;

- эшкә яраксыз гражданин – РФ Гражданнар Кодексының 29 маддәсе нигезендә суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган гражданин;

- техник хата – дәүләт хзмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәитҗәсе) кертелгән мәгълүматның чагышмавына китергән хата (хәреф хатасы, грамматик яки арифметик яки шуңа охшаш хата);

- дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәгенең ерагайтылган эш урыны – муниципаль районның авыл җирлекләрендә гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү _әм бирү, консультация күрсәтү.

- Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) астында дәүләт хезмәте күрсәтү турында сорау аңлашыла (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 маддәсе 2 пункты). Гариза стандарт бланкта тутырыла (1 Кушымта).

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбе исеме | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Хезмәт күрсәтү исеме | Суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган, социаль учреждениедә социаль хезмәт күрсәтүдә булган балигъ булган затны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча яшәргә бирү турында нәтиҗә бирү | РФ Гражданлык кодексы;<br>РФ Гаилә кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>927 нче номерлы РФ карары;<br>8-ТРЗ номерлы ТР Законы |
| 2.2. Турыдан-туры хезмәт күрсәтүче орган исеме | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты | Устав;<br>7-ТРЗ номерлы ТР законы |
| 2.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Язма рөхсәт бирү формасында опека һәм попечительлек секторы нәтиҗәсе яки баш тарту турында хат | РФ Гражданлык кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>927 нче номерлы РФ карары;<br>8-ТРЗ нмоерлы ТР Законы |
| 2.4. Хезмәт күрсәтү вакыты | Нәтиҗә бирү соратып алуны теркәгәннән соң 15 көн эчендә башкарыла, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек вакытында – 30 көннән дә артык түгел | 927 нче номерлы РФ карары;<br>48-ФЗ нмоерлы Федераль закон;<br>210-ФЗ нмоерлы Федераль закон |
| 2.5. Закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларның тулы исемлеге | 1. Гариза (1 Кушымта).<br>2. Гариза бирүченең паспорты һәм күчермәсе.<br>3. Медицина нәтиҗәсе.<br>4. Гражданинны эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы дип тану турында суд карары.<br>Документларның төп нөсхәләре һәм күчермәләре (чагыштырып чыкканнан соң төп нөсхәләре кире кайтарыла) тапшырыла, документларның нотариаль рәвештә расланган күчермәләрен кабул итү мөмкин. | РФ Гражданлык кодексы; РФ Салым кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>927 нче номерлы РФ карары;<br>210-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган документларның тулы исемлеге | Белгеч тарафыннан ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында соратылырга мөмкин булган документлар:<br>- яшәү урыны буенча йорт (фатир) кенәгәсеннән өземтә яки торак бинадан куллануга хокукны яки торак бинага милек хокукын раслаучы башка документ;<br>- яшәү урыны буенча финанс-хисап счеты күчермәсе;<br>- гаиләгә эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы гражданинны алырга теләүче гражданинның хөкем ителмәве турында эчке эшләр органыннан белешмә. | 210-ФЗ нмоерлы Федераль закон |
| 2.7. Норматив хокукый актлар белән каралган очракларда хезмәт күрсәтү өчен килештерү таләп ителә торган һәм хезмәт күрсәтә торган башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла торган дәүләт хакимияте һәм аның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итеп алудан баш тарту өчен нигезләр:<br>- гариза бирүче тапшырган документлар кабул ителгән таләпләргә туры килми;<br>- гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган, әлеге Регламент белән каралган тулы булмаган документлар комплекты тапшыру;<br>- гариза бирүче тапшырган документларда каршылыклы мәгълүмат китерелү;<br>- гариза бирүченең фактик яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итмәве. | 927 нче номерлы РФ карары |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен сәбәпләр:<br>Әгәр гариза бирүче түбәндәге категорияләргә керсә:<br>- суд тарафыннан эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы дип танылган затлар;<br>- йөкләнгән вазыйфларны тиешенчә үтәмәгән өчен опекага алучы (попечитель) вазыйфаларын читләштерелгән затлар;<br>- хөкем ителгән затлар. | РФ Гражданлык кодексы;<br>РФ Гаилә кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>8-ТРЗ номерлы ТР Законы |
| 2.10. Хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә. | |
| 2.11. Әлеге түләүне исәпләү турында мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр таләп ителми | |
| 2.12. Хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алган вакытта чиратта көтүнең максималь вакыты | Аерым категория кешеләр өчен чират билгеләнмәгән.<br>Көтеп утыруның (хезмәт күрсәтүнең) максималь вакыты 30 минуттан артмаска тиеш. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты | Гариза кергән көннән соң 1 көн эчендә | 59-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.14. Хезмәтләр күрсәтелә торган биналарга таләпләр | 1. Гариза түбәндәге адрес буенча тапшырыла:<br>Арча шәһәре, Советлар мәйданы урамы, 12 йорт, опека һәм попечительлек секторы.<br>Гариза бирүчеләрне кабул итү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазланган бинада башкарыла. Инвалидларга хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыкларсыз керү тәэмин ителә, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм чыгу юлларына.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны исәпкә алып, урнаштырыла. | |
| 2.15. Хезмәт күрсәтүнең мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең аңлаешлылыгы күрсәткечләре:<br>- бинаның җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы;<br>- мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү өчен бина һәм җитәрлек | |

| | | |
|---|---|---|
| | белгеч булуы;<br>- мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә башкарма комитетның мәгълүмати ресурсларында, Арча муниципаль районы рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, ысуллары, вакыты турында тулы мәгълүмат булу.<br>- гаризаны электрон формада тапшыру мөмкинлеге.<br>Хезмәт күрсәтү сыйфаты күрсәткечләре:<br>- документларны кабул итү һәм карау вакытын саклау;<br>- дәүләт хезмәте алу вакытын саклау;<br>- опека һәм попечительлек секторы белгечләре тарафыннан әлеге Регламент бозылуга прецедентлар (нигезләнгән шикаятьләр) булу;<br>- гариза бирүченең опека һәм попечительлек секторы белгечләре белән хезмәттәшлек итү саны: турыдан туры дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документлар тапшырганда – ике тапкырдан күбрәк түгел (консультацияләрне санамыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларны почта аркылы җибәргәндә, шул исәптән электрон почта аша – бер тапкырдан күбрәк түгел.<br>Гариза бирүченең белгеч белән бер хезмәттәшлеге дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне кертеп, күпфункцияле үзәк аркылы, күпфункцияле үзәктә ераклаштырылган эш урыннарында дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Арча муниципаль районы сайтында, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү бердәм порталында, Татарстан республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт порталында алынырга мөмкин. | |
| 2.16. Хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүматны башкарма комитетның Интенет-кабул итү бүлмәсе аркылы яки Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт порталы аркылы алырга мөмкин.<br>Хезмәт электрон формада күрсәтелми | |

### 3. Административ процедураларны (гамәлләрне) башкару составы, эзлеклелеге һәм вакыты, аларны башкару тәртибенә таләпләр, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә административ процедураларны электрон формада башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә, күпфункцияле үзәкләрдәге ераклаштырылган эш урыннарында башкару үзенчәлекләре

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеген тасиврлау.

Дәүләт хезмәте күрсәтү үз эченә түбәндәге процедураларны ала:

- гариза бирүчегә мәгълүмат һәм консультация күрсәтү;
- гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документлар кабул итү;

Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган ведомствоара соратып алу формалаштыру һәм җибәрү, гариза бирүченең торак-көнкүреш шартларын тикшерү һәм документларны эшкәртү;

- дәүләт хезмәте күрсәтү яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү;
- гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен тапшыру яки нигезләр булган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш атрту турында хат җибәрү, социаль учреждениедә яшәүче эшкә яраксыз затны вакытлыча Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә тапшыру турында нәтиҗә әзерләү.

Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемада (7 кушымта) күрсәтелгән.

3.1.2. Административ процедура башлау өчен нигез булып гражданинның опека һәм попечительлек секторына консультация алу өчен мөрәҗәгать итүе тора. Опекага алучы белгечкә паспортын, ә Россия Федерациясе законнары белән каралган очракларда, шәхесне раслаучы башка документ күрсәтә. Гражданнарга мәгълүмат һәм консультация бирү өчен җаваплы тиешле сектор белгече мәгълүмат һәм консультация бирү кысаларында:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартларын һәм тәртибен көйләүче норматив хокукый аклар турында мәгълүмат бирә;
- гражданинны суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган, стационар учреждениедә стационар хезмәт күрсәтүдә булган балигъ булган затны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча бирү буенча нәтиҗә бирү мәсьәләләре буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән таныштыра (алга таба – хезмәт күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтү);
- опекага алучыга дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен аңлата;
- социаль учреждениедә социаль хезмәт күрсәтүдә булган эшкә яраксыз балигъ булган затны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча яшәргә бирү турында нәтиҗә бирү өчен кирәкле документлар исемлеген бирә;
- дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза язу формасы турында аңлата.

Консультация телдән гариза белән мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне сорау гариза бирүчегә документлар рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтүне таләп итми.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар: гариза һәм документлар кабул итү 15 минут эчендә башкарыла.

Гаризаны теркәү гариза кергәннән соң 1 көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алуның башка мәсьәләләре буенча консультация һәм мәгълүмат бирү

3.3. Документлар кабул итү буенча административ процедуралар эшләүне башлау өчен нигез булып гариза бирүче тарафыннан гариза һәм әлеге административ регламентның 2.5. пункты белән каралган документлар тапшыру тора.

Гариза бирүче секторга шәхсән үзе дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза һәм әлеге Регламентның 2.5. пункты нигезендә документлар. Документлар кабул итү буенча административ процедуралар башкара башлау өчен нигез булып гариза бирүче тарафыннан гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.5. пунктында каралган документлар тапшыру тора.

Гариза һәм документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч әлеге Административ регламент нигезендә барлык кирәкле документларның барлыгын тикшерә, шул исәптән:

- гражданинның шәхесен билгели – шәхесне билгеләүче документны тикшерә;
- гражданин китергән барлык документларның барлыгын һәм билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә;
- документларның дөрес тутырылуын тикшерә;
- документ текстлары ачык итеп язылуын һәм карандаш белән төзәтелмәгән булуын билгели;
- документларда төзәтүләр, өстәп язулар, сызылган һәм башка төзәтүләр булмавын билгели, шул исәптән документларның эчтәлеген дөрес аңламауга китерә торган җитди ватыклар булмавын билгели;
- кергән документларны терки;
- муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты опекунлык комиссиясенә тапшыру өчен документлар пакеты формалаштыра.

Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч, конфиденциаль мәгълүматны исәпкә алып, документлар кабул итү буенча процедураларның дөреслеге өчен шәхси җавап бирә.

Сектор белгечләре опекага алынган затлар турында мәгълүмат банкында булган конфиденциаль мәгълүматка санкцияләнмәгән керүне булдырмаска һәм (яки) аны әлеге мәгълүматны белергә тиеш булмаган затларга бирмәскә тиеш.

Опека һәм попечительлек секторында булган конфиденциаль мәгълүматны саклауны тәэмин итү максатында белгечләргә әлеге мәгълүмат булган документларны һәм тышкы носительләрне вакытлы куллануга өченче затларга, шул исәптән хезмәт эшчәнлеге буенча эшкә яраксыз яки өлешчә эшкә яраклы гражданнар турында мәгълүмат банкына керергә рөхсәте булмаган белгечләргә бирү тыела.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза кергән вакыттан соң 1 эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гаризалар теркәү журналында теркәү язмасы, расписка яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.1. Вазыйфаи зат яшәү урыны буенча йорт (фатир) кенәгәсеннән өземтә яки торак бина белән куллануга хокукны, торакка милек хокукын раслаучы башка документ һәм яшәү урыны буенча финанс-хисап счеты күчермәсе алу максатында дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратып алу юллый.

3.4. Кирәкле документларның булмавы, тапшырылган документларның Регламент таләпләренә туры килмәве, гаризада яки тапшырылган документларда булган мәгълүматның туры килмәве яки гаризада кирәкле мәгълүмат булмавы ачыкланган очракта документлар кабул иткән вакытта документлар кабул итү өчен җаваплы хезмәткәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен ачыкланган каршылыкларны формалаштыра һәм аны тапшырылган документлар белән бергә гариза бирүчегә тапшыра.

Процедуралар нәтиҗәсе: соратып алуга җавап яки мәгълүмат бирүдән баш тарту турында хәбәр.

3.4.1. Опекага алучы җитешмәгән яки төзәтелгән яки тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән документларны тапшырырга риза булмаган яки аларны тапшыру мөмкин булмаган очракта, шулай ук баш тарту өчен башка сәбәпләр булса, белгеч дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезләнгән язмача баш тарту әзерли.

3.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә каршылыклар булу турында имзаланган язмача хат опекага алучыга яки попечительгә кулына тапшырыла яки тиешле карар кабул ителгәннән соң 5 эш көне эчендә почта аша җибәрелә.

3.5. Опека һәм попечительлек секторы белгече опекунлык комиссиясенә тапшыру өчен документлар пакеты формалаштыра.

Опека һәм попечительлек комиссиясе утырышта суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган, социаль учреждениедә социаль хезмәт күрсәтүдә булган балигъ булган затны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча яшәргә бирү турында нәтиҗә бирү мәсьәләсен карый. Опекунлык комиссиясе утырышы нәтиҗәсе булып беркетмә белән рәсмиләштерелгән һәм опекунлык комиссиясе рәисе һәм әгъзалары тарафыннан имзаланган карар кабул итү тора.

Комиссия утырышы документлар керүгә карап үткәрелә, тик атнага бер тапкырдан да ким түгел. Комиссия тарафыннан суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган, социаль учреждениедә социаль хезмәт күрсәтүдә булган балигъ булган затны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча яшәргә бирү турында нәтиҗә бирү буенча карар нәтиҗәсе буенча опекунлык комиссиясе утырышы беркетмәсеннән өземтә төзелә.

Эшкә яраксыз дип танылган, социаль учреждениедә социаль хезмәт күрсәтүдә булган балигъ булган затны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча яшәргә биргәндә опека һәм попечительлек органы:

- тапшырылган документларны тикшерә;
- гражданинның һәм аның гаиләсенең торак-көнкүреш шартларын тикшерә һәм гражданинның торак шартларын тикшерү актын төзи, гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләрне ачыклый һәм ____Кушымтада бирелгән форма буенча акт төзи.

Эшкә яраксыз затны вакытлыча гаиләгә бирү мөмкинлеге / баш тарту турында нәтиҗә рәсмиләштерә.

3.6. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аркылы күрсәтү.

3.6.1. Гариза бирүче дәүләт хезмәте алу өчен күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкләрдәге ераклаштырылган эш урыннарына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.6.2. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәтү тиешле тәртиптә расланган күпфункцияле үзәк регламенты нигезендә башкарыла.

3.6.3 Күпфункцияле үзәктән дәүләт хезмәте алу өчен документлар килгән очракта әлеге Регламентның 3.3 – 3.6 пунктлары белән каралган процедуралар башкарыла. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе күпфункцияле үзәккә җибәрелә.

Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәктәге ераклаштырылган эш урыны аша күрсәтелми.

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта гариза бирүче Секторга тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (6 Кушымта);

техник хата киткән, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак гариза бирүчегә тапшырылган документны;

техник хата булуны раслаучы юридик көчкә ия булган документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документтагы мәгълүматлардагы техник хатаны төзәтү турында гариза гариза бирүче (вәкаләтле вәкиле) тарафыннан шәхсән яки почта аркылы (шул исәптән электрон почта) яки дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү бердәм порталы аша яки дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәгенә тапшырыла.

3.7.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, терки һәм теркәлгән докумнтлар белән бергә Секторга тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гаризаны кабул иткән вакыттан соң 1 көн эчендә башкарыла.

Процедура нәитҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, секторга каралуга юлланган гариза.

3.7.3. Сектор белгече документларны карый һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булып торучы документка төзәтмәләр кертү максатында әлеге Регламентның 3.6. пукнты белән билгеләнгән процедураларны башкара, төзәтелгән документны, техник хата киткән документның төп нөсхәсен алып калып, гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкиленә) шәхсән кулына (имза куйдырып) тапшыра яки гариза бирүче адресына почта (электрон почта) аша Секторга техник хата киткән документның төп нөсхәсен алып килгән очракта документны алу мөмкинлеге турында хат юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура техник хата ачыкланган көннән соң яки кызыксынган заттан хата турында гариза кергәннән соң 3 көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган (юлланган) документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формасы

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларын үтәүне тикшерүне, карар кабул итүне, опека һәм попечительлек бүлегенең вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаятьне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап бирүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документ проектларының хокукый экспертизасын үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау;
- кабул итлегән тәртиптә делопроизводство алып баруны тикшерү;
- кабул ителгән тәртиптә дәүләт хезмәте күрсәтү үткәрү процедураларына контроль тикшерү үткәрү.

Тиешле тәртиптә документлаштырылган үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган, шулай ук конфиденциаль мәгълүмат таратылу ачыкланган очракта, муниципаль берәмлек башкарма комитеты җитәкчесенә гаепле затларны Россия Федерациясе законнары нигезендә җавапка тарту өчен мәгълүмат җибәрелә.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин.

Планлы тикшерүләр 3 елга бер тапкырдан да ешрак үткәрелә алмый.

4.2. Административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге, белгечләр тарафыннан карар кабул итү, дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфаты, шулай ук конфиденциаль мәгълүматны таратмау өстеннән агымдагы контроль Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башкарма комитеты опека һәм попечительлек секторы җитәкчесе һәм муниципаль берәмлекнең Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары тарафыннан башкарыла.

4.3. Башкарма комитетның опека һәм попечительлек секторы блегечләренең җаваплылыгы закон таләпләре нигезендә аларның вазыйфаи регламентларында беркетелә.

4.4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе әлеге регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәмәгән өчен җавап бирә.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өстеннән контроль дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта эшчәнлекнең ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү вакытында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша башкарыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, аларның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк (хезмәт күпфункцияле үзәк аша күрсәтелгән очракта), опека һәм попечительлек секторы хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Арча муниципаль районы башкарма комитетына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итәргә мөкин:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү вакыты яки тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылганда, әгәр туктатылу нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса;

5.2. Шикаять почта аркылы язма рәвештә кәгазь битендә яки электрон формада җибәрелергә, шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәткән очракта шикаять күпфункцияле үзәк аркылы җибәрелә ала.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең документларны кабул итүдән баш тартуына яки киткән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять биргән очракта яки мондый төзәтүләрне башкаруның кабул ителгән вакыты бозылуга шикаять биргән очракта – аны теркәгән көннән соң 5 эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исемен, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты яки муниципаль хезмәткәрнең исемен;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары, гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән риза булмавына дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә тасвирланган вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре теркәлгән булырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документлар исемлеге бирелә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәте күрсәтелүче зат, законлы вәкиле тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча опека һәм попечительлек органы җитәкчесе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаять канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

5.8. Карар кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.9. Шикаять тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелгән очракта Башкарма комитет җитәкчесе бозуларны бетерү максатында кабул ителергә тиеш булган чараларны билгели.

Шикаятьне тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.10. Гариза бирүчеләр Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, күпфункцияле үзәкнең һәм күпфункцияле үзәк җитәкчесенең гамәлләренә (гамәл кылмавына) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять итәргә хокуклы.

Суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган, социаль учреждениедә социаль хезмәт күрсәтүдә булган балигъ булган затны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча яшәргә бирү турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
1 Кушымта

Опека һәм попечительлек органына
_____________________________нән
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

**Эшкә яраксыз затны вакытлыча гаиләгә бирү мөмкинлеге турында опека һәм попечительлек органы нәтиҗәсе бирү турында гражданинның гаризасы**

Мин,___________________________________________________________________________
(фамилия, исем, әтисенең исеме)
Гражданлык________Шәхесне раслаучы документ:____________________
_____________________________________________________________________________
(кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)
Адрес (теркәлү урыны буенча) ____________________________________________
_____________________________________________________________________________
Адрес (яшәү урыны буенча)_______________________________________________
_____________________________________________________________________________

эшкә яраксыз затны вакытлыча гаиләгә бирү мөмкинлеге турында нәтиҗә бирүегезне сорыйм ___________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
(эшкә яраксыз затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туу көне, ае, елы)
_____________________________________________________________________________
Торак шартлары, сәламәтлек һәм эш характеры миңа эшкә яраксыз затны вакытлыча гаиләгә алырга мөмкинлек бирә.

Өстәмә рәвештә үзем турында хәбәр итәм______________________________
(гражданинның эшкә яраксыз гражданнарны карау һәм
_____________________________________________________________________________
тәрбияләү буенча белеме, шул исәптән белем турында, профессиональ эшчәнлек турында мәгълүмат,
_____________________________________________________________________________
опекага алучы яки попечительлеккә кандидат программаларын үтү турында
_____________________________________________________________________________
документлар, һ.б. күрсәтелә)
_____________________________________________________________________________

Мин, __________________________________________________________________________,
(фамилия, исем, әтисенең исеме)
Әлеге гаризада һәм мин тапшырган документлардагы шәхси мәгълүматны эшкәртүгә һәм куллануга рөхсәт бирәм.

_______________________
(имза, дата)

Гаризага түбәндәге документлар беркетелә:
- шәхесне раслаучы документ күчермәсе
- гражданинның гомеренә һәм сәламәтлегенә карата алдан уйланган җинаять өчен хөкемгә тартылмау турында эчке эшләр органы белешмәсе
- гражданин белән бергә яшәүче балигъ булган һәм балигъ булмаган гаилә әгъзалары турында мәгълүмат кертелгән йорт (фатир) кенәгәсеннән өземтә

- ачык формада йогышлы авырулар, психик авырулар, наркомания, токсикомания,

эчкечелек белән авырмау турында дәвалау-профилактика учреждениесе белешмәсе яки медицина нәтиҗәсе

Башка документлар:
1.
2.
3.

Суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган, социаль учреждениедә социаль хезмәт күрсәтүдә булган балигъ булган затны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча яшәргә бирү турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
2 Кушымта

**Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданинның тормыш шартларын тикшерү акты**

Тикшерү датасы "__" _________________ 20__ ел.

Тикшерү үткәргән кешенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), вазыйфасы ______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туу датасы)
____________________________________________________________нең тормыш шартлары тикшерелде;
Шәхесне раслаучы документ: ____________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

(кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)
______________________________________________________________________

(эш адресы һәм телефонын күрсәтеп, эш урыны)
_____________________________________________________ вазыйфасында эшли.

Яшәү урыны (теркәлү урыны буенча)_________________________________________________

Тикшерү барышында ачыкланды:
__________________________________________________________________ яшәүче торак мәйдан
фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта)

_____ кв. м тәшкил итә, _________________________ бүлмәдән тора, һәр бүлмәнең мәйданы: ___ кв.м, _____________ кв. м, ________ кв. м.
___этажда _______ этажлы йортта.
Йорт сыйфаты (кирпеч, панель, агач һ.б.; яхшы хәлдә, тузган, аварияле; бүлмәләр коры, якты, үтә торган, тәрәзәләр саны һ.б.) ____________________________________________________________
______________________________________________________________________
Йорт һәм торак мәйданының төзекләндерелеше (су үткәргеч, канализация, җылыту, газ, ванна, лифт, телефон һ.б.):
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
Торак мәйданның санитар-гигиеник торышы (яхшы, канәгатьләнерлек, канәгатьләнерлек түгел)
______________________________________________________________________
Эшкә яраксыз зат өчен сектор бүлмәсе, җиһаз булу
______________________________________________________________________
Торак мәйданда яши (тиешле тәртиптә теркәлгән һәм чынлап яши):

| Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта) | Туу елы | Эш урыны, вазыйфасы яки уку урыны | Туганлык мөнәсәбәтләре | Кайчаннан әлеге торак мәйданда яши |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

Гражданинның гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәт ____________________________________
_____________________________________________________________________________________

(гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәт характеры, эшкә яраксыз затны
________________________________________________________________

вакытлыча гаиләгә бирүгә туганнарның мөнәсәбәте һ.б.)

Тикшерүнең өстәмә мәгълүматы _________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________.

Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданинның тормыш шартлары
_____________________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________

(Канәгатьләнерлек/канәгатьләнерлек түгел конкрет шартларны күрсәтеп)

Тикшерү үткәргән затның имзасы ___________________________________

______________________________ ______________ ______________________
(опека һәм попечительлек органы җитәкчесе) (имза) (фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

М.П.

Суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган, социаль учреждениедә социаль хезмәт күрсәтүдә булган балигъ булган затны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча яшәргә бирү турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
3 Кушымта

**Эшкә яраксыз гражданинны Россия Федерациясе территорияисендә даими яшәүче гражданин гаиләсенә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге урында опека һәм попечительлек органы нәтиҗәсе**

Нәтиҗә төзү датасы "__" _________________ 20__ ел.

Фамилия, исем, әтисенең исеме________________________________________
Туу датасы______________________________________________________
Адрес (теркәү урыны буенча)_______________________________________
_______________________________________________________________
Адрес (яшәү урыны буенча)________________________________________
_______________________________________________________________
Гаилә характеристикасы ___________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
Белеме һәм профессиональ эшчәнлеге_________________________________

Сәламәтлеге (сәламәтлек буенча гомуми хәле, балигъ булган эшкә яраксыз затны вакытлыча гаиләгә тапшыруга комачаулаучы авырулар булмавы)
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
Вакытлыча гаиләгә тапшыру сәбәпләре_______________________________
_______________________________________________________________
________________________ гражданин тапшырган документларда
(фамилия, исем, әтисенең исеме)
Балигъ булганн эшкә яраксыз затны вакытлыча гаиләгә тапшыруга комачаулаучы шартлар
_______________________________________________________________
(бар/юк, конкрет шартларны күрсәтеп)
_____________________________________________________ гражданин
(фамилия, исем, әтисенең исеме)
гаиләсенә суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган балигъ булган гражданинны вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында нәтиҗә
_______________________________________________________________
(мөмкин/ гражданинның торак бинасында яшәмәү шарты белән мөмкин/
_______________________________________________________________
мөмкин түгел, сәбәпләрне күрсәтеп)

______________________________ ___________________ ___________________
(опека һәм попечительлек органы җитәкчесе) (имза) (фамилия, исем, әтисенең исеме)

М.П.

Суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган, социаль учреждениедә социаль хезмәт күрсәтүдә булган балигъ булган затны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча яшәргә бирү турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
4 Кушымта

Үз гаиләсенә вакытлыча балигъ булган эшкә яраксыз гражданинны кабул итәргә теләк белдергән гражданинның гаризасы

«Психоневрологик интернат №____»
дәүләт бюджет/автоном стационар
социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе
җитәкчесенә ______________________
___________________________гәг
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

Мин,______________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туу көне, ае, елы)
______________________________________________________________
(шәхесне раслаучы документ)
Яшәү урыны буенча адрес_____________________________________________________________________
Тору урыны буенча адрес_____________________________________________________________________
Эшкә яраксыз гражданинны __________________________________________________________________
(эшкә яраксыз гражданинның фамилисе, исеме, әтисенең исеме, туу көне, ае, елы)
________________________нән ________________________________________ кадәр вакытка минем гаиләгә бирүегезне сорыйм.
Торак шартлары, сәламәтлек торышы һәм эш характеры миңа вакытлыча гаиләгә эшкә яраксыз гражданинны алырга, аны тиешле шартлар, карау һәм ашау белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

Үз өстемә йөкләмә алам:
- минем гаиләдә булу вакытында эшкә яраксыз гражданинның тормышы һәм сәламәтлеге өчен җавап бирергә;
- эшкә яраксыз гражданинның тору урыны үзгәргән очракта Учреждениенең язмача рөхсәтен алырга;
- эшкә яраксыз гражданинга Учреждение һәм (яки) опека һәм попечительлек органы администрациясе белән элемтәгә чыгу мөмкинлеге бирергә;
- бер көн эчендә Учреждениегә эшкә яраксыз гражданинның сәламәтлегенә бәйле очрак барлыкка килү, шулай ук эшкә яраксыз гражданинның авырып китүе, аның имгәнүе, эшкә яраксыз гражданинны ашыгыч медицина ярдәме алу өчен медицина учреждениесенә яки тиешле эчке эшләр органына урнаштыру турында хәбәр итәргә.

Мин, ______________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
Әлеге гаризада һәм минем тарафтан тапшырылган документларда булган шәхси мәгълүматны эшкәртүгә һәм куллануга ризалыгымны бирәм..

____________________
(имза, дата)

Гаризага түбәндәге документлар беркетелә:
Россия Федерациясе гражданины паспорты һәм аның күчермәсе;
Эшкә яраксыз гражданинны вакытлыча Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданин гаиләсенә бирү турында нәтиҗә;
Гражданин белән бергә яшәүче балигъ булган затларның, шулай ук 10 яшькә җиткән балигъ булмаган затларның, гаилә әгъзаларының эшкә яраксыз затны вакытлыча гаиләгә бирүгә язмача ризалыгы.

Башка документлар
1.
2.
3.

Суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган, социаль учреждениедә социаль хезмәт күрсәтүдә булган балигъ булган затны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча яшәргә бирү турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
5 Кушымта


Эшкә яраксыз гражданнарны вакытлыча Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә бирү исәбе журналы

Башлынды:______________
Тәмамланды:____________

| № | Эшкә яраксыз гражданинның фамилиясе,исеме, әтисенең исеме, туу датасы | Гражданинның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туу датасы | Эшкә яраксыз гражданинны гаиләгә тапшыру датасы | Эшкә яраксыз гражданинның вакытлыча гаиләдә булу вакыты | Эшкә яраксыз гражданинның Учреждениегә кайту датасы | Эшкә яраксыз гражданинның вакытлыча булу урыны | Эшкә яраксыз затны вакытлыча гражданин гаиләсенә бирү турында Учреждение җитәкчесе әмере номеры һәм датасы | Гражданин-ның имзасы | Эшкә яраксыз затны вакытлыча гражданин гаиләсенә тапшырган җаваплы хезмәткәр имзасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|

Суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган, социаль учреждениедә социаль хезмәт күрсәтүдә булган балигъ булган затны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча яшәргә бирү турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
6 Кушымта

**ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮ БУЕНЧА ГАМӘЛЛӘР ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕ БЛОК-СХЕМАСЫ**



Суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган, социаль учреждениедә социаль хезмәт күрсәтүдә булган балигъ булган затны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча яшәргә бирү турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына
7 Кушымта

## Техник хатаны төзәтү турында гариза

Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ________________________________________________________(хата төре)

Язылган:_______________________________________________________

Дөрес мәгълүмат:_____________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документка түбәндәге үзгәрешләрне кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итмәү турында карар кабул иткән очракта мондый карарны түбәндәге юл белән җибәрүегезне сорыйм:

Электрон документ җибәрү юлы белән E-mail адреска:_________________

Почта аша кәгазь вариантта расланган күчермә формасында __________________________ адресы буенча.

Үземнең һәм мин вәкиле булып торган затның шәхси мәгълүматны эшкәртүгә (шәхси мәгълүматны җыю, системалаштыру, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), туктату, юкка чыгару, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматны эшкәртү өчен кирәк булган башка гамәлләр кылу), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, дәүләт хезмәте күрсәтү максатында алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан карар кабул итүне кертеп, ризалыгымны раслыйм.

Әлеге низедә раслыйм: гаризага кертелгән, минем һәм мин вәкиле булып торган затның шәхесенә кагылучы мәгълүматның, шулай ук минем тарафтан кертелгән түбәндәге мәгълүматның дөреслеген. Гаризага теркәлгән документлар (документ күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза тапшырган вакытка әлеге документлар гамәлдә һәм дөрес мәгълүматны үз эченә ала.

Түбәндәге телефон буенча миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәте сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашуга үземнең ризалыгымны бирәм: _______________________.

Дата_________________Имза_______________/________________________

Хезмәт билгеләре Гариза керде: Дата:

Теркәү №

Гаризаны алган затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме һәм имзасы.

Суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган, социаль учреждениедә социаль хезмәт күрсәтүдә булган балигъ булган затны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча яшәргә бирү турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
Административ регламентына
Кушымта (мәгълүмати)

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне агымдагы контрольдә тотучы җаваплы вазыйфаи затларның**
**РЕКВИЗИТЛАРЫ**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-84366 ) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |
| Сектор белгече | (8-84366 ) 3-13-81 | Opeka.Arsk@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы (шәһәр округы) Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (8-84366) 3-00-44 | Ispolkom.Arsk@tatar.ru |